**Сөләйман**

**Сүтелә йомгак**

**Шигырьләр, поэмалар**

Казан

Татарстан китап нәшрияты

2011

УДК 821.512.145-1

ББК 84(2Рос=Тат)-5

С98

**Сөләйман, Җ.Ш.**

Сүтелә йомгак... : шигырьләр, поэмалар / Сөләйман. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2011. – 415 б.

ISBN 978-5-298-01962-0

Шагыйрьнең бу китабына ил, халык язмышы, аның тарихы, яшәү мәгънәсе хакындагы лирик-фәлсәфи уйлануларны эченә алган шигырь һәм поэмалары туплап бирелде.

УДК 821.512.145-1

ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-01962-0

© Татарстан китап нәшрияты, 2011

© Сөләйман Җ.Ш., 2011

# Шәҗәрәдә – яфрак...

*** * ***

*Һәр җанлының үз әмәле,*
*Үзенә хас үсү мәле...*
*Бамбук үсә өскә, өскә,*
*Умырткасын тота көчкә,*
*Сөямләп үлчи тәүлек.*

*Үсә имән тәмен белеп,*
*Тамырларын барлый элек,*
*Ботакларын җәя санлап,*
*Еллар үтә, үсә җайлап,*
*Яфракларга күмелеп.*

*...Кипкән яфрак, саргайган сын,*
*Күккә этә яссы башын –*
*Биеклекне бамбук даулый,*
*...Гасырларда имән шаулый.*

*1994*

*** * ***

Җиде казык тота
минем бар дөньямны,
Җиде казык,
Җиде билге,
Җиде үзәк.
Нигез башланмышы итеп каккан казык
Туган йортка
тәүге билге,
тәүге терәк.
Йорт тирәли өммәт рухын
тота казык-читән.
Чалыш читән казыклары калкып җирдән
Күккә баккан зәмәтләрне* тота ипләп...
Мин үзем дә казык,
Тамыр җәйгән казык.

Җирдә туплыйм
бәдән-казык тирәсендә
Галәм рәсеменә бер җан-сызык.
Җир үзе дә казык,
Айны, күк гөмбәзен бәйләп
үзтирәли әйләндергән
казык-сәйяр,
Аның тирәсендә
миллионлаган
без күрмәгән җанияләр...
Кояш-казык тирәсендә әйләнә җир,
Көтү-көтү йолдыз утлый – юкка түгел –
Кояш тирәсендә йолдызга җим.
Минем дөньям казыклары җиде, дидем,
Җиденчесе казыкларның – казык йолдыз,
Җиде күкне бәйләп тоткан үзәк-казык,
Барча дөньям эленеп торган
Алтын кадак...
Ә мәхәббәт,
Ә хакыйкать,
Тәңре үзе?
Әле алда мин күрәсе казыкларның
Иң нечкәсе,
Хыялларым белән генә тоемлаган,
Галәмнәргә казык булыр
Тәңре Сүзе.

*2002*

## *Олы сәфәр*

Тәңрегә юл ачылганда
вакыт килеп,
Елмаюга әверелсә
соңгы тының,
Димәк, Тәңре сине юкка яралтмаган,
Бөек мәгънә тулы икән
елмаюың...

...Җиһан куермасы Җиргә иңгән мизгел –
Тәүге сулыш тулы орлык
бу моң-хәят.
Мәхәббәтне хакыйкатькә үрә-үрә,
Җир-сүрәдә язылачак
яңа аять.

Кара җирдән алып зәңгәр күккә кадәр,
Тетелгән җан
мамык булып күпергәнче –
Нәфес аша сузып,
Рух – таракта тарап,
Нечкә акыл кылларына тидергәнче –

Җиһан-тәнгә үрелгәнче нәфис кыллар –
Күпме сугу,
күпме кагу,
күпме гамәл?
Тигезләмә чишә-чишә уза гомер,
Син бәхетле, җан тетүгә тапсаң әмәл,

Үзәгеңә тынгы биреп тетелсә җан,
Өч дөньяны тоташтырса бер көй, бер моң –

Соңгы сулыш тәүге сулыш булыр, Аллам:
Ике дөнья арасында – арадашчың...
Адәм булып
фани Җирдә Син бәхетле:
Елмаясың – чөнки кала салган эзләр,
Җан җепләрен җайлар өчен кулай диеп,
Әзме адәм шул эзләрдә җанын эрләр.

Бакый күккә кушылгач та, Син бәхетле,
Саф нурларга юллар ачык синең аша,
Тәңре нуры – Җан кылларың – Җир уллары,
Бу мәңгелек
булмас иде
синнән башка...

...Бакый юлга сәфәр чыккач, и адәми,
Елмаюдан балкып чыкса
соңгы тының, –
Канатлары булып тәүге сулышыңның
Мәңгелеккә алып керер елмаюың...

*2001*

*** * ***

Ни ул сагыш? Мескенлекме, әллә өстенлекме?
Җелегеме сагыш халыкның?
Аршынымы әллә тарихның?..
Бәхетле заман бит
җылысыз ут кебек –
Күз ачсаң – бар кебек,
Күз йомсаң – юк кебек...
Халыкның теләсәң белергә гомерен,
Тапкырла йөзләргә ташларын-күмерен.
Чыкмассың очына, сүтсәң дә гасырлар
Сагыштан үрелгән йомгагы – күңелен.
Һәр тамчы сагышы – гасырлар агышы...
...Халкымның укмашып, терелеп барышы!

*1994*

## *Шәҗәрәдә яфрак булып*

Таш уала, тамчы кибә,
балчыкның да, алтынның да үзлегендә
юктыр мәгънә.
Даһи Оста кодрәтендә туса туар
ошбу матдәләрдән садә-сурәт.

Әтисез мин
булыр идем әллә бер таш,
әллә тамчы, әллә балчык.
Әти биргән үз тәненә, җисеменә тәңгәл буй-сын.
Әгәр дә мин таш та, су-балчык та түгел икән, –
Әти, сиңа, җан-рухыңа рәхмәт яусын!

Сызгыра җил, өзгәләнә,
дулкын ярсый, бәргәләнә,
бии ялкын.
Әмма да бу шулай кебек тоеладыр гына, –
җансыз алар,
Даһи Оста сулуыннан булса гына,
сурәткә дә җан-тын сабар.

Әтисез мин
булыр идем җил-сыбызгы,
яки ялкын, бәлки, дулкын.
Әти биргән
үз җанынннан
биштән берен өзеп,
Шул җанкисәк бәргәләнә, –
йә, кара син түзеп!

Әтисез мин
булмас идем бу җиһанда,
Тумас идем һичкайчан да кеше булып...

...Юк, югалмас
таза тамыр –
Улым үсә,
шәҗәрәдә
яфрак булып, –
яңа буын...

*1990*

## *Ат тоягы*

Алты-җиде яшьләр булгандырмы, биш-алты малай, күршеләр, елга буена салам ягарга йөргәндә юлда ат тоягы табып алып, шул тоякны учакта кыздырганыбыз исемдә...

Әй егетләр,
хәтердәме теге
ат тоягы?
Хуҗасы – ат
Киткәч иткә, тиресе – читкә,
җаны – күккә, –
Яткандыр ул безне көтеп,
таптап туйгач
юл тузанын.
Бер буалык салам
яккач,
Ни чыжлады,
ни тартылды сеңерләре!
Уяндымы, сызландымы
шул тоякның
баш киткәндә
өзелеп калган кисәк-җаны, –
искә алып
юл ташларын барлап үткән
гомерләрен...
Сугыша-сугыша, куыша-куыша
шәүрин буе,
Бер – беребез, бер  беребез
кимердек без сөяккәчә
шул тоякны –
Хет берәүме искә алсын
үзен атның.
Ат урынына без кешнәдек,
Колын булып без сикердек
Олы Елга сыртларында, –
и-һа-һа-һа!..
Юкка гына
кибеп барган Бүле көтте буалауны –
Килә торды тирес-салам буа өчен –
без ут иттек
бер тоякка
шул олауны...

Хәтердәдер – дөнья чиксез,
Төн ни, көн ни,
кич тә иртә, иртә дә кич, –
Бәхетле чак –
йолдызлар вак,
кайгы ерак,
беләктә көч!
Алты-җиде яшьләр микән –
Гүя бер төш...
Еллар үтте...
юллар үттек...
Ат тоягы онытылмый –
Үзем бит ат!..

Ә кемгәдер (кеше димим) безнең аяк
шул ук тояк,
Кемнәргәдер (йә нәрсәгә) белем-фикер-акылыбыз
чәйгә десерт иртәнге як...
Ә җан очар йә оҗмахка (йә, бир, Алла!),
Йә тәмугка (сакла, Аллам!),
Йә янәдән башлар җирдә
бер-бер тәндә яңа буын...
Ком сәгате
тавыш-тынсыз или бирә дөнья комын...

...Ераккарак китеп кара,
кеше, җиргә –
Күрәсеңме –
– Уа! уа! – чайкаласың бишегеңдә,
Кулларыңда уенчыкка
бомба, корал...
Алты-җидең кайчан килер –
Әле сорау...
Тагын бераз күтәрел дә тагын кара –
Син юк анда, җир үзе дә нокта гына...
Безнең тормыш, ыгы-зыгы кызыктыр ул
микроскоптан йә лупадан караучыга...

*1993*

## *Казан елгасында су түгелдер*

Казан елгасында су түгелдер,
Кургаш тулы ярлар арасы,
Киң дә түгел, чоңгыллар да тынган,
Ничек аны ары чыгасы?

Матәм чорын ачып беравык,
Күтәрелде тарих пәрдәсе,
Төер булып бәрде тамакка
Уналтынчы гасыр ядрәсе.

Юк, булмаган берлек: төгәл җавап,
Ике яктан килгән бер татар,
Түбәтәй бер – фикер-акыл төрле,
Шул ук сәбәп бүген – шул хәтәр!

Санлы түгел, саллы булсак икән,
Алтын түгел байлык – зыялы!
Шул вакытта кыл да сыймас рәткә
Дары тулы базлар сыярмы?!

Ә бүгенгә – сорау өсте сорау,
Йә, кайсыгыз белә җавабын?
Биш татарның бүлешмичә, бердәм,
Бармы берәр йорт-җир корганы?

...Кис тә яндыр: түзә – сабыр,
Умырткасы булса камыр,
Шәҗәрәдә мәллә шаукым,
Шартлауданмы тузган акыл?
Чәчелгәндер, очкан фикер,
Әле башы калган, шөкер,
Калган гәүдә, яралы тел,
Җанмы соң бу, әллә соң көл?
Төзелеп бетмәгән дәүләтем,
Өлгереп җитмәгән милләтем, –
Иртәрәк тузган шул таш чүлмәк,
Алтын ук булмаган ул, димәк,
Селтәмик барын да Урдага,
Гаеп бар бүген дә уртада.
Буаргамы дисәң бер-берсен,
Тукмаргамы дисәң бер-берсен,
«Йоклаганмы, үлгәнме», – дисең? –
Күз ачып та өлгерәлмисең!
Теле – чарлаган пәке,
Каезлый безнең рәтне,
Ерак бармый, үз итеп,
Татарын ята тетеп...

Казан елгасында су түгелдер,
Кургаш ялгый ярлар арасын,
Киң дә түгел, чоңгыллар да тынган,
Насыйп микән ары барасы?

*1993*

## *Авылымда яңадан мәчет ачылып, ике ел үткәч...*

Уңган иде чикләвекләр –
үскән иде каплап яфракларын,
көязләнеп,
Чирткән берсе – йә буш, йә черек,
Ә бит тыштан, кабык ягын баксаң,
Җиткән иде тәмам өлгереп!
Шундый купшы, шундый ыспай тышлык –
Үскән генәме соң – ишелгән!
Тик хикмәте,
шыту-үсү мәле
Чикләвекнең бит ул төшендә...

Мәчет тавын бизи яңа мәчет, –
Тамырымы калган сакланып?
Шатланыйммы, сөенимме шашып,
Елыйм микән җиргә капланып?

Яңа мәчет бизи Мәчет тавын,
Өмет шәме сынып сүнгән чак,
Исә җилләр, исә Тимерледән*,
Күпме бәгырь ятка дүнгән чак.

«Лә илаһы...» – колагымда чыңы,
Изге җаннар гүргә иңгән чак,
Кыйбла-айсыз туган буын чоры,
Кеше үзен-үзе җиңгән чак.

Мәчет тавын яңа мәчет бизи,
Тауны бизи – анысы бәхәссез,
Иске нигез көтеп алган мөнбәр –
Иман түгел микән бәһасе?

*1993*

## *Татарстан картасына карап*

Дәүләт чиген карап баксаң
Төрле яктан, эчтән-тыштан,
Татар өстән, татар астан, –
Шуңа да ул аталадыр Татарстан.
Тукый берәү – Урыс ия, –
Россиянең бер өлеше.
Икенчесе каршы чыга, Татар ия, дия-дия,
Уналтынчы гасыр башын кайтармыйча,
Юк килешү.

Татарстан, Татарстан,
Киселгән, кысылган, болганган,
Гасырлар тудырган ил-дастан,
Хуннардан, кыпчактан, болгардан...
Кемгә дә кермәгән җир таптап,
Күршегә атмаган ут-балта,
Элмәгән күршенең теленә йозак та,
Куймаган күршенең дененә тозак та.
Яшәгән бүлешми һаваны,
Ирекне, Иделне, Даланы...

Ә бүген ул үзе яралы,
Теле дә ямаулы-ямаулы,
Үзе дә гүя зур ямаулык, –
Һәрьяктан татарга камаулы...

...Киләчәк гасырлар комында
Калырмы татардан җылы эз?
Телне дә корт чаккан замана,
Юк җавап сорауга, мир өнсез!..

Бер генә терелү чарасы,
И аңлачы, татар баласы!
Комда – эз, тәндә – җан, илдә сан
Булыр ул, акылың җыялсаң!

*1993*

## *Болгар җиле*

Исә җилләр – хәтер җиле,
Исә җилләр Болгардан,
Болгар җиле югалмаган –
Хәрабәгә чолганган.
Кара пулатка сыланып
Җилләр ник улый икән,
Аянычмы истәлекләр,
Киләчәк тырный микән?
Ак елан булып ысылдый
Болгар сакчысы – җилләр,
Хатирәләр – ут-өермә,
Җаның өтәр, димиләр.
Жәлләмиләр варисларын
Шәһре, шанлы Болгарның,
Таш җаннарга җил ни, зар ни –
Куыра җанлыларын.

...Болгар җиле гасырлардан
Гасырларга күчешли,

Бер-бер хәбәр отар микән,
Безнең чордан үтешли?

*1994*

### *Диңгез күрмәс иде...*

Пычак белән кыпчак рифмалаша,
Икесе дә үткен – кыл кисә!
Татар дигәч, тагын шул ук аһәң –
Кыпчак килеп төшә кылт! искә.

Мин татармын,
әмма дала түгел, –
Күңелемә якын урман-җир,
Кылган түгел, имән шавы җанда,
Исән әле, димәк, агацир*...

Мин татармын,
әмма бүлгәләмә!
Каныма да тимә тамчылап,
Тарих җайлап, өндәп маташмаган,
Татар иткән төеп-камчылап!

Идел белән аһәңләшә татар,
Үз канына кушып кыпчагын!
Зөя суы диңгез күрмәс иде,
Үз итмәсә Идел кочагын...

*1994*

### *Ә һәлакәт якыная*

Мин – җир, мин – күк,
Мин – бер, мин – күп,
Мин – су, мин – ут,
Җан – мәңгелек, яшәү – минут.
Мин бер җиһан, мин бер нокта,
Мин бер галәм һәм хәтта ... юк та.
Дөнья гаме күкрәгемдә,
Җир үзе дә бер иярчен
үзәгемдә,
Барча халык фани җирдә,
көйләр, моңнар –
бер дөньямның мең субае...

Чал тарих, әйт, күрдеңме син берәр вакыт
дөньяларның җайлы чагын?!

Сират күперен дә җуйган вакыт!
Кешелеккә сынау килә сынау арты.
Ахыры Галәм, уңмады, дип, орлыкларым,
Кешеләрдән акылларын ала тартып...

...Ә һәлакәт якыная минут саен...
Сөембикә манарасы авыша бара,
моңсу ае...

*1994*

### *Ит тегермәне көенә*

Дөнья шулпасында адәм-калҗа,

Язмыш кашыгыннан кача-кача
бата бара чәнечкенең дүрт ябенә.
Киек Казлар Юлларыннан
суынып барган юл тузаны
коела-өелә өсләренә, –
Кемгәдер ул бөтнектәдер.
Адәм-калҗа йөзә бирә бата-калка,
Күренеп ала
Әле башы, әле йөрәк,
әле бәгырь...
Яфрак-яфрак җир өсте дә
күз сурәтле киң тәлинкә төбе, –
Җәлләмәгән берәү яфракларга
буявының кызылын да,
сарысын да, сорысын да, карасын да.
Шул тәлинкә төпләрендә тәгәрәтеп,
сукыр көннәр, өнсез төннәр арасында
нәрсә йөртә бер-берсенә бәрә-төртә
бәндәләрнең кызылын да,
сарысын да, карасын да?

Әй, әллә кем! Аш вакытың җиттемени?!
Болгатасың Тәлинкәңне төпләреннән?
Без «Җир» диеп, без «Өй» диеп,
күпме мизгел торган идек бу Җиһанда,
Ялт-йолт килә көмеш кашык
син аш салган нәни казан өсләрендә...
Арлы-бирле очынабыз, тузынабыз, кизәнәбез –
Кайнап чыктык төрле яклап...
Димәк, чынлап өлгергәнбез,
                ахры, чынлап өлгергән
                                без...

*1994*

* * *

Мең җәрәхәт – түзә йөрәк, –
эзен салган һәр теш кысу,
Сабан-телләр һаман сөрә, –
Безгә – бәгырь,
                сезгә – басу...

*1994*

* * *

Чит-ят мохит, чит-ят гадәт...
Моң-аһәң дә
биштән үргән чыбыркыдай
                ала-кола.
Юк биредә,
канатлар юк сиңа, йөрәк,
                ут эчсәң дә.
...Ә бу – Казан, рухи мәркәз,
                изге кала...

*1994*

### *Бу заман язгы елга күк*

Бу заман язгы елга күк, –
Юк әле тынар чагы,
Боз өстендә яңа гына
Янды өмет учагы.

Мәңгелек кебек иде боз,
Бозда яктык учаклар,
Учаклар сүнде, капланып
Өмет җан биргән чаклар...

Кемдәдер өмет кабынды, –
Болганчык судан – балык.
Чирү-чирү адәми зат,
Бу халыкмы?
Бу – халык...

*1994*

*** * ***

Әйттеләр, халкым, бире кил,
Биредә сиңа азык.
Арышы юк... камылга да
Рәхмәтле булды халык.
«Юкәдә икән чикләвек», –
Ышанды шунда халык...

Килде көн, тагын өндиләр:
Бердәнбер юл шул,
халык
упкынга оча күмәкләп,
Йә, кара алып калып.

...Көтү чире йоккан халык,
Тәм таба үзен чалып...

*1994*

## *Татарстан флагына карап*

*****

Татарстан ярасына
ак бинт булып
Ай сузылган...

*****

Өстә – яшел, яшәү, ямь.
Аста – кызыл, көрәш, каза.
Уртасында –
әллә ауган өмет-шәм,
әллә өметләнеп киерелгән гасаб...

*1994*

*** * ***

Күк һәм җир – тегермән ташлары,
Ә җиһан гүяки тегермән.
Ташка – таш:
Тегермән тавышы басалмый –
Җирдә гел ызгышлар, дөбердәү.
Ташка – таш:
Таба җай – кемнәрдә уяулык.
Ваемсыз кавемнәр
югала ватылып, он булып.
Тарихка чигелә каберләр –
Гүяки капчыкка ямаулык.

*1994*

* * *

...Һәр җанлыга туу, үлем зарур –
Һич өзелмәс канун җиһанда.
Йә аңла син шуны,
        ил ярасы
Үз аркаңда ярылып ятканда.

Ни аяныч, милләт җуйган гасыр,
Ахры, бүген килде халыкка,
Тәңре биргән сихри, моңлы телем
Тере килеш ята табутта!..

*1995*

* * *

Огню огонь предела не положит,
Не сохнут от дождя глубины вод...

*Ф.Петрарка*

Әмма ләкин:

Ут белән утны егалар урманда,
Утка чик бар каршыдан ут булганда.
Яңгыр килеп мәхрүм итә буадан,
Кара тасма гына кала елгадан...

*1995*

* * *

Катлам-катлам боз астында,
Катлам-катлам су астында
Сөләйман балык өне,
Ярый әле каргашырга,
Ярый әле алдашырга
Белмибез балык телен.

Шөкер әле, күл төбендә
Яши белгән халык бар,
Безнең мәнсез сүз тимәгән
Җан иясе – балык бар...

*1995*

## *Тәкә бәхете*

Башында мөгез, өстендә тире,
Тәкә хыялы – булырга бүре!
Сырлы мөгезләр кыелды төптән –
Иң зур киртәдән арынды тәкә.

Мөгез булмагач, шатланды тәкә,
Бүре булачак бүген-иртәгә.
Төсләр бер чама. Тун артык җылы –
Кыркылды йоны, өтелде җаны.

Күлдә чайкала горур, кыю сын,
Чирү башлыгы тәкә булгансың!
Шәүләдә – бүре! Калды бик азы:
Тешләр табасы, койрык тагасы...

Тәкәгә бәхет: нинди охшаган!
Бүре инде бу, суйган-каплаган!
...Чирүгә бәхет: чирү башында –
Төшке чәе дә, кичке ашы да.

*1995*

### *Ачыну*

Гәүдәң җирдә, җаның гүрдә,
Уянмадың,
Өч-дүрт кабат күзең ачып карасаң да.
Ахры, мәрттә төрк варисы,
Уянмас та,
Табанына очлы безең кадасаң да...

Ах бу чечен, Ичкер иле,
учка салдың зиһенемне.
Җәрәхәттән туган мәрҗән бөртегедәй,
Җан-кабырчык үзәгендә
фикерләрем.
Ике фикер аерылгысыз:
моңлы сагыш,
сагышлы моң,
Өскә чыга әле берсе, әле берсе:
Айлар буе ут йотса да исән, исән!
Моңлы сагыш –
җәрәхәтле чечен җире!
Гасыр буйлап кисәк-кисәк өзелеп килә
киселгәнен сизмәс хәлдә
сагышлы моң – татар теле...

*1995*

### *«Бире»*дә ул да, мин дә...*

Җиргә иелгән айбагар-көнбагыш...
төн тышчалы орлыкларда – туачак көн.
Очар канат орлыкларга: давыл да җил,
Орлыкларның суыра җанын ни битараф: ком-ташлы җир.

Салмак кына тибрәнүдә
күңел-диңгез.
Бер-бер артлы
тезелеп китте
вак дулкыннар:түгәрәкләр, түгәрәкләр...
Айги** сүзе йә томшыгын,
                йә канатын тидергәли агымсуга...

Сыгылмалы корыч чыбык катлы-катлы:
Бер очында йөрәк: йомгак башы чәнечкеле баригада***...
Бер очында гомер:
Чыбыгында
ут кызуы, су суыгы,
              тимер сандал «тибрәтүе»...
Бола-судан хасил туфан,
Батыр-үрдән бәргән вулкан:
Тәңре үзе тамга куйган төрки-туган...

*1995*

### *Кем соң җәйлар телнең җанын*

Чәбәләнгән Телем кат-кат,
Йолкып-тартып тетмәгез,
Үрмәләр өчен үрләргә
Телне аркан итмәгез...

Чәбәләнгән Телем кат-кат...

Чәбәләнгән татар теле,
Кем соң үрер җаена?
Кем соң җайлар Телнең җанын
Телнең үз уңаена?..

Кем соң җайлар Телнең җанын...

*1995*

*** * ***

Янә кайтты
меңләп еллар каккан ярларына
талгын дулкыннары Казансуның.

Калыктылар
таллары да ләм астыннан,
тал үзәген
бoҗра-бoҗра элмәк-еллар
...ята буып.

...терелүме, әллә
талпынумы соңгы –
дулкыннары дерелдәвек
Казансуның?

*1996*

*** * ***

Комда мизгел: адәм эзле җирдә.
Милләт эзе җирдә – шигырьләр.
Көл-күмердән туган милләтләр бар,
Шигырьләрдән үреп гомерләр.

...Чыра булып телгәләнгән милләт тә бар –
Күмер булып өелә
шигырьләр...

*1996*

*** * ***

Тамырлар
Табаныңнан
Таныр лар...

*Л.Зөлкарнәй*

Уйланырлык: авыр ул киселү,
киселмичә
...үсү юк җанга.
Киселүләр
аянычлы түгел... –
шомармасын гына табаннар...

...яланаяк шәүрин чирәмендә...
...киселгән җир...
йөрәк – дөп-дөп-дөп...

Шәүрин буен
табан сыры тоя...
Димәк,
бире
миннән калган төп.

...үз төбенә янә күтәргәндә,
яфрак ярыр кебек бүрәнә дә...

*1996*

## *Соңгы болыт*

Соңгы болыт булмасмы бу –
очты күккә болыт булып,
җан түреннән өмет.
Күгәренгән ил битенә
ятты
кершән-иннек.
Ахры, кыйблаң «дөрес» иләнгән
күршең кулындагы иләктән,
кичә генә «кыргый милләт» идең,
имеш, бүген – «зирәк милләттән»...

Аерасыңмы, «ура! халкым»,
мәдхиядән мәрсияне?
Татар илен болыт иттең,
булыйм диеп россияле...

*1996*

*** * ***

Җыр кирәкме сезгә?
Җыр да бию?
Җаныгызмы сорый тамаша?..
Әй җәмәгать,
дөнья урманында
кайсыбыз соң бүген
адашкан?..

Кайсыбыздыр безнең
вакыйг түгел,
дөнья көзгесендә бер рәшә,
тик белалмыйм:
минме,
синме, дустым,
икебез дә бергә,
янәшә...

Фани дөнья – зеңләп торган көзге,
фани дөнья –
синең дөньяңдыр.
Мин – уйдырма,
бәлки, нур сыныгы...
көзге кысасында урын тар...

Йә, ник шулай йокы белмисең син,
текәләсең нигә үтәли,
күңел күзем,
маңгай күзен узып,
...син күргәнне аңлап җиталмыйм...

Мәче сыман
сыртын кабартканы,
этләр кебек
тешен ыржайтканы,
куык булып тулган –
күпергәне,
карачкыга өлге итеп
киптергәне –
ниндие юк бу дөньяда көзгеләрнең,
әйтерсең лә кәмит бүлмәсендә
чагылдыра
шадра
йөзләрен дә:

калҗа тотып,
табак
ялаучысын,
билен бөгеп,
таяк
күзләүчесен,
кулын биреп,
аяк
чалучысын,
туган диеп,
пычак
кайраучысын,
вәгъдә биреп,
җаның
алучысын,
салам җәеп,
базга
салучысын,
борын чөеп,
болыт
кагучысын,
аклыйм диеп,
дегет
ягучысын,
сыйпап-сыйпап,
койрык
тагучысын,
милләт диеп,
мөнбәр
даулаучысын,
Алла диеп,
тамак
ялгаучысын...

Кая гына караш ташласам да,
ватык көзге – шадра көзгеләр...
Сәбәп, ахры, миндә,
кем әйтала, –
аңлатыгыз миңа,
күзлеләр...

*1996*

## *Дәүләтле татарлар*

Җил-давыллар
җыештырмый,
туздыра гасырларда.

Әстерхан, Кырым, Себернең
туфрагы – татарлардан.

Югалмастан ыру-ыру
горур намың кайтар,
төрки-тамыр – алтын казык,
шул тамырдан
татар.

Бер казыкка,
төп өйгә,
Күлтәгин ташына
бәйләнсә күңелдә
канатлы тулпарлар –
әй, чит-ят кавемнәр!
Без исән!
Кулга кулмы,
билгә билме?
Без риза!
Без әзер!
Без күк түрк өммәте –
Дәүләтле татарлар!
Дәүләтле татарлар!

*1996*

*** * ***

Беркемнән дә түгел,
беркемгә дә түгел.
Хакыйкатьнең канатлары –
Ирек.
Зиһен элпәсендә – җаны.
Җиде күген ялгап
эзли күңел
Хакыйкатьне –
Кан туганын.

*1997*

*** * ***

Каурыйлары
чәбәләнгән асыл кошлар
канатларын кагып көй-моң сузармы?

И татарның тишкәләнгән әлифбасы!
Форсат килеп ямалырмы, йә тузармы?

Чәбәләнсә күңел-йомгак җепселләрең
төссез-тозсыз ят яңгырар үз сүзләрең...

...Табигатьтән, күктән алып
авазларның
иң затлысын Тәңре салган...
Тәңгәл имла туган телгә – кошка канат –
азат җаннан...

*Марсель – Экс-ан-Прованс*
*1997*

*** * ***

Даң-даң бүрәнә, Садри бабай үләнә,

Ике кадак оны бар, дүрт кадак йоны бар,
Бер сәләмә туны бар,
Картлар-яшьләр, җыелышка!
*(Балалар фольклорыннан)*

Мәҗүсилек кылларында
иң нечкә, назлы көйләр,
колак-күз алмас кылларда
саклана яшьлек, диләр.

Күңелем гамәл дәфтәре –
яшьлек сызган сыр-җөйләр,
шул җөйләрне барлый-барлый
яшим ләса мин – җүләр.

Йөрәк түренә сыенган
утка гашыйк балачак,
хыялый яшьлек оясы –
шәүриндә* – төнге учак.

*1997*

*** * ***

Хәтсез йолдыз күктә,
Иң якыны – Кояш.

Адәм моны күреп белә.

Хәтсез йолдыз күктән өстә –

Адәм аны белеп белә,
Адәм аны сизеп белә.

Адәм шундый –
Күрмәгәнне күрә белә,
Күрмәгәнен
...якын күрә.

Әллә кемнәр, әллә кайда –
Шагыйрь, галим,
...әллә ниләр.

Адәм моны күрми –
белә,
Адәм моны белеп белә.

Үзе белән гомер сүткән
бәндәләрне
Адәм күрә –
Күреп белә.
Тик...
күргәнен күрә белми, –
күреп тә – күрми,
күреп тә күрми.
сизеп тә – сизми,
сизеп тә сизми.
белеп тә – белми,
белеп тә белми.

Язылганча – килеш-килбәт, бәдән...
Тәңре, шулмы –
син бар иткән Адәм?

*1998*

*** * ***

Диңгезгә килдем.

Барча халык, ахры,
диңгездәдер, дидем.

Тауларга мендем.
Барча халык, ахры,
таулардадыр, дидем.

Кинәт килгән бер фикергә кердем.
Шул фикердә инде
меңнәр барын күрдем.

Бер дөньяда
мең дөнья бар...

...Дөньяларны бүлеп тора
иләк-ярлар.
Бер дөньядан бер дөньяга
күчә азлар...

*1998*

*** * ***

Без бар икән җирдә, Тәңре кушып, –
без, татар да,
димәк, мәхәббәтле!

...Халык – бер ил:
һәр адәме
үз иленә
булса гына мәрхәмәтле.

*1998*

*** * ***

Чиста күңел, изге гамәл, ачык фикер –
Табигатьтән аермадың, Аллам, шөкер.
Мәхәббәттән калдырмадың Чишмә халкын,
Горур иттең, матур иттең яшен-картын.

Болгавыр чак болгатса да ачы җилләр,
Капласа да авыл өстен яңгыр-болыт,
Тайгакларда югалтмадың кыйбла юлын,
Тайгакларда таянычың – сабыр холык.

Сагышлардан сагышларга салды язмыш,
Юк түгелдер үкенерлек ялгышлыклар.
Чишмә суын кой* суыннан аерабыз –
Тәүбә диик, тәүбә итсәк, Тәңре саклар.

Нинди серләр саклыйсың син, туган җирем?
Күргәнсеңдер манарадан Болгар илен.
Сизмәдем дә, кай арада истең соң син,
Тарап үттең тамырлардан, Вакыт җиле?

*1998*

*** * ***

Җиде күккә күтәрел дә
Бер карап бак дөньяга,
Тәңре яралткан җаннармы
Тәңре корган ояда?

Җиде күккә күтәрел дә
Бер карап бак үзеңә,
Акыл канат куйган микән
Телгә кунган сүзеңә?

Җиде күккә күтәрел дә
Бер карап бак җиһанга,
Җиһан чиксез, җиһан тыныч,
Кемнәрдән тыз-быз, гауга?

Җиде күккә күтәрел дә
Ач күзеңне, и адәм,
Кемгәдер орчык кына ул
Без яшәп яткан Галәм...

*1999*

## *Татар йорты*

Татар йортын тымат* нигез тота,
Катлы-катлы сарай салырлык.
...Бер катына тулып йоклый татар,
Идәненә җәеп... сабырлык.

Туры басса, түшәм башка бәрә, –
«Бөек шигырь», «бөек көйләр»дән.
Ә нигә ди безгә биек түшәм –
Шуышырга күпләр өйрәнгән.

Биек түшәм кирәк түгел безгә,
«Бөек түшәм» каплый күкләрне,
Өч-дүрт катлы йортлар буладыр дип
Аңына да керми күпләрнең...

Татар түшәменең матчалары –
«Мин-мин» шагыйрь, «мин-мин» түрәсе,
Шул түшәмнән ары күк күрмәгәч,
Такырая бара түбәсе...
И татарым...

*2003*

## *Өч таш*

(*Күңелем портреты*)

Мин күкләргә аттым чакматашын,
Җаным булыр аның чакмасы,
Бу чакматаш – кылган гамәлләрем,
Җан-чакмага күктә калкасы...

Чакма чагылып, чакматаштан туар йолдыз...

Офыкларга аттым янә бер таш –
Хыялларым аттым йомарлап,
Гомер чиге купшы кабер булыр,
Баш очыма аны куярлар...

Һич югында, җир өстендә
бер-бер тамгам калыр...

Иңбашыма салдым нужа ташын,

Иң авырын ташның, иң зурсын, –
Бәхет килеп канат үскәндә дә,
Аякларым җирдә нык торсын.
Гомер уза. Баса бара йөк-таш,
Тирәнәя бара һәм эзем...
Чакматаш та, хыял-таш та түгел,
Бу – язмышым минем, бу – үзем!..

Йолдыз – күктә, кабер – чиктә,
        Туган көннән: «Ядәч!» – дидек язмыш белән,
                        истә әле, истә...

*1993*

* * *

Нәрсә соң ул Бәхет, диеп
баш ватармы
кем бәхетле?
Хафаланмас Сөю, диеп, мәхәббәтле,
Лаф орырмы, Ирек, диеп,
кем ирекле?
Сулаганда саф һаваны,
алмыйсыңдыр уйга аны,
Кысылганда гына тының,
аңлыйсың һаваның асылын...

*1993*

* * *

Дуслык ни ул? Бармы? Юкмы? – ялгызлык өзгәләнә,
Дусты булган – яши бирер, үзәген өзгәләмәс.
Туганлык бар, бусы – төгәл,
            ни җитсен туганлыкка!
Бәхетем дә, рәхәтем дә – якынлык-туганлыкта!

*1993*

## *Асылташ*

Гомереңне вакыйгалар иләгеннән
или-или,
Оныгыңа һәм тагын да алгы буын варисыңа
барлаганда тормышыңның
җәүһәр-энҗе бөртекләрен, –
Калсын иде шул иләктә күзгә күренеп
бер асылташ,
Әйтер идең: гомер иттем,
юкка гына көч түкмәдем,
Ташып аккан бозлар сыман
кайчакларда булыйм булсам,
Кыйблам – хаклык, югалтмадым елга ярын,
Нәсел-ыру бәҗрасына миннән мирас –
шул йөзек-каш...

*1993*

## *Болгар таҗы*

Шәһре Биләр – Болгар таҗы,
Көмеш билбау – Чирмешәне,
Күңелләрдә яши нурың,
Ай-кояштай Шәрекъ шәме.

Мин сиңа гашыйк, Биләр,
Син миңа тансык, Биләр,
Ап-ак чәчкәләр хушына
Кушыла синең көйләр.

Ай кызыга кызларына,
Кызыл чия иреннәре,
Алтын чәчле, зәңгәр күзле
Безнең Биләр киленнәре.

Кылыч тисә кылычына,
Яшен уты – егетләре,
Әмма уен-көлке дисәң,
Булмас алар кебекләре.

Биләр таңы алсулана,
Өзгәләнә былбыл, сайрый,
Ишетәсеңме, сузып-сузып
Кәккүк безгә еллар саный...
кәккүк... кәккүк...

*2003*

*** * ***

Халык өчен
Һәр чор, һәр көн –
Ни Киләчәк,
Ни Үткән көн түгел.
Халык тоташ –
Ул бер тәсбих кебек.
Үткән көннәр, чорлар –
Аһ-зар, чыр-чу, җыр-моң, теле –
Түгелме соң кешеләрне халык итеп
Тоташтырган өммәт-тәне?

Тере халык өчен Яшәү
һәрчак – хәзер,
Һәрчак – бүген!
Тоташ халәт,
Тоташ акыл,
Тоташ күңел...
Үткән көн ул – кеше гомереннән,
Тормышыңны тасма итеп
карaганда, –
Анысы да,
тинтәк башка
Яңару һәм искерүнең,
Яшәрү һәм картаюның
Төп асылы сыймаганда...
Халык йә бар, йә – юк.
Бер алмагач кебек –
Тамырлары, кәүсә-ботаклары,
Яфраклары, чәчкә-алмалары –
Барысы да бергә – бербөтен.
Үткәне һәм киләчәге бергә:
Тамыр – кәүсә – ботак –
– яфрак – чәчәк – алма...
Бу бергәлек яши
тамыр, кәүсә барда...
...Бер тукыма – халык.
Яшь тә түгел, карт та түгел,
Шул ук халык,

Тукымадан тора гомере.
Затны затка тукып үсә халык,
Һәр затның бар яшәү дәвере.
Халык өчен кеше
Йә яшь, йә олырак, йә карт –
Кеше туа, яши, картая,
Тукымага бер-бер артлы
керә тора.
Димәк, сез дә, мин дә –
халык өчен тигез бер ... зат,
карамыйча
кайчан, кайда
тууыңа, яшәвеңә...

...Ә халыкның кайдан
башланмышы?
Кайсы өлешеннән тукыманың
Аерып алып булыр иде бер халыкны?
Балык хәятына
төшенергә тырышуын
бер балыкның
хәтерләтми микән минем тукыганым?
Бирелгәнме җепкә күзалларга
Тукымага төшкән бизәкләрне?
Бирелгәнме җепкә
төшенергә асылына
Тукымага бизәк салган
калыпларның?..

...Җиһан өчен халык –
Халык өчен инсан булган кебек...
Сүз җелеге шунда:
Яшик әле, гүя дөньялар
Бүгенгедән генә торган кебек.
Кеше өчен шулай дөрес түгелмени?
Гомере буе бер җеп булып
өлгерә дә
(кайсы кыска, кайсы озын,
кайсы нечкә, кайсы калын,
кайсы төсле, кайсы төссез,
хәтта була үзенә хас исе, тәме)
тукыла ул җирне сарган тукымага.
Тукымадан
халыкларның башланмышын
табып кара!
Җиңел түгел, ешрак – мөмкин түгел,
Кайчы белән кереп-кереп карасаң да.
Идел белән чагыштыру
төгәл булыр,
Йә, кара син, күпме елга
биргән аңа суын!
Ә ахырда бер диңгездә Идел үзе...
Шунда төшеп юк буласын сизгән кебек,
Теләгәндәй аерырга һәлакәттән һәр инешен,
Вак елгалар булып коя Идел
Зур Диңгезгә...
Инсан гомередәй, Идел суы
кушыла тора, Хәзәр, сиңа...
Суын коя, әмма үзе
пар ярлары кочагында
Идел булып кала бирә,
Суы гына һаман ага,
Һаман яңа...

Күктән иңдерелгән
Җан-рухларның
Табигатьтә чагылышы – Кеше.
Халык итеп туплап кешеләрне
Үз катына кайтаручы – Җиһан.
Кеше – Халык – Дөнья – Җиһан.
Бер халыкның мең аһ-зары бер дөньяга сыя.
Бер Җиһанда мең дөнья бар.
Бер Җиһанга барча дөнья сыйган.
...Халыклардан тукылганы Җиһан тукыманың
башланмышы
һәм ахыры аның
«Булыр ахырзаман»...

Таңы микән, әллә киче микән
Без яшәгән чоры бу Җиһанның?
Яңа таңга коеламы йолдызлары,
Әллә төнгә кучә микән
Кичке шәфәкъ?
Ни булса да, минем гомер
тукымада бер бизәкнең җебе булып
ята бара тукымага – «хәзер!» «бүген!»
Бүген яшәү, бүген тою, бүген рәхәт!
Мин бар хәзер, мин бар бүген!
Кичәгесе – ул мин түгел,
Ул минем эз.
Иртәгәсе – ул мин түгел,
Ул бары фал, ул – бер хыял...
Артта гомер – диңгез,
Алда гомер – диңгез,
Мин нәкъ ике диңгез уртасында
Әллә көймә,
Әллә утрау –
Ике як та чиксез, ике як та тигез,
Ике як та чиксез билгесез...

...Безнең заман, ахры, Җиһан киче булды,
Эңгер-меңгер шуңа Җирдә дә.
Җиһан төне тынлык алып килер,
Ял, яңарыш килер Җиргә дә.
Килер заман, янә таңнар атар,
Яктылыкта яңа орлыклардан
Яңа кеше туар, үсәр яңа халык,
Тәмен тоеп
Хакыйкатьнең, Мәхәббәтнең, Изгелекнең.
Яңа кеше туар, яңа халык,
Башланмышы булып...
башка тереклекнең...

*2003*

*** * ***

...Куркасы юк вакыт җитмәс диеп,
Күңелгә хуш булса гамәлләр,
Күңел тоя гамәл-вакыт парын,
Аңлый-аңлый үтә гомерләр...

...Вакыт
киштә булса,
вакыт – бүлем-бүлем,
Һәр бүлемдә – рәтләп гамәлләр,
Яңа туган гамәл

үз вакытын били,
Шул киштәдә бүлем әмәлләп.

Вакыт капчык булса,
Бар эшләрең – бергә, –
Сыйган кадәресе капчыкка.
Яңа туган гамәл
урын ала өстән,
Калганнары калка
...җай чыкса.

Вакыт табын булса,
Бер-бер артлы килеп,
Гамәлләрдән өем өелә.
Чәбәләнә гамәл,
Хәтта өзгәләнә,
ятмаганда вакыт көенә.

Җитми, дибез, вакыт...
Нәрсә җитми икән,
Вакыт микән, әллә – чамамы?
Вакыт җитми безгә, –
Вакыт савыт булса,
киштә, капчык, табын, казанмы...
...Куркасы юк вакыт җитмәс диеп,
Урын табып булмас дип гамәлгә,
Гамәл туа, димәк, вакыт җиткән,
Яңа гамәл – яңа киемнән.
Һәрбер гамәл үз вакыты белән –
Үз ризыгы белән туган бала кебек.
Үз вакытын киеп килгән гамәл
Өсти генә вакыт, хәл-әхвәлгә кереп.
Вакыт өсти, яңа төсмер бирә,
Яңа яссылыклар өсти, кирәксә.
Вакыт сарыф итми җайлы гамәл,
Үзен көткән шәйгә эләксә.
Килгән булса үз вакытын киеп,
Язмыш тактасыннан юллар булып,
Миңа вакыт бүләк итә гамәл,
Тибрәнүдән тибрәнүләр туып.
Олы гамәл зур киемнән була,
Шунда сыя йөзләп гамәлләрең,
Олы гамәл киеп килгән вакыт
Озынайта гомер мизгелләрен.

Куркасы юк вакыт җитмәс диеп...

*2004*

*** * ***

Ишкәкләрдә озак барырбызмы, –
Давылларда тузган җилкәннәр...
Татар иле – илме, җаны – җанмы?
Бармы таянырлык җилкәләр?

Табигатьтә әле мең матурлык,
Ай-кояшлы дөнья, афәрин,
Әмма, татар, таңга таба түгел,
Төнгә таба арбаң тәгәри.

Тамырлардан килгән татар рухы
Әллә тузган, әллә таушалган,
Татар диеп типкән йөрәкләргә

Дөнья үзе бүген сусаган.

Татар, диеп дәшәм уңга-сулга,
Җан кисәге – очкан һәр аваз,
Әйтерсең лә җилгә каршы сибелә, –
Кайда, кайда сүзгә кайтаваз?!

Дөнья бүген, татар, сине көтә,
Дөньям тигезлеге – татарда...
...Ә бүгенгә – эзлим, чыра тотып,
Мин татар, дип сыенырлык җан...
...Син татар, дип сыйдырырлык җан...

*2005*

*** * ***

Бер сүнеп, бер янган милләтем,
Болгардан киселгән өммәтем,
Биек тау башында Казаным,
Искереп яңарган өметем.

Казансу агыла офыктан,
Дулкыны кагыла күңелгә,
Татардан татарга йөгерә
Кушылып меңьяшәр Иделгә.

Иске дә, яңа да түгел ул,
Бер янган, бер сүнгән күңел ул,
Биек тау башында Казаным –
Учаклар кабызыр күмер ул.

*2007*

## *Иске Казан*

Муллахаҗи зиратында хәтер җиле,
Исә җилләр сызып-өзеп җан кылларын,
Моңлы татар көйләреннән тезмә сыман,
Казансуның рун язмалы дулкыннары.

Кушымта:

Иске Казан, Изге Казан,
Өзелмәс, сүрелмәс хатирә.
Иске Казан, Изге Казан,
Мәңгелек көй минем хәтердә.

Скиф уклары сызгыруы сеңгән сиңа,
Хан чишмәсе ургып чыга күкрәгеңнән,
Иске Казан, изге Казан – син Пайтәхет,
Изге ядкарь Алтын Урда күкрәвеннән.

Кушымта.

Дистәләп моң, телне кушып, кайнап бергә,
Туа татар Алтын Урда Казанында.
Мәңге яшәр татар, Тәңре кушып, җирдә
Тугры булса изге Иске Казанына.

Кушымта.

Татар телле Алтын Урда башкаласы
Әле дә ул яши татар йөрәгендә.
Алтын Урда кальбе булып Иске Казан
Тибә бүген Татарстан күкрәгендә.

Кушымта.

*2007*

*** * ***

Канатларны каурый-каләм иттем,
Җан җебеннән үрдем күперләр,
Йөрәк маен салдым ут-савытка,
Татар диеп әле бер дөрләр.

Татар диеп сөрән салдым миргә,
Тар-тар булып кайтты кайтаваз,
Татар үзе
    үзен югалтканда,
Татар иле кире кайталмас!

Сибелмәгән дөнья буйлап татар,
Аң-зиһенең, татар, сибелгән.
Башка берәү бишкә бүлми сине,
Син җаныңда, татар, бүленгән.

Күпме адәм татар диеп яши,
Рәшә икәнен дә белмичә.
Миллион татар рәшә була бирер,
Җаны белән «Без – ил» димичә.

*2009*

*** * ***

Гарәп канатлы татар мин,
Татар тамырлы гарәп,
Гарәптән килеш-килбәтем,
Татардан холык-гадәт.

Нәсел агачы тамыры
Сузыла күңел аша,
Мин – яфрактан
        нәсел җебе
Фазлан*нарга тоташа.

Җан булган ул, кан өстәлгән,
Яңарган төрки өммәт,
Кышкы карларны эретеп,
Күңелгә үткән аять...

...Дистәләп гасыр үтсә дә,
Җан онытмый, җан тоя.
Ун гасыр үскән күңелгә
Меңьяшәр татар сыя!

*2009*

## *Хәтер*

**1**

Хакыйкать һәм мәхәббәттән
Үрелгән безнең җиһан,
Бәрәкәт иңеп күкләрдән
Яралган җир-су, инсан.

Һәр тибрәнү, һәр талпыну
Бәйләнгән хәтер – җепкә,
Хәтер – йомгак, чолгап килә
Үткәнне киләчәккә.

Хәтер яшәтә күкләрне,
Җир – хәтер күчәрендә,
Кеше булып яши кеше,
Хәтер яшәсә генә.

**2**

Хәтер-читлек – эчке дөнья,
Хәтер-ятьмә мир сөрә,
Хәтере нык халык кына
Киләчәк таңын күрә.

Күк-җиһаннан иңгән кавем
Җир-ана кочагында,
Өзгәләнгән хәтер үзе
Төрки-татар сагында.

Борынгыдан түгел эзләр,
Эзләр Җир үзәгеннән,
Җир тарихын язып булыр
Төркиләр эзләреннән.

**3**

Барысы да элеккечә,
Котлы тау, Казансуы,
Көтә Биек тау татарның
Хуҗа булып кайтуын.

Тауларда тирән хатирә,
Табигатьтә нык хәтер,
Хәтер барда, өмет тә бар,
Татар үз сүзен әйтер.

Хәтер бар яткан ташларда,
Бар хәтер искән җилдә,
Хәтта таш та булмас адәм
Хәтер югалган илдә.

*2009*

## ***Татарга***

Татар җаны кыл өстендә бүген,
Татар иле – тузган корт иле,
Йортсыз-җирсез чаба киләчәккә –
Шундый булмыймыни шыр тиле.

Көннән көнгә кояш байый тора,
Таңнар атмый татар илендә,
Тел терәге – татар авыллары
Уты сүнгән шәмнәр хәлендә.

Былбыл теле – былбыл сайраганда,
Татар теле яши татарда,
Татар телен йотмый дөнья комы,
Татар телен йота татарлар.

Бу әрнүле сүзләр агу түгел,
Әче дару, татар, җаныңа.
Бар теләгем – яшәү уты салу
Чыңгызлардан килгән каныңа.

*2009*

*** * ***

Бармы ул халык хәтере? Бармы ул халык үзе?
Татар булу-булмау белән үзгәрәме Җир йөзе?

Илсез мурта* яши алмый, мурта көчле илендә,
Ә соң адәм кешеме соң, илен җуйган хәлендә?

Ил булганда, кеше дә бар, ә халыкка – ил терәк!
Дәүләт түгел, милләт бакый, ә милләткә тел кирәк!

Тел үсәсе бакчаларда купшы түтәлләр кирәк,
Тапталган ташлы түтәлдә «ык-мык» кына өлгерә...

Татар халкы яшәеше гүя язгы боз-сөңге,
Тамчы тама, сөңге эри, тып та тып йота эңгер...

*2009*

*** * ***

*(Акрошигырь)*

**В**акыт – тырма,
тырма тешләрендә салам, башак, камыл, тамыр...
**А**змы вәгазь, үгет, гадәт: фани дөнья казыклары –
рәт-рәт тешләр...
**К**амыл гына дияр идең: яланаяк кыр үткәндә,
чәчрәтмәсә ал тамчылар ярты карыш буйлы безләр...
**Ы**шанучан: салам-салам җанга азык, аңга азык...
салам-салам...
тарта, бүген мәгънә шул дип, тырма теше – гарпун-казык.

**Т**амырларны эләктерә вакыт-тырма,
каерса да кайсылары вак тешләрен,
**Т**әңре язган шәҗәрәдән
барлый-таба-тарта тамыр өзекләрен.
**Ы**ндыргача сызылып бара тырма эзе:
өстән-өстән, төпле-тирән, кыек-өзек, туры-төзек...
**Р**ух тамчысы: бер башакта орлык булып күпме тамчы!
киләчәге, азыгы да, җаны-каны – фани дөнья казыгында.

**М**и-ха-ха-хай! Авызлыкны чәйни-чәйни, күкрәгендә тоя-тоя
зур камытын,
**А**лга тарта (алга диеп) карт алаша (кая барсын!),
авырая-баса барган бу тырманы –
үз кырында үз хәяты, үз морады.

**М**и-ха-ха-хай! Ми-ха-ха-хай!
**И** колынның вакыт-тырма тирәсендә сикерүе,

камыт бавын тешлим диеп җилкенүе!
**Н**ишләр идең, и алаша, форсат чыкса,
кире кайту бар дисәләр колынлыкка?
**А**хры, тырма өсләреннән язмыш үзе
бармакларын теш-теш итеп салындырган
бер бармактан бер бармакка мәтәлисең,
саламмы син, башакмы син, камылмы син, тамырмы син...
**Т**амга-билге ат сыртында: колын өчен – канат эзе...
тумышыннан...
ат пошкыра: камыт эзе кушылып китә
канат эзен сыйпап искән
Чапказ* җиле агышына...

*1995*

## ***Шәһре Биләр***

Тау битендә изге чишмә – көмеш су,
Талчыбыкта былбыл сайрый, моңлана.
Хат юлыдай борма-борма Чирмешән,
Суларында Биләр таңы аллана.

Изге чишмә – күңелемә пар канат,
Мин былбыл да, талчыбык та янында,
Биләр, диеп канатланам, тын алам,
Шәһре Биләр рухы яши җанымда.

Биләр-судан сагыш җыя тулы ай,
Ай юлында Шәһре Биләр капкасы,
Алтын капка көтә булыр ачылып
Алтынчәчнең чәй суыннан кайтасын.

Тау битендә изге чишмә – көмеш су,
Талчыбыкта былбыл сайрый, моңлана.
Хат юлыдай борма-борма Чирмешән,
Суларында Биләр таңы аллана.

Көмеш тояк бәхет уя бәгырьгә,
Тулпар атта лачын-яугир – ут-яшен,
Курай-кубыз моңы исән йөрәктә,
Күңелемдә бөек Биләр шәүләсе.

*1999*

## ***Имин генә булсын татар-йорт!***

Фани дөнья – дулаган ат бүген,
Дилбегәңне, дустым, ныклап тот!
Ир-егетләр юлны салыр әле,
Имин генә булсын татар-йорт!

Дөнья түгел, без үзебез атлар,
Камчылардан юеш каеш-сырт,
Без түзәбез, без тартабыз йөкне,
Имин генә булсын татар-йорт!

Кемдер әйтә: «Беттек!», кемдер елый,
Илен җуйган күпмеләп маңкорт,
Ир-егетләр атын-исемен җуймас –
Имин генә булсын татар-йорт,
Имин генә булсын татар-йорт...

*1993*

## ***Фикерләр***

*** * ***

«Җил җилкәннән күренә...»

*** * ***

Фани дөньяда яңгырыйм дисәң:

«Җирдә тау үстергәнче –
Күктән таш төшер...»

«Җир өстендә ут якканчы –
Манарада шәм торгыз...»

Шуның киресен эшләсәң –
Ишетерсең – исәрсең!
Әмма
...бакый дөньяда – исәнсең...

*1998*

*** * ***

*Бар төрле савытлар –*
*Бал савыты – бал өчен,*
*Май савыты – май өчен,*
*Дүрт тоткалы, алпан-тилпән,*
*Гәүдә-савыт ни өчен?*
*Тәңре салган җан өстенә –*
*бер уч акыл,*
*бер уч оят,*
*Хет бер тамчы ден өчен.*

*Ә калганы – үз көчең...*

*1993*

## ***Ташларыңны барлар заман***

Время разбрасывать камни,
Время собирать камни.

*Екклесиаст*

Гомере буе таш тарата татар,
Тарих арбасына җигелеп,
Гасыр буйлап җан сугарган ташлар,
Җыясың бар, татар, иелеп...

Таш таратып,
сагыш җыяр татар,
Моң-зарларын күрер язмышыннан,
Далаларын, тулпар атын сагынып да,
Вакытымы җитмәс, карашымы –
бүгенгесен, иртәгәсен,
киләчәген сагынырга...

Чатнаттырып башны артка борыргамы,

Караргамы
ук сызгырган,
ат кешнәгән кыйблаларга?
Юк! Тотарга башны туры!
Онытмаска шәҗәрәңне,
онытмаска
ташка күчкән бөекләрең...
Тик онытма!
Вазифаң да бөекләрдән! –
Калышмыйча дәвереңнән,
үз даладай якын итү
чиксез җиһан киңлекләрен!..

...Тетрәтә дә күңелемне,
чаң суккандай,
җиһаннарны айкый, айкый
әллә кайдан яңгырый фәрман:
Туздырганны туплар заман!
Туздырганны туплар заман!
Гасырларга сибелеп барган
ташларыңны барлар заман!..

...Упкын булып күзгә күренеп,
рәшә түгел, язмыш үзе уйный сыман.

*1994*

## *Казык*

Казык кактым.
Сагынуларым,
Шатлыкларым,
Уй-хисләрем туплап
бер казыкка.
Бәйлә шунда
Хис-тойгыңны,
Моңнарыңны.
Казык тирәли бит
җирләр мул азыкка...

*2002*

*** * ***

...Бу дөньяга ялгыш кергәнмен лә,
Ялгыш кереп ерак үтелгән.
Кире кайтам, күңел җанга дәшә:
– Җитеп барган сымак күпергә,
...Кылдан нечкә таныш күпергә...

Бу дөньяны якын күрдем ялгыш,
Ялгышканмын отып рәвешен,
Соң, аңлыйм ди, аңладым ди шуны,
Ни кылыйм соң, мин дә бит кеше!
Ялгышканмын отып рәвешен...

Ник бу сорау минем башка килә,
Нинди ачыш көтә бу юлда?
Безнең тормыш, имеш, уен гына...
Уен микән әле, и Хода?
Сер ачылыр сыман бу юлда...

Ничек баксаң, дөнья шулай икән,

Ничек күрсәң, дөнья шул икән.
Безнең күңел үзе үрмәкүчтәй,
Бер тибрәнү – үзе бер килбәт.
Ничек күрсәң, дөнья шул икән...

...Безнең күңел үзе үрмәкүчтәй,
Бер тибрәнү – үзе бер килбәт.
Күңел үргән дөнья-пәрәвездә
Чәбәләнгән көек мин, димәк...
Бер тибрәнү – үзе бер килбәт...

...Безнең дөнья – күңел талпынуы,
Пәрәвезнең бары бер төре.
Әкияттәге рәшә сыннар сыман,
Кем соң вакыйг бире, кем тере?
Пәрәвезнең бары бер төре...
...Май атлауга охшаш безнең дөнья,
Бәндәләрдән җан атлагандай...
Өлгергән җан аңлап китсен диеп,
Ашыктырмый микән, и Ходай?!
Безнең дөнья – җан атлагандай...

Юк, уен да, пәрәвез дә түгел,
Ни уйласаң, адәм, үз эшең.
Ахры, берәү җирдән азык җыя,
Атланган май итеп өлешен...
Атланган... җан итеп өлешен.
Ни уйласаң, адәм, үз эшең...
...Үзең уйлап тапкан өлешең...

*1999*

### *Мин бүген кырмыска*

Бәйләнмә сүзләргә,
Сорама җавап та,
Мин бүген ишетмим, ишетмим.
Мин бүген кырмыска,
Мин бүген югалдым,
Мин үзем якын да –
Ерак та...

Мин бүген кырмыска
эчтәге дөньямда,
Әле күп төзисем, бизисем.
Соң булсын – уң булсын,
Денемә хуш шәкел,
Ни гомер эзләдем,
Ни гомер...

Чуалды эзләрем
Тузанлы юлларда,
Күпме йорт салынган нигезсез,
Эчтәге кояшны
Күрмичә, күп вакыт
түгелгән тәм өчен,
Түгелгән...

Нигезен ныгытам,
Сагыш-моң, кайгыдан
үрелгән шигырьләр нигез-таш.
Канатлы җан-рухым
гыйбадәт кылырлык
бу дөнья җайлы да,

Айлы да.

Бәхеттән чигелгән
гөмбәзгә бик ерак,
Тик күрәм кыйбламны ап-ачык.
Йа Ходa, ни татлы
үз дөньям кочагы,
Тән-гәүдә чик сыман:
Бер якта – зур дөнья,
Бер якта – үз дөньям.

Көн дә төн төзелә,
Кунаклар бик сирәк,
Бу дөнья күренми тиз генә.
Әмма бар ачкычлар,
тик эзлә, күр генә:
Бу – минем шигырьләр,
Бу минем шигырьләр...

Мин бүген кырмыска,
Юк фани тормышта,
Мин бүген югалдым үземдә.
Бу дөнья ташлары
Иң-җилкә җиңмәслек...
Сулышым тынганчы,
Гөмбәзен куйсамчы,
Бу дөнья җылысын,
Балам, син тойсаңчы...

*1994*

*** * ***

Үз-үзеңә,
эшләреңә бәя бирү,
читтән торып
күрә белү үз-үзеңне,
Җанварлардан, маймыллардан аеручы
бердәнбер шарт,
Иң зур баскыч, уйлап баксаң,
шул түгелме?

*1993*

*** * ***

Безнең шигырьләребез,
Күңел шөгыльләребез...
Шигырьгә дә бар шөгыль:
Ачылу җиңел түгел.
Эзләмә дан, җыйма сан,
Шөкер ит, бер җан тапсаң...

*1994*

*** * ***

Кеше, сине чагыштырам кое белән,
Сокландыра тирән кое суы белән,
Чыкса чыгар чылбыр чыңы буш коедан,
Мәгънә булмас хәтта өстән су коюдан.
Кешене дә кеше күрәм шуның белән –
Аң-белеме шат йөзенә чыгу белән,
Уй-фикере саф һәм чиста булу белән,

Айкалмаса, кысыла-кысыла тешләренә,
Буш коеда буш чиләктәй теле генә...

*1994*

*** * ***

Күңелем пыяладай
чәрдәкләнсә дә,
Шөкер, бәгырем ярылмады,
бәгырь бөтен...
Бөре булып күңел-пыяла кисәкләрендә
кан тамчылары, –
Йөрәк гел талпына, димәк, гел җуймый өметен...

*1994*

*** * ***

Йолдызларын коя-коя,
туып килгән көн ягына
Ай тоткалы зәңгәр касә –
Төн авышты.
Ак болытлар көзге сыман
чагылдырды кояш йөзен –
Әйтерсең лә изге бер җан күккә ашты...

*1994*

### ***Җеп очлары күп тә***

Язмыш йомгагыңның җан җепләрен
таушалдырган иде җил-давыл,
Өзгәләнгән меңләп гасаб җебе –
Ничек түздең шуңа, и авыл!..

Йомгак очы бер булырга иде, –
Бу йомгакның меңләп җеп очы,
Шигырем белән ялгыйм, күңелем белән,
Өзгән булсам берсен, ялгышып.

Җеп очлары күп тә – язмыш бер шул,
Җан-йомгакка илтә бер җепсел.
Канлы-яшьле җепләр төенләнә,
Сихәт башы булды бер әфсен.

*1994*

### ***Бәхет-сагыш – бер көянтә***

Олаулап татар сагышы...
Бәгыре – челтәр-челтәр...
Халкыма бәгырен ямарга,
Бәлки, шул сагыш җитәр?
Бәхет акылны тарата,
Канатын кага-кага...
Сагыштан адәм югалмый,
Бәхеткә чыдап кара...

Бәхет-сагыш – бер көянтә, –
Тотрыксыз... уйнап тора...
Язмасын ла интегергә,
Бер кашык сагыш сорап...

*1994*

* * *

Күңелне чигүләр бизәсә,
Күңеле чәчәктән димәгез,
Күңелгә чигелгән чәчкәләр
Бәгырьгә ямаулык –
тимәгез.

*1994*

* * *

Үз мохитен тапкан кеше –
Ярларына кайткан елга,
Бу кешене тиңлим тагын
Сөткә төшкән оеткыга...

*1994*

* * *

Тамак ялгаганда аш кирәк,
Пәке кайраганда таш кирәк...
Бутаганда гамәл тәртибен,
Авыртмыйча калган баш сирәк...

*1994*

* * *

Әйттең әни, балам, бәгырем, сүзем тыңла.
Миңа килеп ишетелде: йөгер, уйна...
Сүзең булды: балам, җаным, син бар, шөкер,
Ә колакка килеп керде: яшә, өлгер...

Үтте еллар... Әни әйткән
Сүзләр җитте колагыма,
Шул сүзләрне мин кабатлыйм
Күккә баккан оланыма...

*1994*

* * *

Кәеф,
Күңел,
Җан,
Бәгырь...
Йөрәк...

Кәеф кырылса да – бәгырь әле тыныч,
Күңел генә әзрәк болытлый,
Күңел төшсә – җанга бәрә суык,
Сызланса да бәгырь, ут йотмый.

Җан көйгәндә, бәгырь әрни, елый,
Кургаш-яңгыр тетә йөрәкне...
Белсә иде бәгырь – кискәләвен
Соңгы таянычын, терәкне...

Кәеф, күңел һәм җанны да үтеп,
Агулы ук тисә йөрәккә, –
Шунда инде бәгырь чатнап сына,

Бердәнбер юл кала, ул – ... мәрткә...

*1994*

### *Язгы уйланулар*

Зәңгәрсу төпсез гөмбәз.
Аяк астында бәллүр кәрәз...
Март кояшы кәрәзләргә бал тутыра...
Бу матур көннәр
безнең төссез ыгы-зыгыларга
ялтыравык конфет кәгазе...

*1994*

*** * ***

Галәм кешелеккә кырыс әти кебек, –
Үсеп барасыз, тәртип кирәк, дип,
Табигать-каеш белән суктырса да,
Кояшлы елмаюыннан мәхрүм итми...
Өмет юк түгел әле, димәк, галәмдә
Әлеге
Ыштан кия башлау яшенә җиткән кешелеккә...

*1994*

### *Афәт шәүләсе*

Җәя чөйде укны киерелеп...
Иңен каерып
сеңер белән бөккән җәя-зирек
Калтырады, озак тынмады.
Күкне ярып очты агулы ук,
Узып очты корыч чыңлавын...
Кыя кошы – бөркет – канатларын
Соңгы тапкыр каерып ачты да,
Угы белән бергә очкан җәя кебек,
Китереп бәрде җиргә (җир, чыда!)
Әйткән сыман: «Уян, Анам,
Ничек түзәсең?!»
Йомшак канатлары белән
җирне кочып җансыз ята бөркет,
Әйтерсең лә афәт шәүләсе...

*1994*

### *Юк тынгы*

Агачтан агачка дулкын-хис сузылган,
Без генә күрмибез, күрмибез,
Маңгайда ике күз – җиһанга ике эз, –
Күзлеме, дигәндә, күзле без.

Ә күзләр, әйтерсең аң-фәһем иләге, –
Бөртекләп ачыла бу дөнья,
Кыска шул гомерләр, соң җитә күңелгә:
Җаннардан үрелә такыя!

И кеше! Чәчкә дә табигать баласы, –
Чәчкә дә өлешле бәхеткә.
Төпчеге – син, кеше, иң соңгы җимеше,
Рәнҗетмә гөлләрне, рәнҗетмә.

Моның бар азагы,
табигать бүген дә,
Кешеләр, безне ни кисәтә!
Кисәтә табигать, димәк, бар өмет тә,
Әле бар кешелек исәптә.
Бөдрә тал өзелсә, ялварса үләннәр,
Ак каен каргаса үзеңне...
Күзләрең ач, кеше! Аңыңа кил, кеше!
Күкләрнең җитәрме түземе?

...Тамчы да таш тишә... Тик вакыт бар микән
Тамчылап җыярга акылың?
...Ә миңа юк тынгы, күңелем чаң суга...
Төш күреп елмаясың, улым...

*1994*

## *И балык*

И балык, татлы сүзең,
Телгә чыкмавы белән,
И балык, затлы үзең,
Миңа капмавың белән.

И балык, елгыр балык,
Сыртыңа юк күз атмак...
Ах, синең беркатлылык,
Ярда балык... –
и ахмак...

*1994*

## *Фән һәм шигырь*

Кодрәт алып
язгы кояш нурларыннан
яңа гына шытып чыккан,
Югарыга,
иркенлеккә башын сузган,
Чәчәкме ул,
йә бер чүпме булачагы мәгълүм түгел
үлән сыман,

Кайсы тырнап,
кайсы сыйпап
рәт-рәт санак* төймәләрен,
Кайсы балкып,
кайсы сыкрап
чыга калкып шигырьләрем...

Татлы балын кәрәзләргә
мөлдерәмә итеп җыйган
бал кортлары иле сыман,
Күңелемә оялаган моң-зар иле
җыя җанга
шигъри хисләр –
шигъри балын.

Бергә кушып ике иҗат –
фән һәм шигырь
талпынуын,
Керешүгә фән эшенә
санак-каләм алып,

Ташып чыга
күңел-кәрәз төпләреннән
шул хисләрем,
Пыялага сызылып барган калыпларга
илһам салып...

*1984 – 1995*

*** * ***

И телем, синнән файдамы,
Йә зарармы бай санлы?
Әллә син, телем, тукмакмы
Тукмаучы үз хуҗаңны?

Ни кабат хәлдән таясың,
Тешләргә салып сыртың,
Көн дә төн сүзләр сытасың,
И телем, фикер корты...

*1995*

## *Инсайт*

Табак-табак колакларын
Салган борчак күзләренә.
Ялт-йолт килә үткер пычак,
Дуңгыз –
балчык эзләвендә.

Бәйләп салгач аркасына,
мырк-мырк килде күккә карап,
тәүге тапкыр
күрде күкне –
Күрү өчен
...соңгы кабат.

*1995*

*** * ***

Сусаганда җир өстендә
чык суыдай йотым сүзгә,
Кая барыйм – сезгә чумам,
Төпсез кое – шигырьләрем.
Тын кысылса җир өстендә,
Өзгәләнсәм һава эзләп,
Кая барыйм – сезгә очам,
Чиксез күгем – шигырьләрем.
Аяк чалу батыйл гамәл,
Әмма аның булмас чиге,
Аяк чалып егылганда,
Сезгә авам, шигырьләрем.
Гавам сырхау, иман сырхау,
Тәүбә, тәүбә, йокса чире –
Кая барыйм – сезгә киләм,
Сездә дәва, шигырьләрем,

Сихәтле агу да – сез,
Әҗәлдән дару да – сез!

*1995*

*** * ***

...Ә тормыш – көтүче курае,
Көй көйли көтүләр җаена,
Юк башы бу моңлы көенең,
Гел шулай булыр күк тоела.

...Кояшны офыклар йотканда,
Җәелгәч җәйләүгә кич-эңгер,
Курай чак хәятын сагынып,
Учакта сүрелә ут-күмер.

Язмышлар чыбыркы уйната,
Шарт та шорт яңгырый әмерләр.
...Чыбыркы шартлаудан кыскарак
Язмышка үрелгән гомерләр,
Мәңге дип уйлаган гомерләр...

*1995*

## *Түрә булам, дисәң...*

Теләде бәндә
булырга түрә –
Иске түрәләр кулында иләк:
Иләктән үтте, бу – яңа түрә!
...Иләктә ята –
намус шәп-шәрә.

Түрәгә түрә буласы килгән
Үтәчәк инде фильтр-күмердән.
Иләктән үткән намус бөртеген
Сеңдерде күмер: ул артык бүген.

Инде тагын да зур хаким исә
Була түрәдән – лакмусны үтсә.
Лакмус кәгазе күрсәтә: чиста,
Намус иләнгән, шомарган, оста.

Хакимгә хаким – иң бөек тәхет,
Якында хәзер, якында рәхәт!
Намус дигәннең калмады тыны,
Намус киптергеч ялады дымын.

...Юк, бу илдә булмыйм түрә, хаким, дисәң,
Тыныч кына дөнья күреп яшим, дисәң,
Намусыңны ал да инде шул иләктән,
Бер шалаш тап, йә оя кор син келәттә,
Үпкәләмә язмышка да, дус-ишкә дә,
Уйлан үзең, кайсы бәндә кайсы мәлдә
Хаким булу морадына ирешкән ди?
...Шул яңгырда булырмы таш
коры да ди, юеш тә ди?

*1995*

## *Асылда...*

Җан, җиһан – бер тамырдан...
Җан, җиһан бер, асылда:
Тамчы да – су, ташкын да – су.
Җан – җиһан тамчысы.
Җиһан – җаннар. Барчасы.
Җан теле – җиһан теле.
Җан сүзе – җиһан сүзе.

Җен дә җан бер тамырдан.
Җен һәм җан бер, асылда.
Җен дә җан, җан да җен.
Җан әсир җен.
Җен – азат җан.
Җан – җен – җиһан...

*1995*

## ***Фикер***

Өлгергән фикер ул –
Ярмаланып пешкән
тияр-тимәс таркалырга торган бәрәңгедәй –
Чак кына кагылу белән ачылып китә дә,
Кәрәздәге күзәнәкләргә яткан бал кебек җайлап,
аңлаешлы итеп урнашып,
уңган камыр кебек күтәрелеп,
Зиһенгә – көч, күңелгә канатлар бирә...
Фикер бакчасы да шул ук бакча,
биредә дә
фикерләрнең бар төрлесе,
фикер-кыяр, фикер-кишер, редискасы,
фикер-алма, фикер-йөзем һәм башкасы.
Үсү өчен фикергә дә яңгыр кирәк, кояш кирәк.
Ныгу өчен бу җимешкә
...давыл кирәк, көрәш кирәк.
Фикер-йөзем юкка чыкмас харап булып,
Тапта ныклап, фикер булса – шәраб булыр.

Фикер кайчак ефәк сынлы умырзая –
кар астыннан калыкканы – үтә затлы,
Фикер тагын чырай сыткыч әче балан –
кырау төшеп басылганы күпкә татлы...

Бу юлларны мин, Сөләйман, язам дисәм,
Янәшәгә унлап фикер килеп җитә,
Тыз-быз килеп әле берсе, әле берсе
Сүзләр ташлый, җөмләләрне этә-төртә.
И укучым, син үзең дә сизәсеңдер,
Фикерләрнең гәпләшүен күрәсеңдер.
Җитте сезгә, фикерләрем, бит... мин хуҗа!
Сез бары тик минем башта кунак кына,
Шул юлларга сүзләр булып яткан фикер –
Инде сәлам! Тынычланып калдың, шөкер.
Чират та юк арагызда, юк юл бирү,
Әдәплерәк кыланадыр хәтта чиру.
«Әй Сөләйман, үзең ничек кыланасың,
Фикерләрең борчак сыман томырасың,
Үзләре вак, өлгермәгән, ямь-яшелләр,
Саллылары көтә чират, эндәшмиләр,
Саллылары үзең әйткән бәрәңгедәй,
Саллылары янар чәчкә аткан гөлдәй»...

Йа Хода, фетнә түгелме?
Мин хуҗа! Нокта салам!
Бу фикер булыр соңгысы һәм
Тәмам! Тәмам! Тәмам!

*1995*

*** * ***

Күңелем – давыл биштәре,
Чишмәгез, кагылмагыз.
Йөрәгем – давыл арбасы,
Ялгышып тагылмагыз!

Җан-давылдан бу өермә, –
Таш күңелләр өнәрлек*,
Җиде күккә, бишек итеп,
Җирнең үзен эләрлек...

*1995*

* * *

Инде күптән Инсан күктә –
Җир өстендә тигезләнде
кабере дә.
Ил* мичепә җанын яккан
Күпме мәрхүм
яши бирә...
күңелемдә.

...Яши берәү, дөнья сөрә, –
Күңелемдә тигезләнде
кабере дә.
Ни кызганыч:
Җан түрендә үсә зират...
күрер күзгә. Тереләрдән.

... Йолыг-тәгин**, белмим үзең,
каберең дә, –
Гасырларны үтеп исән
...җан түрендә.

*1995*

## ***Коелыгыз***

Хәле бетеп егылган ат, –
Дагалап интекмәгез.
Җанына кадак кадаклап,
Атны
интектермәгез...

Хәле бетеп егылган ат...

Күңелләр иләкләнгән чак.
Җилкән булмас – көтмәгез.
Тишкәләр генә, ялгамас –
Күңелгә сүз текмәгез...

Күңелләр иләкләнгән чак...

*1995*

## ***Тормыштан***

Сират күперләре –
Дулкын арты дулкын.
Көймә ишкәк җәйгән,
Кочып дулкын сыртын.

Дулкын уңаена

Көймә бара җайлап,
Ашыр морадына,
Булсын атна... айлап...

Янә дә бер көймә,
Алда дулкын күреп,
Ишә ишкәкләрен,
Күчәм дип җилкенеп.

Кайда соң бу көймә,
Чагылмый колачы?
Юкка чыкты көймә,
Күбек сытылганчы.

...Комга яткач төбе, –
Диңгез ачты серен:

Дулкын алды – упкын,
Дулкын арты – упкын, –
Йә тап ишкәк-канат,
Йә ят, йолдыз санап.

*1996*

*** * ***

...су өстендә әрле-бирле,
кармак чәйнәп.
Канатларга тиеп ала утлы сәнәк...
бу – ят мизгел, мин бередә – ялгыш...
ярты юлда: әллә кайтып,
әллә китеп барыш...

Тамчы-тамчы: яңгыр – су сәгате:
тамчы – сәнә.
Тәңкә-тәңкә ягылып калам
әллә кемсә ятьмәсенә.

Ятьмә чите – офык-кыршау,
белмим – ни мәл,
ни мәлләр?
Белмим – нигә? –
күк-ятьмәдә
чәбәләнәм...

*1996*

*** * ***

Күл өстендә
    шәүлә түгел –
өмет күләгәләре.
Кибеп килгән уймак-күлнең
сизелә кинәнгәне.

*1996*

*** * ***

Күңел күге тишкәләнә
хәтта
кар бөртеге аткан
шәүләдән дә...
күңел ярасына

ямаулык –
күбәләктән төшкән
күләгәләр...

*1996*

## ***Ямаулыклар***

Чигү чиктем ямау итеп, күңелем келәм кебек,
Күңелдәге чигүләрнең сәбәбен беләм кебек...

Алмаш-тилмәш ак та кара: юл – галәм серләренә,
Аклы-каралы дөньямның зәп-зәңгәр күзләренә...

Интегер идеммени соң чыптадан ямау салып,
Дөнья тишек, мән югала зиһен-дәрья чайпалып...

Елак күкне ямыйм әле, тасма кисеп балкыштан,
Аллы-гөлле елмаюдан тамчылар язсын хуштан!

*1994*

*** * ***

Авышты таң көнгә –
кояш нуры чүрәсеннән*
җәйде агач
күләгәсен.
Учак яктым төнлә –
агачтан җиргә сикереп,
биеде шомлы шәүләсе...

...ник күләгә хуш күңелгә,
шәүлә – шомлы?
аңладым шуны...

*1996*

*** * ***

Бер күләгә – кара да ул,
соры да ул,
якты да ул,
шул күләгә –
әче дә ул,
төче дә ул,
татлы да ул.
Табигать күк
бербөтен ул
күләгә дә,
ничек баксаң, шулай ята
күңелләргә.

*1996*

*** * ***

Чәй-шикәр дә, бал да түгел,
безгә татлы
сүз – татлы.
Коймак колакка май булып
тәүбәгә
тәүбә ятты.

...аңладым: без бит татарның
махсус үстергән төре:
алданып, рәхәт табабыз,
ял итәбез...
җир сөреп.

*1996*

*** * ***

Җәй.
Иң рәхәте –
җиләк исле
печән чүмәләсе күләгәсе.

Көз.
Талган җанга иң татлысы –
йөрәк кушкан кәсеп күләгәсе.

Кыш.
Мәңгелеккә ялгый
оныклардан төшкән
нәсел күләгәсе.

Яз.
Күңелләрдә шундый якты –
әйтерсең лә дөнья,
күләгәсез.

*1996*

*** * ***

Вакыт – тырма,
мин – тегермән,
икебез ике чатта:
вакыт тырмалый галәмне,
мин борчак тарткан чакта...

*1996*

*** * ***

Оныткан да ник искәнен,
игеннәрне ишә-ишә,
нидер эзләп азаплана
тынгы җуйган яңгыр җиле.

...Ә башаклар һаман яңгыр көтә...

*1996*

## *Бу жыру жыру түгелдер*

Бу жыру жыру түгелдер,
Бу жыру – бер уйлану.
Авырдыр ул тере җанга
Шәфәкъ күреп уяну...

Кызыл Чишмә авылында
Чишмәләр челтер-челтер,

Туган туфрак – йомшак юрган,
Шул юрганга ни җитәр?

Мәчет тавы текә иде,
Инде ул да басылган,
Кайтыр юллар борма-борма,
Язмыш ялгар кайсына?

Кызыл Чишмә шуңа кызыл –
Чишмәләр кызыл түшле.
Чәй суыннан авыз итсәм,
Сызлаулар кимер төсле.

Туган җирең ризык түгел,
Сайлап ала алмыйсың,
Хәтта шул гади ачышны
Гомерең буе аңлыйсы.

Мең ишетеп, мең укыган,
Сүзләргә сүз тоташа...
Ә хакыйкать кереп килә
Җир теккән күзләр аша.
Гәүдәң җиргә ник иелгән?
Хәтер капчыгы иңдә,
Авылдашлар гүргә түгел,
Минем хәтергә иңгән...

Бу җыру җыру түгелдер,
Бу җыру – бер уйлану.
Авырдыр ул тере җанга
Шәфәкъ күреп уяну...

*1996*

## *Үлән арасында имән*

Синең җаның, синең егәрлек
сыямыни фани гомергә!
Җиде буын китеп карау кирәк,
җиде буын җыйган моң-җан кирәк,
синең җанны тулай күрергә...

...Үлән арасында
чак-чак күренерлек,
үсә сыек чыбык, –
җилдән өзелерлек...
...Шушы нечкә сыннан
үсәр диеп имән,
кайдан белсен үлән –
үлән жанлы үлән.

*1996*

*** * ***

Көмеш ятьмәме ул,
әллә көмеш бишек,
тишек күңелме ул,
әллә җанга ишек:

балкыш элпә аша

кояш карый күзгә,
килә чайкаласы
ятып пәрәвезгә.

Җиләк исен җуйган
җыйнак аланнары...
шәфәкъ куермасы –
миләш-баланнары.
Гөмбә җыяр чаклар
җитеп килә безгә,
җитеп килә безгә.
Ефәк пәрдәләрен
ачып вак яңгырның
кереп барам көзгә,
кереп барам көзгә.

*1996*

*** * ***

Аллы-гөлле
чигү чигә сылу –

...күңелендә
чәчкә-гөлле болын.

Әби-карчык
салмак кына
йон эрли –

ә орчыкка
күңелдәге
эңгер
үрли.

*1997*

*** * ***

Офыктагы
кояш кыйпылчыгын
кояш этә
кызу упкынга.

Дөнья хәле – көзгедәге сурәт,
күңелләрдән килгән «уф» кына...

*1997*

*** * ***

Таш ишелә, юлны каплый...
каплый...
күңелләрне тишеп тәгәри.

...таш кынамы –
тау ишелә калсын,
тыныч җанда
хәтта... тау эри!

*1997*

*** * ***

Борын-борын заманда,
бытбылдык патша булганда
чыпчык – җырчы, былбыл – шымчы,
карга – галим, күгәрчен – залим,
саескан – сакчы, бөркет – ялчы...

Борын-борын заманда...

*1997*

* * *

...Җир йөзенә карап
Тәңре уйга талды...

Кара савытына
ап-ак кара салды.
Ак тамчылар, чәчрәп,
төнге күккә тамды.

Кара савытына
яшел кара салды.
Кара кипте, уңды,
өмет төсе калды.

Кара савытына
зәңгәр кара салды.
Зәңгәр күлләр булып
зәңгәр хыял калды.

Кара савытына
кара кара салды...

...Җир йөзенә карап,
Тәңре уйга калды...

*1997*

* * *

Чишмә тавын йөгереп үткән идем,
Хәзер шуңа
менәм
тырмашып...

Үтү белән менү арасында –
Фани тормышым.

*1997*

* * *

Хаталы сүз йә сызыла,
йә языла кабат.
Ялгыш хәреф –
күз төшкәнче
исән.

Тәңре язган Җиһан китабында
безнең дәвер бер сүз.
Адәм шунда хәреф-хата
дисәң?..

*1997*

* * *

Җиз кыңгырау чыңгылдавы...
ә җизе каян дисәң,
ләззәтле чыңны кочарлык
иртә-таң үзе икән.
Ләйлә-Мәҗнүн күзләреннән
Зәңгәр күктә нурга нур –
и кояш сине яктырта,
фәза* да шуннан хозур.
Ай сырларын сыйпап алгач,
Эри айның таплары,
нурлы сүз – айдан күренгән
җирнең ак канатлары.
Егет сүзе көмеш булсын,
Алтын сүзне кыз әйтер.
Риясыз юл – томансыз юл –
сафлык үзе күрсәтер...
ләмгә төшмәс алсу алма –
алмагач купшы җирдә,
нәкъ шунда бәхет оясы –
былбыл моңы кич-иртә.
Әнә... чү! ап-ак чәчкәләр...
хаклык бар, диде Алла.
Елтыр күзле, кояш йөзле
тамыр көткән пар алма...

...Сүтелә йомгак, тәгәри,
алга түгел, гел артка.
Улым дип уйга калам да,
ләкәтә... эти, атам...
...ыруг көен таңнан таңга
тарата җиз кыңгырау,
хисләрдән эреп җемелди
күңелгә тигән кырау...

*1997*

* * *

Бер гыйбарә –
саклыйм дисәң
күңел кырын:

акыл аша үткән ызан –
бары
маңгай сыры.

*1997*

* * *

Әлиф ләм мим.
Мәгънәсен Аллаһ үзе генә беләдер.

*Коръән тәфсире. Бәкара сүрәсе.*

Аһ, әлиф,
ләм мим...
ишетәм шул чакны –
күңелдә – Сүз туа,
сүз-коан...

*1997*

* * *

Бер түмгәге
бер гомергә тигез.

Бер түмгәген
бирмәм мең сазлыкка –
гәрчә
мең сер булыр
мең түмгәкле сазлык тирәнендә...

түмгәк түгел, –
гомер бәһасендә
хәтта
җан эленеп торган
үләне дә...

*1997*

*** * ***

*Кояш яктысында*
*шәм кабызучылар турында уйланып...*

Көндез якты.
Хисләр хискә яткан,
камашыпмы,
әллә
укмашкан.

Ябылганчы
көннең күз кабагы –
кичләр, –
нур уйната,
зеңли
...шома-яссы хисләр.

Ак нур булып
очар өчен
төнлә –

канатларың
җайлап
баш астыңа куеп
йокла көндез,
газиз
Хисем.

Сиңа бишек –
Фәһем-зиһен.

*1997*

*** * ***

Таң нурына меңнәр үрелгәндә
һич үрелмәс шул ук нурга
Хисем.

Бер таң нуры –
бер Хис.

Һәм...
киресе.

*1997*

***Чи-керт-кә-стан***

*Г.Айгига*

Трепещет знак-кузнечик
над полем и под небом!..

*В.Хлебников*

r-p-o-p-h-e-s-s-a-g-r
who
a) s w(e loo)k ...
...to
rea(be)rran(com)gi(e)ngly,
grasshopper;...
*E.Cummings*

Крылышкуя золотописьмом
тончайших жил,
Кузнечик в кузов пуза уложил
Прибрежных много стран и вер...

*В.Хлебников*

Суынып барган мич арты.
Дөм караңгы өй.
Оеп йоклый авыл йорты...
Чикерткәләр
...төш юрый.

Чикерткәләр дөньясының
офыклары – йокы...

Шәлперәйгән болын.
Әлсерәгән көтү.
Сикергәли
Чикерт-чикерт
чикерт-кәләр
сикер-гәли...

Эңгер йота
саркып чыккан
кара сыер сөтен...

*1997*

## *Урта диңгез – Олы диңгез*

Урта диңгез – Олы диңгез –
Ияр тигән кыргый ат,
Таныдыңмы мин – кыпчакны,
Хәтерең, диңгез, яңарт!

Унбиш гасыр син дәрьяга
Гомермени – бер сәнә...
Кораб-ияр максат түгел –
Күрешер өчен сәбәп.

Ташка катып исән калган
Мин – алмагач орлыгы,
Тере Хәбәр булып шыттым
Мин – Атилла оныгы.

Алмагачка тулы булган
Алтай – Диңгез арасы,
Хәтер күзәнәкләрендә
Ап-ак чәчкә дәрьясы...

...Күк белән дәрья тоташкан,
Күбеккә баткан кораб,
Пәрәвездәй төн пәрдәсе
Корабны алган чолгап.

Йолдызларга тиеп китә
Кораб, суда йөзсә дә,
Дулкын саен бер талпына
Йөрәк, ничек түзсә дә.

Җидегән йолдыз чалкан ятып
Күктән безне күзәтә...
Әйтерсең лә Тәңре үзе
Чаткы сала үзәккә...

Шомлы дәрья, шомлы гүләү,
Диңгездә – сыңар саңак –
...Әни, синең учларыңда
Бара сыман бу кораб...

*Урта диңгез, Кальяри-Рим*
*1997*

*** * ***

Бөркет – бөртек-бөртек,
Берәм-берәм.
Карга – тамга-тамга,
Төмән-төмән.

Ялгыз карга –
шом, томан...
Бөркет төркем-төркем –
йә төш,
йә ахырзаман...

*1997*

*** * ***

Төнге күктән шәһәр –
Мәрҗән тулы, асыл,
Чиккән түбәтәйдәй
Җем-җем килә Марсель.
Очак канатына
Тиеп ала сыман
Ак-каралы дөнья,
Ак-каралы инсан.
Дөньяда бармы син,
Әллә килерсең бер, –
Марсельгә барыбер,
Марсельгә барыбер...
Урамнары текә,
Таудан эңгер төшә,
Диңгез дулкынында
Җанын тирби мишәр.
Дөнья җилен җигеп
Уза фани гомер –
Соңгы кабатмы бу,
Әллә килерме бер?..
...Миңа да барыбер,
Миңа да
      барыбер...

*Экс-ан-Прованс, Франция,*
*1997*

*** * ***

Күңелдә сүз –

суда йөзгән балык.

Сүзнең
телгә чыккан мәле –
ялтыравык кармак кабып
ярда яткан
балык хәле.

*1997*

## ***Мин – минсез дөньяда***

Мин – минсез дөньяда...
Җирән карсак көчек
килә очып,
үз җиленнән
аяклары чәбәләнә,
үз ләң-ләңен
таккан койрыгына.

Чәйнәр иде
минем ботны –
әмма...
Тешләп кара
бу дөньяда
юкны.

Рәшә булып
үтте минем аша
ала-кола телле
чуар төркем.
Минем аша
шау-шу дөнья
үтеп бара,
Әйтерсең лә
челтәр аша үткән
төтен...

Кайсы мизгел
мине
рәшә йотты?
Йә бу дөнья
үзе рәшәме?
Яңгыр җиле иссен
тетеп-йолкып –
Гарасатның
үзен
дәшәмен!
...Кемнең әле
күргәне бар
рәшәләрнең
Яшен утларында
яшәгәнен!..

*

...Шатлыкка сөялдең –
бармы иңе?
Кайгыга иярдең –
бармы чиге?..

Шатлыктан атындың –
кайгы – күсәк.

Кайгыдан басылдың –

шатлык – түшәк.

...Кайгылар
төренгән
шатлыкка.
Шатлыклар
төрелгән
кайгыга...

...Дүрт яклап
чит җилләр
кайда да...

Адәм-корт
кимерек алмада...
...Галәм-йорт
нәфескә чорнала...

...Мин – минсез дөньяда.

*1997*

*** * ***

**1**

Шатлык – якты –
...тәмуг учагыннан
чаткы.

Канун каты:
күңелдән ташыган
шатлык –
кочакка сыймаган
чаткы –
тәмуг уты.

**2**

Кайгы – сары –
ботагында кипкән
җәннәт алмагачы
яфраклары.

Өзелеп,
җиргә ятканнары –
сары-соры-кара...—
орлык көткән өмет тавы –
яфракта яфрак-яфрак...
шатлык таптаган,
кайгы күперткән
...туфрак.

*1997*

*** * ***

Йодрыкларым, йомшап,
канат булды,
пакь хисләрем –
манма моң гына.
Олы юлда Чишмә сукмаклары
вәзен булып керә җырыма.

*1997*

* * *

Өелмәсә ватык хатирәләр,
фатихасын бирсә туганнар, –
тагын синнән, Тәңре,
нәрсә көтим...
күңелемдә сүзсез догалар...

*1997*

* * *

Җиһан берни түгел, –
Олы бер көй.
Дөнья берни түгел, –
Олы бер моң.
Гомер берни түгел, –
Гади бер шәй.
Адәм берни түгел, –
Гади бер җөй.
Мәңгелек көй умырткасы –
Мәңгелек Тын.
Мәңгелек ТЫн.
Мәңгелек ТЫН...

*Әнкара*
*1997*

* * *

– Язганың – байтак,
Сызганың – байтак,
Ник сирәк язмаң
Улыңа атап?

– Күңелдә – туфан,
Бәгырьдә – вулкан.
Бик юка дивар,
Бик нечкә кыллар.

Сызырга куркам...
Тияргә куркам...

*Марсель – Франкфурт*
*1997*

* * *

Кыяларда
бөркет оялары,
күрим дисең –
бармы канатларың?
Язмыш чөйсә күккә, күрерсең дә,
ябылмасмы
яшәү кабак*ларың?

*1997*

## *Үз илемдә*

Ярдан ярга саллар акмый, акмый су,
Күпер салып чыксаң гына чыгасы.
Ай, өзелә бәгырькәем кыллары –
Үз җиреңдә Сак-Сок булу ямансу.

Үз җиремдә, үз илемдә мин ятим,
Ил туфрагы – юл тузаны, нишләтим?
Татар моңы өзгәләнә җан эзләп,
Татар җаны юл чатында – рух эстәп.

Ярлар текә, җил тынгысыз, юл ерак,
Текә ярлы дәрьяларны кем үтәр?
Сак-Сок булдык туган җирдә йөрешли,
Кайда оя безнең җанга, кем әйтер?

Текә ярдан юллар илтми офыкка,
Күз күреме араларда – тау гына.
Язмыш сыный, кем үтәр дип дәрьяны,
Ак-каралы дөнья җәеп алдына.

Текә ярдан юллар илтә күкләргә,
Ага сулар, ишелә яр, җил тына.
Йөрәк кенә килешалмый язмышка,
Ярдан ярга юллар эзләп талпына.

*1998*

* * *

Орлык холкын белә, диеп,
Хәтта күккә, дип, терәү,
Тегермәннән чәчүлеккә
орлык сайлаткан берәү.

Таш тәгәрмәч, тимер тешләр...
Мескендер кем оныткан –

...бу –
те-гер-мән!
Ул он тарта,
ул сайламый орлыкка...

*1998*

* * *

Тун-толыплар кияр идем, –
Юк суыгы
суык сыман.
Челтәр күлмәк кияр идем, –
Юк җылысы
җылы сыман.

Язылганда язар идем, –
Языла да,
язылмый да.
Язылмаса, язмас идем, –
Язылмый да,
языла да.

Ни – вәзене,
Ни – рифмасы,
Әллә салкын, әллә җылы.
...Ахры күңел тулып килә –
Әле көлә,
Әле елый.

*1998*

*** * ***

Акка кара язасыңмы,
Карага ак сызасыңмы –
Бу синең эш, и кеше!

Кушма гына карага ак,
Акка кара кушма гына.
Бу – Тәңре-Хода эше...

*1998*

*** * ***

Язмыш гүя патефон.
Адәм – аның энәсе,
Ә тормыш – тәлинкәсе.
Энә юкта: тәлинкә – такта,
Тәлинкәсез: энә – мәнсез.

*1999*

*** * ***

Адәм – язмыш каләме,
Акыл җитмәс галәмәт.
Язмыш кулы да – адәм,
Язмыш колы да – адәм.

*1999*

## *Тән һәм җан*

Күбәләкләргә сокланып, кушылып очар идем,
Күбәләкләр белән бергә җирләрне кочар идем,
Җирләрне кочар идем дә җилләрдә йөзәр идем,
Курчак булып кыш чыксам да, үкенмәс, түзәр идем.
Кемнәр белсен, кемнәр әйтсен бу дөнья агышларын,
Кеше белән күбәләкнең бердер шул язмышлары.
Күбәләк элек курчак ул, ә кешедә – тән-гәүдә,
Димәк, җан да күбәләктәй очар әле бер мәлдә.
«Күбәләк» җырын яраттың, белми идем сәбәбен,
Әти, хәзер аңладым ла, шул хакта бу каләмем.

Ә дөньяны
аңлап булмый аны,
Бу дөньяны һәркөн ачасы, –
Эшне ташлап була,
кешеләрдән – качып,
Үзеңнән соң кая качасы?!

Нәрсәгә дип бирелгән соң
Безгә бу баш? –
Әсирлектә тотаргамы хыялларны?
Йолдызларны узып очмасын дип күккә,
Канатланган уй-фикерне тыяргамы?
Нәрсәгә соң безгә бу йөк – гәүдә?
Әллә инде йөрәк-бавыр-үпкәләргә
оя өчен?
Ә бу йөрәк, бавыр, үпкә, күкрәк –
Әллә инде җан-моңымны

Тән-гәүдәгә җигәр өчен?
Күкрәк читлегендә
самими җан – әсир!
И талпына бу юләр җан әллә кая,
и тынгысыз!
Әйтә гәүдәм: «Син гомергә миндә – исәр!
Бергә булу минем белән синең язмыш –
котылгысыз!»

Гәүдә белән җан көрәше һич тукталмый,
Гәүдә-курчак йоклаганда, җан йокламый, –
Күреп кайта сагынулары тарткан җирен,
Төшләремә алып кайта
мәңгелеккә очар җирен.
Килә вакыт, җан талпына – җан иректә,
кысасыз җан!
Шундый иркен, шундый тыныч!
Нигә әле очмаганмын әсирлектән әллә кайчан!..

Бу уйлардан арынасы иде, –
Мин бербөтен: тән вә җаным,
Кан юллары җан юллары берлән,
Җан кылларын сыйпый каным.
Ә дөньяны аңлап булмас аны,
Бер дөньядыр һәрбер тамчысы,
Мизгелендә дөнья туа, мизгелендә үлә,
Тән-җан бергә шул дөньяда гизә,
Бу дөньяны мәңге ачасы...
Миңа кадәр, миннән соң да шулай,
Тән-җан бергә булса, бу дөньяда – кеше,
Бу хакыйкать гади, кеше – дөнья төше.
Талпынсак та, бирелмәгән безгә, –
Кешегә юк үзен ачасы,
Кешеләрдән, дус-ишләрдән китәм, –
Үземнән соң кая качасы?

Аны белми тәнем, белми каным,
Аны белә үз сәгатен көткән әсир җаным...

*1991 – 1993*

## ***Нәфес***

*(Цикл)*

Нәфесең тый, диләр –
юккамыни,
Кыргый айгыр – нәфес, бәхәссез!
Дилбегәңне ныклап тоталмасаң,
Җаның күктә,
сыктау мәгънәсез!

Нәфес тыю –
Читкә кагу түгел,
Ул – тыелу, белү чик-чама...
Нәфес үзе –
Кыргый атлар ише,
Буйсындыра алсаң, аргамак.

Нәфес тыю –
Чама белү, дидек...
Тормыш җилеге дә шул нәфес,
Канны – рухка,

Рухны аң-зиһенгә
Тоташтыра нәфес салган эз.

Кеше – бишек,
Нәфес сиртмә икән
Тәңре салган сантый җаныма,
Гомер буе
Нәфес тирбәүләре
Тормыш тәме булып сарыла.

Нәфес – теләк,
Ашка нәфес кирәк,
Куәт керсен дисәң каныңа.
Туйдым диеп
Читкә этмә икән,
Сиңа дигән өлеш барында.

Нәфес – пычак, нәфес – кылыч кебек,
Кисә, турый – эше шул ласа,
Гәүдә ризык, кием күрмәс иде,
Фәлән кадәр нәфес булмаса.

Нәфес – теләк,
Җырга нәфес кирәк,
Җыр-биюдән ныгый рух-күңел,
Матурлыкка,
Нәфислеккә нәфес,
Шунда гына биек җан күгең.

Нәфес – теләк
Аң-белемгә булса,
Зиһен күгең җитәр гарешкә,
Нәфесеңне тыйсаң
Тынын буып,
Исемең дә булыр фәрештә.

Фәрештәгә сүз әйтүем түгел,
Абруе да аның югары,
Әмма, кеше, кеше булып тугач,
Үтәсең бар кеше юлларын.

Бәргәләнеп дөнья читлегендә,
Нәфес сиртмәләрдә тибрәнеп,
Җан җепләрен эрли-нечкәртәсе,
Йомгак әзерлисе бар әле...

*2003*

*** * ***

Мәхәббәтне нәфес-субай тота,
Субайларсыз дөньяң ишелер,
Ә Хакыйкать – нәфес-субайларның
Кеше итүчесе кешене.

Җәһәннәмнән алып җәннәткәчә
Сузылган юл нәфес кылыннан,
Тәмуг очы кылның – чәнечкеле,
Җәннәт очы – кояш нурыннан.

Сират күперенең үзәгендә –
Хакыйкатькә нәфес – кыл булып,
Бер дөньяңнан бер дөньяңа үтү
Янә шул ук нәфес аркылы.

Агудан да дару ясап була,
Дарудан да агу чыга ла,
Агу белән дару аермасы
Нәфес бизмәнендә сынала.

Юк яманы, юк яхшысы нурның,
Нур җылыта, тишә, кисә дә,
Нәфес тә шул – кояш нуры кебек,
Кайчы булып кайчак
киссә дә.

Бар дөньяңны, адәм, нәфес тота,
Тәңре салган нәфес – гомерлек,
Нәфес кылы юкка чыккан мәлдә,
Әйтеп өлгер соңгы гозерең.

...Мин сорамыйм холкың нинди диеп,
Мин күз салам – нинди нәфесең?
Нәфес кочагында син бер бөҗәк,
Нәфес-өмет белән кешесең...

*2003*

*** * ***

...Нечкә кыллар
тирбәткәндә тәнне,
инде җанга рәхәт дигәндә,
нәрсәнедер онытмадым микән? –
Тырнап үтте фикер чигәдән.

Җиде күктән
җиде төсләр эзләп,
Җирдән Күккә юллар сузганда,
Җирдән китеп Күккә җиталмыйча
Азапланмыйм микән ызанда?..

Күктә ризык – Җаның теләгәне,
Җирдә ризык – Нәфес ризыгы,
Күңел генә
бәргәләнә, сайлый, –
Ахры, шулдыр Күңел азыгы...

...Күктә көткәннәрдән
күптән көткәннәргә
кайтумы ул,
әллә төшүме?
Кешеме мин
җирдә талпынганга,
күккә атылганга,
кешеме?

Нәфрәтләнеп тулу
куык булып,
ут-ялкынга охшап ярсулар –
күк катына сыймас кабырчыкмы,
әллә шулмы җиргә кайтулар?..

Күкләр биек, иге-чиге булмас,
күперләре берьяк юллылар,
менәм дисәң – менү өчен юллар,
төшәм дисәң, меңләп юлы бар.

...Әмәлләрен шуның
эзләп уза гомер,

тау юлында – гомер-кулазак*...
Тәннән тәнгә күчеп йөргән кебек,
менеп-төшеп йөрү – һай, газап...

*2003*

*** * ***

Нәфес – сөю,
Нәфес – ялкын,
Нәфес ул – кош
Күңел күгендә.

Нәфес – нәфрәт,
Нәфес – тәмуг уты,
Нәфес – елан
Ташлы күңелдә...

Нәфес ул – су кебек,
Боз һәм пар уртасы,
Суытсаң, боз була,
Җылытсаң, пар чыга.

Нәфес – кодрәт тә ул,
Нәфес ул – дәрт, дары,
Күкләргә күтәрә
Аның бер микъдары.

Адәмне кол иткән,
Комсыз җан, җансыз таш –
Шул нәфес сәбәпче –
Үлчәмең кәй булгач.

Нәфескә бар оя –
Ул – ышык куеның.
Нәфес ул чүпрәсе
Күпергән уеңның.

*2003*

*** * ***

Күңел тишкәләнсә, ямау салам,
Ямаулыкка – бишек көйләре,
Нәфес ямый күңел тишекләрен,
Нәфес-җилем тота җөйләрен.

Үзәк өзелгәндә, нәфес кылы тота,
Ялганганчы үзәк кыллары,
Сыңар канат булып күңел талпынганда,
Пар канатка нәфес – сыңары.

Нәфес бетсә, теңкә корыйдыр ул,
Тияләрме, юкмы – барыбер.
Теңкәләргә тигәч, ярсый идем,
Хәзер аңлыйм –
...әле бар гомер...

*2003*

*** * ***

Минем көймә янә дулкыннарда,
Нәфес җиле этә көймәне,

Инде җилкән кирәк булмас дигәч,
Күңел-дәрья әллә нишләде.

Әллә кайдан дулкын килеп бәрде,
Әллә кайдан чыкты җилләре,
Инеш идең, кыйблаң диңгез, диден,
Инде кайда, күңел, мөнбәрең?

Син тынгысыз, күңел, ә җан сыкрый,
Йөрәккә дә тия авазы,
Яхшыгамы, юкмы диеп сорый,
Янә сипләү нәфес арбасын.

Яхшыгамы, юкмы? – Җан чайпала,
Күзе ачык, күрә ал-артны,
Әйдә, күңел, нәфес җене тигәч,
Киереп бак янә канатың.

Тынычлыкны ташлап дулкыннарга,
Ияргәнсең икән нәфескә, –
Нәфес булсын – күңелеңдә көймә,
Көймә була күрмә нәфескә.

*2003*

* * *

Дөнья читлегендә,
Зиһен читлегендә,
Күңел читлегендә,
Нәфес читлегендә –
нәфес, күңел, зиһен.

Дөнья читлегендә,
Зиһен читлегендә,
Күңел читлегендә –
нәфес, күңел, зиһен.

Дөнья читлегендә,
Зиһен читлегендә –
нәфес, күңел, зиһен...

Җиһан читлегендә – Дөнья...

*2003*

* * *

Кабаланма кыйбла күренми дип,
Кыйбла юлы аклы-каралы,
Йөрәк уты сүрелә барган саен,
Караңгылык каплый кыйблаңны.

Кыйбла юлын шуннан танып була –
Күңелеңә тула яктылык,
Җан куышын җаның җайлы тоя,
Йөзеңдәчә фикер сафлыгы.

Маңгай күзе кыйбла таный алмас,
Күңел күзең әйтсен кыйблаңны,
Кыйбла юлы кыска – фикер кебек,
Фикер кебек озын, бормалы.

Кабаланма кыйбла күренми дип,
Яз килмичә, яфрак күрмәссең,

Кыйбла да шул яшел яфрак кебек –
Яз китерә белсәң, күрәсең.

Каббала* да кыйбла, Кәгъбә дә ул,
Туган йортың, туган нигезең,
Кем бәхетле – дүрт тарафы кыйбла,
Башкаларга кыйбла – ул үзе.

*2003*

*** * ***

Яшел үзән күренмәсме диеп,
Менгән саен мендем югары,
Ак болытлар юлны каплаганда,
Ак хыяллар булды юлларым.

Яшел үзән – чәчкә тулы дөнья,
Яшел үзән – синең күңелең,
Яшел үзән – минем эзләгәнем,
Күзләгәнем минем өзелеп.

Яшел үзән күренмәсме диеп,
Таудан тауга күчеп эзләдем,
Тау очлары күккә өндәделәр,
Яшел үзән көтте күзләрем.

Яшел үзән, син ачылдың кинәт,
Инде сине күрмәм дигәндә...
...Тау елгасы алып китте... түбән,
Гомер буе көткән үзәнгә.

*2003*

*** * ***

Атларга йөгән кидермим,
Йөгәнсез атлар оча,
Бир ирек! Атың-канатың
Күкләр гизеп кайтачак.

Атлар кайта су буйлатып,
Җил җилешә көнләшеп,
Атлар йөри гасырларда
Ак бәхетләр өләшеп.

Атларның тып-тып басуы
Тимер дагадан микән?
Тып-тып итеп, саный-саный,
Гомерләр ага микән?

Ыргыла атлар җиңүгә,
Ярсулары маңгайда,
Мин дә бит күптән бәйгедә,
Үзем – ат, үзем – җайдак.

Атлар уйный болыннарда,
Гомердән гомерләргә,
Чирәмгә түгел, эзләре
Уела бәгырьләргә.

Тулпар атның канатлары

Әйтерсең көмеш кочак,
Атлар белән безнең җаннар
Тоташкан борынгыча.

Таң алдыннан тояк эзе
Чолгана көмеш чыкка,
Тояк тавышы күңелне
Кайтара балачакка.

Атларга карап кычкырам:
Атларым, әй-һәй-һәй-һәй!
Тояктан чыккан аваз да
Күңелгә яткан сүздәй.

*2003*

*** * ***

Иңнәреңә офык салган килеш
Барып була бары йолдызларга...

*2003*

*** * ***

Җирдә яшим, йөрим дисәң –
Сал җилкәңнән офыкларны...

*2003*

*** * ***

Коедан су алмый торсаң, саега бара кое,
Мүкләнә бара бурасы, саргая кое суы.

Хәтта күкләр түбәнәя, очмый торсаң беравык,
Күк катламы иңгә төшә, тормасаң канат кагып.

Тоныкланып кала дөнья, җуела бизәкләре,
Нечкә кыллары өзелеп, тартылса үзәкләрең.

Яшәешнең тәме бетә, хис яшькә әйләнмәсә,
Күңелләрнең тибрәнүе бәгырьгә бәйләнмәсә.

Нәфес күге – ябыштыргыч, орынма димәдемме?
Тишсәң тишәрсең ул күкне, очлап фикерләреңне.

Саегая акыл күле, йөзеп-чумып тормасаң,
Читтән торып балык тотып яшәрмен дип уйласаң.

Зиһен, кайда канатларың, таркалдымы җилләрдә?
Җиде кат күктә очканың калды сагынып сөйләргә.

Диңгез булып тибрәнүләр бар иде түгелме соң,
Уй-фикерләр уянгандай, шәт әле түгелдер соң.

...Ә бүгенгә диңгез димим, күл дә түгел ул хәтта –
Сазлык суы тибрәнүе халәтен хәтерләтә...

*2003*

* * *

Җирдә чакта адәм вазифасы:
Әрле-бирле килеп
Җирне күккә тегү...

Тегелгән җир күктән аерылмас...

Сирәкләргә әмма насыйп кәсеп:
Җан җепләрен тетеп, эрләп, үреп,
Җирне күккә
Бишек итеп элү...

Җир-бишектә үскән җан югалмас...

*2003*

* * *

Җан күгендә очар мизгелләрдә,
Канатларны салып,
Җирдә баскыч ясау –
Җирдән күккә күтәрерме
Бер-бер кемне?

Баскыч ясау
изге гамәл үзе,
Әмма баскыч канат түгел бит ул.
Баскычларны күпме бастырсаң да,
Якынайтмый
күкнең үзен бит ул.

Акыл әйтә: үзең бул биектә,
Күктән түгел, күккә сал эзең.
Син талпынган чалым өскә илтсә,
Һич булмассың анда берүзең.

Баскыч түгел, ачкыч кирәк җанга,
Ачылган җан кирәк җирдә дә,
Җан ачылса, күңел канатлана,
Бәгырь тынычлана җилдә дә...

Тик... барыбер баскыч ясый Кеше,
Безне Күккә якынайтам диеп,
Тынычланмый, кайчак сыкранса да,
Баскычлары яшеннәргә тиеп.

Баскыч ясый Кеше, үҗәтләнеп,
Җиргә төшеп, канатларын салып,
Баскыч көтеп карап торучылар
Җылыналар
...каурыйларын ягып.

*2003*

* * *

Йолдызлар караңгыда күренә...

*Татар радиосы. Реклама бүлеге*

Караңгыда чыра кабынса да,
Йолдыз булып оча чаткысы,
Чаткыларга дәррәү кул чапканда,
Кем искәртер кояш яктысын?..

*2003*

* * *

Яхшыдан баш тартмыйлар.

*Татар радиосы. Реклама бүлеге*

Эткә – хуш исле печән,
ә кәҗәгә – итле-майлы сөяк...
...Яхшыдан баш тартмыйлар.

*2003*

* * *

Йолдызлар караңгыда күренә...

*Татар радиосы. Реклама бүлеге*

Каплагыз кояшны, җәегез төн-пәрдә...
...Йолдызлар күренер шул мәлдә...

*2003*

* * *

Караңгыда йолдызлар яктырак күренә...

*Татар радиосы. Реклама бүлеге*

Караңгыда чаткы да йолдыз булып күренә...

*2003*

* * *

Бәхетме? –
аяк тавышларын узып,
әни безне каршыларга чыккан...

Бәхетме? –
әни белән без бишебез,
оныклар да шунда, туган йортта...

Бәхетме? –
әниемнең елмаюын күрәм
самавырның җиз йөзендә...

Бәхетме? –
дәшә алам минут саен бүген
әни диеп җир йөзендә...

Бәхетме? –
әнинең дә, үземнең дә
улым диеп дәшкән чаклар әле.

Бәхетме? –
озын гомер, саулык биреп,
сине, әни, Тәңре саклар әле...

Бәхетме?
әнинең
...сүгүе, әрләве,
бәрүе, тетүе, дәшмәве...
...бары тик яшәве, яшәве...
бик озак, бик озак яшәве...

*2004*

* * *

*Тәкәбберләнүчеләргә:*

«Кикрик баш белән бергә күтәрелә.
Баш күтәрелгәнче кикрик күтәрелсә,
ятып калган баш пычактан үткәнне көт тә тор!»

* * *

*Картайдым дип зарланучы картларга,*
*мин әле яшь дип масаючы яшьләргә:*

Алда күпме гомер яшиселәрең
әлегәчә күпме гомер яшәвеңә бәйләнмәгән.

* * *

*Мактанчыкларга:*

Койрыгыңны бәйләп куй син билеңә,
Һичьюгында, чүлдә генә күтәр,
Агач-куак булган җирдә куркыныч,
Ботак-мазар тиеп харап итәр.

*2006*

* * *

Янтра – җантра – җантора – җан тора...*

Акылдамы акыл?
Юк, җанда.
Зиһендәме акыл?
Юк, җанда.
Фикердәме акыл?
Юк, җанда.

Шашып аккан акыл
юк җанда.
Зиһен таркаулыгы
юк җанда.
Фикер чуалуы
юк җанда.

Җанны телә
Нәфес, нәфес, нәфес...
Җан тетелә фикер-тирмәндә**.
Җан сызыла, әрни, улый, улый...
Үкенгәндәй миңа иңгәнгә...

*2006*

* * *

Мантра – Мәнтора – Мән тора...
Аум мани падве хум!

*Санскритта язылган*
*борынгы сакраль әйтем*

Саум* Мәнни Пат Фәһем!
Саум Мәнни Пәт Фәһем...

Ал, Тәңрем, бездән сауым,
Камка сыердан савым,
Камка сыер Илаһи,

Саумлы булсын кавем.

Бир, Тәңрем, безгә саум,
Мантыр борынгы кавем,
Кайтыр таралган зиһен,
Мән-мәгънә иңгән саен.

Саумның күктә очы, –
Күк капусы ачкычы,
Ул ача да, ул яба да,
Күз ачып ябылганчы.

Пат ул – бертигез сөю,
Пат, димәк, килә көе,
Тигезлектә, сөюдә
Ярала гармония.
Аң-фәһем, ефәк бишек
уй-фикер, зиһен өчен.
Мән белән үсә фәһем,
Иңдереп саум көчен.

Саум Мәнни Пат Фәһем!
Саум Мәнни Пәт Фәһем...

*2006*

### ***Өч бишек***

Тантра – тәнтра – тәнтора – тән тора...

Тән – тәм, тән – бәдән,
Тән – пәрәвез, тән – эргә.
Тән – сулыш тулы куык,
Тән – биләү бер гомергә.

*****

Тән – яр, тән – ярлар,
Тәнсез җан – ярсыз елга,
Тән – бишектә җан – тормыш,
Җан – рух – йөзем, тән – колга.

*****

Тән – тыш, тән – куыш.
Эчтән сулыш куышы,
Тыштан – сулыш дәрьясы –
Тәңре-Җиһан сулышы.

*****

Тән – рух – мән – бердәм,
Тәнсез акыл –
сантый җан.
Тән-нәфескә чолганып,
Көч җыя җирдә җиһан.
*****
Тән – рух – мән – адәм,
Җан иңеп – өммәт башы,
Тәнсез рух – таусыз вулкан,
Рухсыз тән – мунча ташы.

*****

Тән – рух – мән – бергә,
Бер гомергә – бу вәзен.

Мәнсез рух – ут-өермә,
Рухсыз мән – кылыч йөзе.

*

Тән – рух – мән – мәдәк*,
Җан тибрәнгән өч бишек,
Өч бишектә тибрәтеп,
Җан асрый җирдә кеше...

*2006*

*** * ***

Әйе, татар, туу,
яшәү,
үлү,
Булу-булмау – Аллаһ кулында.
Әмма ничек булсын дәвамың,
Татарлыгың сүнсә улыңда?

*2007*

## *Ни әйтәсе кала?*

Бу адәмгә
ни әйтәсе кала –
Әверелә бара күсәккә.
Аң-фәһеме үткер пычак булып
Җирне телә кисәк-кисәккә.

Бу халыкка
ни әйтәсе кала –
Әллә халык, әллә чытырман,
Җыруларда түгел, бит кайчандыр
Халык үзе булган карурман.

Бу дөньяга
ни әйтәсе кала –
Кочак иткәч нәфес упкынын?
Кем канатлы – карыйк бер талпынып,
Җил-җай итеп дөнья шаукымын.

Бу галәмгә
ни әйтәсе кала –
Галәмдә юк зар да, рәхәт тә,
Галәм-Тәңре безне Адәм иткән,
Бер сүзем юк гайре рәхмәттән...

*2007*

*** * ***

*М.И.Мәхмүтовка*

Эх, мин яшь егет,
Калтырый куллар,
Үтәдер гомер,
Үтәдер еллар...

*Халык җырыннан*

Үтә еллар, уза гомер, –
Галәм кушкан хәрәкәт,
Чама белеп канат каксаң,
Хәрәкәттә – бәрәкәт.

Кемгәдер – гомер бер мизгел,
Кемгә – һәр мизгел гомер,
Күмердән үскән гомер бар,
Гомердән калган – күмер...

Әдипләр бар, канат кагып,
Җил-давыл чыгаручы,
Бар остазлар, канат тагып,
Күкләргә очыручы.

Берәүнең газиз халкына
Шәм даулап китә көче.
Бар шәхесләр – милләтенә
Үзен ялкын итүче.

Яшьлек үзе калтырану,
Тоташ тибрәнү – гомер,
Син бәхетле, картлыгыңда
Калтырамаса бәгырь.

*2007*

## *Дүрт ат*

Өч ат җигеп олы юлга чыктым,
Берсе – нәфес атның, кыргый байтал,
Икенчесе атның – рух-аргамак,
Күккә чөеп җиргә бәрде байтак.

Өченчесе – зиһен... канатлы ат,
Еллар үтте чабып, ат ныгыды,
Атланалмый атка изаландым,
Әзме төштем сырттан мин егылып.

Нәфес-атка – камчы, тимер дага...
Рух-атыма – көмеш чишмә чыңы,
Зиһен-атка – салмак җиһан җиле –
Өч ат тарта сәфәр чыгучыны.

Дүртенче ат – һич күренми күзгә,
Дүртенче ат – дүртенче кат – мәнөс*.
Дүртенче ат җиңел атландырмый,
Булу кирәк һәр минутың дәрес.

Тузмый торган нәфес арба кирәк,
Ай-кояшлы рухта типкән йөрәк,
Күкне иңләп, нурга сыйган акыл...
...Мәнөс атын җигә белгән сирәк.

Атлар җигеп олы сәфәр чыктым...

*2009*

## *Монологлар*

*Нәфес монологы:*

«Миңа, миңа, миңа гына
алтын-көмеш, асылташлар,
Берне, бишне,
...юк, унбишне,
юк, юк, күбрәк,
санап түгел, учлап, көрәп...
Рух белән мин, нәфес, килештерәм,

Чүпрә булып рухны кабартам,
Акыл гына җанга тия, кисеп,
Акыл гына миңа арата!»
Нәфес үзе чама беләмени!
Дилбегә дә йөгән – аңа чит!
Рух-дилбегә бирә юнәлешен,
Акыл-йөгән куя аңа чик.

*Рух монологы:*

«Мин – өермә, буран, бозлы яңгыр,
Мин – аҗаган, яшен, ут-көлтә.
Бер мизгелдә җанны утка салам,
Шул мизгелдә җанны боз итәм.
Нәфес бирсә дәрман,
мин дәрт бирәм,
Мин канатлар тагам кешегә.
Мин күтәрәм күккә сине, адәм,
...Йә тәмугка сине төшерәм».
Рух ул җилкән язмыш корабына,
Җилкәнгә җил – нәфес куәсе,
Дөнья гизгән адәм-корабны
Акыл белә кая куасын.

*Акыл монологы:*

«Миннән өскә – зиһен патшалыгы,
Мән-мәсләктә минем таяныч,
Фикер тегә дөнья катламнарын,
Тегелмәгән дөнья – аяныч.
Күңел бит ул – иксез-чиксез куыш,
Шул куышка куык – мин акыл,
Куык эчләрендә и айкала
Нәфес уты капкан рух-ялкын».
Өч катламлы – нәфес, рух, акыл, –
Гүя бәлеш дөнья мичендә.
Адәм булып пешсен өчен бәлеш,
Күпме утлар кирәк эчәргә...

*2008 – 2009*

* * *

Көмеш тәңкә булып йөзә өстә күбек,
Тәңкәләнми уйнап, тирән диңгез төбе...

Минем күңел – диңгез, уйлар дулкын кебек,
Бакый ягы тыныч, фани ягы – күбек...

*2009*

* * *

Гомерне ике яшәсәң,
Жәл булмас иде бусы,
Каралы-аклы булса да,
Аклы-каралы тузы.

Жәл булмас иде биюләр
Чит-ятлар кубызына,
Ярты гомер түзгән икән,
Түзәр идең азына.

Түзәр идең җилләрендә

Сынса да канатларың,
Тышауланса да боргычлап
Йөгерәсе аякларың.

Җилкәннәрең ертылса да,
Тотылса да пычакка,
Түзәр идең гомерләрне
Ике үтәсе чакта.

Түзәр идең, яшәрмен дип,
Гомер янә килгәндә.
Тик...
Бер тормыш, бер гомер ул,
Ике килми кемгә дә...

*2009*

### *Тормыш-балан*

Сыкранмас өчен
гыйбрәт бар
күзге кызыл баланда.
Чырай сыткыч әче балан
Карлар төшеп баллана.

Тормыш та шул ук балан...

*2009*

*** * ***

Күз алдында
йөк төягән
җигүле ат.
Үз хәлемне
аңлыйм сыман
шуңа карап.

Үзем шул ат,
үзем – арба,
үзем үк йөк.
Өч халәттә
чәбәләнгән
мин бер көек...

*2009*

### *Тормыш – гармун*

Гармунны тартып-төртеп торсаң гына көй чыга...

*2009*

*** * ***

Өзелә калса ике кылы бәгыреңнең,
Шик юк, кеше, җанвар булып калуыңа.
Ул кылларның берсе – оят, берсе – намус...
...Җанвар булгач – безнең дөнья урман сиңа.

*2009*

*** * ***

Иоганн Гёте, һәм Добровский, һәм Мәхмүтов –
Өч халыкның өч баласы, өч нуры...
Карловы Вары суларының чeлтерәве
Даһилардан хәбәр булып яңгырый.

Һәр тарафта сихри кайнар чишмәләре,
Шифа суы тәнгә бирә мең сихәт.
Аң сихәте, җан сихәте даһилардан –
Шигърият, илаһи тел һәм мәгърифәт...

*Карловы Вары*
*2009*

## *Моцарт йортында. Венада*

Моцарт йортында. Венада.
Яңгырый көй-такыя...
Көмеш кылларга кушылып
Тибрәнә сыман дөнья.

Әле күктә, әле җирдә...
...көй канатлы –
    көй оча,
Өермә булып күтәрә,
Агымсу булып коча!

Көй тутыра бүлмәләрне,
Моцарт уйный...
Моң – тере!
Диварларда катлам-катлам
Мәңгелек көй хәтере.

Яңгырый көй ике гасыр –
Үрелгән алтын нурдан,
Шул көйләргә гашыйк күңел –
Син миңа якын туган...

...Кырык бишнең матур язы.
Вена. Фотода әти.
...Кинәт сызып үтте җанны
Ут булып – ре-ми-фа-си...

...Ике мең ун. Мин биредә...
Күңелнең нечкә мәле.
...Минем җанны синең җанга
Ялгый Моцарт көйләре...

*Австрия, Вена*
*2010*

*** * ***

Ап-ачык,
ап-ак,
яп-якты –
...әҗәл.
Буталчык,
кап-кара,
караңгы –
...яшәү.

Гомер бакый тартылабыз
ачыклыкка,
аклыкка,
яктылыкка...

*1999*

## ***Өмет***

Тәнем-җаным җитмәс,
беләм.
Тик, иншалла,
җитәр каным, –
Миндә туган рух тамчысын
Чишмә итәр оныкларым.

Тузганак та,
җил дә булмас,
Мин ялгаган өммәт мәле.

Фани дөнья бәгырендә
Сөләйманнар күзәнәге...

*1995*

## ***Авылыма***

Күзләрең кызгылт сөрмәле,
Ул күзләр – чишмәләрең,
Чишмә суы юа, сафлый
Күңелем киштәләрен.

Керфекләрең күксел-кара,
Ул – урман-керфекләрең,
Эретә күңел төерен
Хәтта кар бөртекләрең.

...Олы Елгаң моңсу-боек,
Читләшкән сыман елгаң,
Күңелле түгел миңа да –
Ах, каенлык югалган...

*1993*

*** * ***

Ник языла озын шигырь?
Яратам бит кыскасын –
Берчак оныгым күрсен, дип,
Күңелем карточкасын.

*1993*

*** * ***

*Җайлы ул әйтергә «сөям» дип,*
*Һәр йөрәк тибешем шул ласа!*
*Мин разый тумаган булырга,*
*Син – миңа, мин сиңа булмасак...*

*1994*

*** * ***

Ярсыз елга –
елга түгел, юеш җәймә,

Ярсыз елга
кая аксын, кайсы көйгә?
Ярсыз – елга тиз югала, бетә кибеп,
Ярсыз – елга эзен җуя җиргә иңеп.
Өч көн ялгыз,
үзем генә аулак өйдә,
Яши алмыйм икән инде
ярсыз мин дә.

*1983*

*** * ***

*(Акрошигырь)*

**В**акыйг бәхет: сөлек сында –
калыпларга сыймас фараз,
Күк капусын ачар хыял,
Тәңре үзе хасил кылган фикер-бәян...
**Е**фәк бишек ике күңел сиртмәсендә
хыялларга тияр-тимәс.
**Н**азлы уртак тибрәнүләр...
әрнүләр дә уртак...
...уртак бишек:
кын күрмәгән ике кылыч – ике йөрәк:
йөздән йөзгә нур тамганчы – әзме очкын,
әзме кисек...
**Е**рактан, еллардан күренер:
бер кында кылычлар,
сузыла бишектән бишеккә җан кылы,
синең кан – минем кан тамчысы
йөрәктән йөрәккә
тын бирә гасырлар аркылы...
**Р**ух рәссам күчерә синнән дә, миннән дә:
иң нечкә тибрәнү:
мәңгелек тибрәнү...
**А**й шаһит:

**М**оң тулы бишектән дулкыннар
**А**гылыр, агылыр, агылыр...
**Т**өннәрдә йолдызлар кабызыр,
**У**т булып күкләрдә чагылыр –
**Р**әшәгә әйләнеп болында тибрәнер
**Ы**шаныч – яктылык –
**М**атурлык
кыллары
ул синдә, ул синнән
мәңгегә үрелгән,
мәңгегә!

*1995*

*** * ***

*Кызыл Чишмә кызына*

Бер мизгеллек бәхет! –
кизләү өсләрендә
Энҗеләре эри гыйнварның,
Тылсым тулы нурлар
сыйпый ап-ак сыртын
Җирне кочып яткан җанварның.

Йөгереп барган көйгә
тынып калган дулкын –
Катлы-катлы – гүя саңаклар,
Олы Елга үзе

тимгел-тимгел чуртан,
Ә сыртында каен-канатлар.

Сыйпалганда чулпың
чуртан күзләренә,
Мәрҗән күзләреңдә ут яна,
Ап-ак карга яткан
тәңкә эзләреңнән
Йөрәгемдә җылы эз кала...

Татлы иреннәрең
тидермә бәкегә,
Салкын судан саклый күрсәнә,
Канатларын чуртан
әрле-бирле чайкый,
Ахры, шуны күреп ирсәүгә.

Кара толымнарың
тидермә бәкегә
Ымсындырып Елга-чуртанны,
Язга әле иртә,
татлы төшләр чиртә,
Төшләре дә сине йотарлык.

*1995*

## *Кара җиләк*

Кара җиләк сайлый күл куенын,
Урманның да сайлый карасын,
Кайсы – урман, кайсы күл төсендә,
Бер татысаң оныта алмассың.

Синдәй татлы җиләк ул бик сирәк,
Ай, кара җиләк, кара җиләк,
Карурманга тартыла йөрәк,
Бер дәвасы бар – кара җиләк.

Тамчы-тамчы үсә кара җиләк,
Файдасы бар, диләр йөрәккә,
Сагынуларны баса алмый җиләк, –
Урман сагышлары җиләктә.

Кара җиләк синең күзләреңдәй,
Кара җиләк синдәй чем-кара,
Яраларга шифа да сулышың,
Яратудан гына юк чара.

*1993*

## *Курай моңы*

Ә курайда моңлы ла уйнадың,
Өзеп-өзеп үрдең җаныңны,
Башкорт моңы – сагыш тулы дәрья,
Юкәләргә акты сарылып.

Балдай куе, салмак бер көй иде,
Курайчысы чыккан исемнән,
Ә курае канга сеңгән, эреп,
Шуңадыр ла йөрәк җилсенә.

Аһ, бу көйгә чумып-йөзеп булыр,
Канатланам, сөям-сөеләм.
...Өфеләрдән кайтып барыш, очып,
Чалкан ятып курай көенә.

*1993*

### *Сиңа гына*

Хәтфә үлән булсам, җуймамын эзләрең,
Гомеремне чалгы кискәнче,
Кочар идем назлап билең салган эзне,
Ефәк җепкә охшап кипкәнче.

Тамчы булсам әгәр, керфегеңдә мәрҗән
Булыр идем гомерем беткәнче,
Кар бөртеге булсам – татлы иренеңдә
Соңгы мизгелләрем үтсәче.

Купшы чәчләреңне үрер-сүтәр идем,
Тарар идем булып җил-тарак,
Тынмас идем һич тә, синнән туймас идем,
Йә шашынып исеп, йә – салмак.

Балан булсам әгәр, әче димәс идең,
Тел очыңа өзелеп төшсәм дә,
Кызыллыгым минем – янып яратудан,
Әчелегем – өзелеп көткәннән.

Якты йолдыз булсам, синең йөрәгеңә
Тамар идем түзми, җай табып...
Аккош булсаң, разый, күлдә шәүләң булыйм,
Каурыйларың тирбим чайкалып...

*1993*

### *Әллә бармы гаебең?*

Иртән генә аккош сыман
Иркәләндең, алтыным, –
Әллә сихер сарылганмы,
Күреп дөнья асылын?

Куырылган җан канатың,
Сыйпаган мәллә суык?
Керфегеңдә хис тамчысы
Мөлдериме яшь булып?

Шат йөзеңнән нур сирпелсә, –
Хәернең дә хәере!
Күзләреңне яшерәсең,
Әллә бармы гаебең?
Әллә бармы...
        гаебем?

*1982*

*** * ***

Өзгәләнмә,
      өзгәләнмә,
            өзгәләнмә үзәгем,
Дөньяң – бөтен, кайгың – төтен,
Өзгәләнмә, түз әле.

Тормыш изә изелгәнне,
Тәкәбберне – сындыра,
Чарлый-үткерли, ныгыта,

Меңнәрдән сайлап кына.

Өзгәләнмә
 изеләм дип,
Бу әле сыйпау гына,
Өзгәләнмә сыгылганда, –
Бу әле сынау гына.

Өзгәләнмә чарланганда,
Сабыр диген, түз әле,
Тәмуг утында ярала
Асылташның гүзәле.

*1983*

## *Мине көткән чәчкә-гөлләр*

Арышлары – ай моңына манма!
Сихерләнгән кызлар –
 гөлләре,
Мине көткән,
көткән чәчкә-гөлләр,
Сагыну тулы
зәңгәр күзләре.

Көмеш балык йолдыз чүпли күлдә,
Күкне кочып йоклый Зирекле,
Иңем сарган сагыз-еллар эри,
Һәр тамчыңа кадәр иректем!*

Кара бәрхет япкан камышларны
кыштырдатмый җилләр –
Нинди тын!
Чү, өркетмә,
Болыт күлгә төшкән,
Салмак кына чайкый
чал сыртын!

*1984 – 1985*

*** * ***

Йа Аллаһы! Фәрештәңә тиң илчеңне юксындыңмы, –
 ник чакырдың күккә?
Булсын адәм колың вә вәкилең –
барыбер бик иртә, нигә соң бик иртә?!

Мәрхәмәтле вә кодрәтле, йа Аллаһы, –
кешеләргә рәсүлләрең биреп,
Тик аяныч,
Җан җылысы вулкан булып ташканнарны
тиз аласың кире.

Авылымны, Ходай, ярлыкагыл,
аңламаса югалтуын кыйблаи җан,
Чишмәләр дә сизгән сыман, көйсез,
Яшь-яңгырын коя гына, үкси җиһан.

*1990*

## *Туй уңаеннан*

Табигатьтә бар туу да,

Бар яну, бар сүрелү,
Бар югалту, бар табу да,
Бар сөю, бар сөелү.

Кемгә ничек, ошый миңа
Гөрләп туй иткән көннәр,
Ярату иңгән яшьләргә
Сокланмас икән кемнәр!

Туй атлары җан түрендә,
Күңелләр тулган заман,
Ап-ак яллы алмачуар
Җилдереп бара сыман.

Атлар чаба каенлыктан,
Очалар тими юлга,
Төшми калган яфракларны
Сыдыртып китә дуга!

Җилферди каен тузлары,
Чыңлый, чыңлый кыңгырау...
Җил-давылдан сүнми Сөю,
Тимәсен генә кырау!

*1993*

### ***Ник сорыйсың телеп йөрәгем?***

Яныбызда гына тал-тирәк,
Талчыбыкның кайсы пешерәк?*
Бергә чакта юк шул кадер-сан,
Кабат кайтсаң иде, багалмам.

Бергә чакта юк шул кадер-сан...

Яныбызда гына тал-тирәк,
Былбыл тавышлары бик сирәк,
Былбыл җыры меңгә бер булсын –
Тик соңгысы гына булмасын.

Тик соңгысы гына булмасын...

Яныбызда гына тал-тирәк,
Күңел өчен тагын ни кирәк?
Ник сорыйсың телеп йөрәгем,
Тәңре алды миңа кирәген...

Ник сорыйсың телеп йөрәгем?..

*1993*

*** * ***

Иңдә – җиһан,
Билдә – офык,
аяклар очак иде...
Абынып,
очтым упкынга...

...ул синең кочак иде.

*1997*

### *«Аһ, җиргә иңәр идем...»*

Оча яфрак салмак кына,
Былтыргы яфрак микән,
Ап-ак карга ятты яфрак,
Мендәргә санап микән?

Яфрак төште салмак кына,
Җилдә зыр-зыр килмәде,
Эзе калды күңелемдә,
Төшкә дә керер әле...

«Җилләр үлчәде гомерем,
Җилләр исте үтәли,
Сорамадым су да, җим дә,
Эзләдем очу мәлен.

Саргая торды, очтылар
Тиңнәрем күмәк-күпләп,
Очасы иде миңа да,
Очасы иде күптән.

Көзге җилләр – туй атлары –
Болгый, очырта җилеп,
Яфраклар кызыл, ялкынлы,
Өлгергән кәләш кебек.

Яфрак туе сибә көмеш
Әбиләр чуагына,
Пәрәвездә алтын ямау –
Ут-миләш куагыннан.

Туй вакыты – иң матуры,
Шул чакта китсәң икән,
Уңнан – яфрак, сулдан – яфрак,
Шуңа ни җитә икән!
Ник соң, Тәңре, шундый язмыш,
Ник әле дөнья да тар,
Як-якта, өстә, аста да,
Ак кәфендәй кар да кар...

Ялгыз яфрак әллә соры,
Әллә җир төсле иңе,
Бәргәләнә ап-ак карга, –
«Аһ, җиргә иңәр идем,
Аһ, җиргә иңәр идем...»

*1993*

### *И тылсым!*

Көзге җил каенга сарыла,
Яңгыр да җуйгандай тавышын...
Күктәге йолдызлар гөлт! итә,
Төшкәндә аларга карашың...

Карашың сихерле, сөйкемле,
Мин аңлыйм, мин тоям үземдә...
Догадай кабатлыйм: и тылсым!
Мәңгегә өзелмә, өзелмә!

*1994*

*** * ***

Җир өчен кояш ул бердәнбер,
Кояшның күрмәссең шәүләсен,
Мәхәббәт тә кояш шикелле, –
Шәүләсез януда мәгънәсе...

*1994*

### *Янар чәчкә*

Чәчкә-чәчкә сүзләр,
Бәллүр вәгъдә-гөлләр
Алдый алмас уяу йөрәкне.
Күңеленә Сөю
Тамган сәгатьләрдә
Чәчкә сүзләр, гөлләр кирәкми.

Кайчакларда җилләр
Үтәр бәгыреңә,
Очар хисләр, кире кайтмыйча,
Янар чәчкә – Сөю –
Ачылмас мәңге дә,
Сагынмыйча, утлар йотмыйча.

*1994*

### *Тулган ай*

Тулган ай.
Йолдызлар коелды төнката...
Каенга сарылып үкседе
тол хатын...
Чәчрәде хисләре өзгәләп ак тузны,
Бер генә мизгелгә булса да
чигенде, югалды ялгызлык.
Ни ачы омтылу, ни татлы бу газап,
Тартылды каен да гүяки бер гасаб...

Карт каен түзмәде...
Әйтерсең чатнады үзәге...
Хисләрен, теләген биралды
Яшь хатын, и садә!
Әбиләр чуагы дип тормый,
Ыргылды каен-су кәүсәдән...

*1994*

*** * ***

Уйладым: күңел ул ни икән?
Җан өчен калыпмы күкләрдән?
Анадан сөт белән керәме,
Йә адәм үзенчә тегәме?

Уйладым: кемгәдер калыптыр,
Күңеле җанына табуттыр,
Кемгәдер канаттыр күңеле,
Ә миңа күңел – җан күреге...

*1994*

### *Әйдәле, хыял, яшьлеккә*

Әйдәле, хыял, яшьлеккә,
Печәнгә төшик тагын,
Олыгая барган саен,
Өметкә тия чалгың.

Аһ! хыял, синең канатлар
Болынны каплый иде,
Исеңдәме, чиллә төне
Иллә дә татлы иде...

Шул төндә ике йөрәкне
Бәйләдең бәгырь-җепкә,
Таң кызы җиргә төштеме,
Әллә мин йөздем күктә.

Җиләкле печән исеннән
Һушлардан язган чагым,
Җәннәт капкасы булдымы
Мине йоткан кочагы...

...Таңгача йолдыз чүпләдек,
Башны печәнгә салып,
Төн белән көнне ялгадык,
Күз кабакларын ябып...

*1994*

*** * ***

Әгәр син җаныем булмасаң,
Әйтмәсәң «әйе» дип теге чак...
Йөрәгем сизенә, юк шиге –
Тормышым кипкән күл буласы,
Хәятым буласы – мәңге чат.

*1994*

## *Боз китә*

Аңлыймын да сине, аңламыйм да кебек,
Бер карыйсың – дулкын, бер карыйсың – күбек.
Бер карыйсың – боздан катлам-катлам сырган,
Күп тә үтми туза тузмас дигән юрган.

Асылы бик гади: син гүя бер елга,
Табигать тә сиңа, дүрт фасыл да – туган,
Бер көнең җәй синең, дулкындай күңелең,
Көз җитеп, яңгырлар күпертә күбеген.

Кышы да көттерми, бураннар тиз җитә,
Сәгатьләп үзгәреш елганы боз итә.
Табигать-күңелгә бер чара бик җиткән, –
Кояшлы елмаю бозларны юк итә.

Шул серне белергә ни гомер, яшь китә,
Ачкычы табылгач – кояшлы һәр иртәм,
Җәйдән соң яз җитә, яздан соң җәй җитә,
Кояшка чыдамый, боз китә, боз китә!

*1994*

## *Тиңең җуйгач*

Сискәндем, карадым дөньяга шаккатып:
Ни гүзәл
йолдызлы бу кичләр!
Ах! Ник соң әле җан өшетә гүзәл кичләр?!

Таң калдым чәчкәгә күз атып:
Күңелгә ягыла хуш исләр!
Ах! Ник соң буа, тасма булып, шул хуш исләр?!

Бу таныш җыр, ә ишетәм тәүге кабат:
Ягымлы, йөрәккә җайлы көй!
Ах! Ник соң тырный күңелемне бу җайлы көй?!

Нигә, нигә син соңардың ачы сабак:
Исән чакта шуны аңлап була бит, –
Җуйгач тиңең, матурлык та буа бит!
Ах!..

*1994*

## *Күңел дулкыннарың*

Нечкә кыллар, тияр-тимәс булып,
Күңелемне ялгый күңелгә,
Бу кылларны чиртсә чиртер хисләр,
Ә сүз – сызгыч, сызгыч бер, телгә.

Уйлар туа, төнгә чума тора,
Төн куесы гүя тоташ хис,
Авылымнан Ямаш бистәсенә
Кулын сузган сүнеп барган кич.

Ак киемнән, ай-кояшлы итеп,
Күрәм Сине, күрәм төн кисеп,
Сагынуларың баш астыма куям,
Күңел дулкыннарың – тәү бишек.

*1994*

## *Агылам төшләреңә*

Әгәр ныклап онытылсам,
Укырмын кебек сүзең,
Йөзләп чакрымнар арада,
Алдымда нурлы йөзең.

Тырышамы уятыйм дип,
Бәрә дә тына дулкын,
Юк, – тәнем сизә сизүен, –
Сүзләрен булмый укып.

Бу сәгатьтә ниләр борчый,
Ник болай күңлең тынсыз?
Ай бу төн! – Каккан казык мин,
Кайталмыйм очып тәнсез.

Тынычлан, әни, сизәмсең,
Мин сыйпыйм чәчләреңнән,
Тынычлан, әни, күрәмсең,
Агылам төшләреңә.

*1994*

** **

*Вакыт юк дип зарланучыга:*

«Йөзләгән каурыйларыңны җилпеп маташканчы,
Шул каурыйлар беркетелгән канатыңны җилпе.
...Канатыңны җилпегәндә, каурыйларың да җилпенер...»

*** * ***

Яшьлеккә күперләр тиз туза,
Аръякта – балачак шаукымы,
Ә юллар тоташыр шикелле,
Салават күпере аркылы...

*1994*

*** * ***

Сиңа, җаным, кулай итеп,
Койдым шигырь калыпларын.
Минем кылган гамәлләргә
Мөһер сугар оныкларым.

Җаным –
син бер тамчы күктән –
Тойгы-хисләр алиһәсе,
Беравыкка тәнгә иңгән
Күңел күгем – Җан бирнәсе.

Үзем – зиһен, –
бер мизгелгә тәнгә ия
фани фәкыйрь,
Әллә канат, әллә йөгән –
Миңа тынгы бирмәс фикер.

Ошбу тәнсез –
фикер өнсез,
Ошбу тәндә –
үзем теләп...

Җиһан-дәрья гизеп йөреш,
Өнсез өннең өнен өнәп.

*1995*

*** * ***

Кан тибешең күчте минем канга,
бармакларны кысты бармаклар...
юк, очмадың җирдән,
кочтың җаның белән...
күңелем күзен ачкан минутлар...

Юк, очмадың җирдән,
күңелемдә – кояш, –
ул бит синең җанның өлеше.
Гомер бакый: бер аң, бер тән булып, –
Ике җанга – йөрәк тибешем...

*1996*

*** * ***

Мин менәсе таулар
карап күралмаслык.
Башы – очлы кыя:
болыт куналмаслык.
Мин сайлаган баулар нечкә,
күз алмаслык.
Ялгыш чолганганда,
муен чыдамаслык.

Менәм текә тауга, ә бау –
минем гомер.
Кыя түбәсендә –
сиңа оя, бәгырь.

*1996*

** * **

Сагынам да,
тизрәк күрешүләр
булмас микән дигән уй килә:
йолдызларны күктән койсалар да,
булмас идем җирдә ятимрәк.

*1996*

** * **

Йолдызлы күк,
иләк сыман,
карлар или салмак кына,
Их, үзеңне ак кар итеп хис итәсе!
Карлар булып коеладыр зәңгәр күктән
Ай кызының тәңкә-тәңкә хәситәсе.

Кышның әле көмеш туе – күктә, җирдә,
Ылысларның түбәтәйле, хозур чагы.
Ә йөрәкнең үз фасылы,
Йөрәк сизә
озакламый
Бәллүрләнеп килгән кар өстендә
Умырзая калкачагын.

*1996*

** * **

Болын – яшел.
Үзе чалгы көтә
аллы-гөлле чәчкә,
үрелә билгә.

Их шул мизгел!
Хуш исләрдән исәр –
болыт-яңгыр көтә
яшьлек – чиллә...

*1996*

** * **

Җылы сүз дип,
синнән өметләнмим,
кояш нурларында туңсам да.

Тик нигә соң гел тоясым килә
күләгәңне генә булса да...

*1996*

*** * ***

Өзелгәнем,
җирдә эзләгәнем –
язлар сыйдырырлык бөреләр,
кояш сыенырлык күңелләр.

...җирдә – сөрү, көзге сөрү бара,
җем-җем уҗым – язга ялгама.
Уҗым кырын күреп, урап кайтсам,
өзелеп килгән өмет ялгана...

Һәр тамчыда
чагылмыйдыр
умырзая елмаюлы яз-бикә...
Һәр тамчыда
күзләмә кояшны...
Шыбыр-шыбыр коя тамчы-яңгыр –
Тып-тып иткәннәре – кояшлы...

Язлар бит ул күктән күккә ята,
офыкларны этеп як-якка,
тамчы сыйдырмый дип,
килми каламыни язлар,
сыенырлык бөре бар чакта.

*1996*

*** * ***

Арыш мыегын кытыклап,
тибрәнә көмеш рәшә,
рәшә белән тияр-тимәс
арыш нидер серләшә.
Кояш нуры чак-чак сыйпый,
чү! болыт, каплый күрмә,
әнә җил дә исми хәтта, –
югалды Зирекледә.
Бу бит тылсым, могҗиза дип,
тын тора йөрәк – сизгер,
...тургай җыры кагылса да,
югалыр күк бу мизгел.

*1996*

*** * ***

Күңелем – сәхнә.
Күпме караш
текәлгән сәхнәгә.
Кем
ни
көтә?
Дошман – үксү-улау.
Дуслар – мактау-майлау.
Һаман көтә хатын
төштә күргән хакын.
Пәрдәләре генә
ябылмасын диеп

көтә газиз әни.
Үзем дә мин көтәм:
елтыр күзле кызым
бермәл шул сәхнәдән
шәйләр үз йолдызын.
Күңел сәхнәсенең
ярым ачык мәле,
улым кулларында
күңел пәрдәләре...

*1996*

* * *

Кара толым, кара чәч,
Гәүһәр каш йөзек –
Ядәч!
«Мәңгегә!» диясем килде,
Иренгә ирен тигәч!

Юк, әйтми торыйм әле,
Мизгел – мәңгелек мәле!
Иренгә ирен тиюне
өзмимче,
сузыйм әле!

*1997*

* * *

Олы елга ташмый калмый язын,
Кар таулары ага болганып,
Дулкыннарга кушылып агар идем –
Ярлар кыса
үзен елганың.

Хисләремне боз-калыпка салдым,
Тынычланыйм, дидем, басылыйм,
Елга булып ага, эри бозлар,
Боз эретә күңел ялкыны...

Карга өрдем – умырзая калкыр...
Керфекләре булыр ефәктән.
Ап-ак карга бишни* елмаюлы
Умырзая тамды
...шәфәкътән.

*1997*

* * *

Мин сагынсам айга карыйм,
Син дә айга карарсың...

*Халык җыры*

Урта диңгез кочагында
Сардиния – җәннәт,
җәннәт.
Калкулыклар яр буенда –
түм-түгәрәк,
түм-түгәрәк.

...Түм-түгәрәк калкулыклар
Ята сыман

мине әйдәп...

Яр буенда комнан җәймә,
Ак күбектә җәймә чите –
Кайнар комны җайлый-или
диңгез җиле –
күчеп-күчеп.

...Әйтерсең лә җылы кочак
Әзерләнгән минем өчен...

Төн көмеше, көн алтыны,
Таң-фирүзә – сиңа чалым.
Кушылмыйча дулкыннарга
Түзәмени Сөләй-балык.

Фәза – чиксез,
Дәрья – чиксез, –
Мин
ялалдым
...сине танып.
Тормыш – фани,
Мин – мәңгегә.

...Мин мәңгегә –
Сине табып!

*Италия, Кыя-Лагуна*

*1997*

*** * ***

Йөрәк әрнүеннән улый-улый,
мендәр белән күкрәк арасында
күпме төннәр сыттым
мин – юләр...

Юләрлегем – сагынып сөйләрлегем...

Җәрәхәтсез
тумый,
тумый мәрҗән,
җәрәхәтсез тумый Сөюләр...

*1998*

## *Үкенмәм*

Кил яныма
язгы җилләр булып.
Соңгы карлар булып ятсам да –
үкенмәм.

Кил яныма
ләйсән яңгыр булып.
Соңгы бозлар булып аксам да –
үкенмәм.

Кил яныма
җәйге челлә булып.
Мин – күл булып,
кипсәм дә –
үкенмәм.

Кил яныма
ком бураны булып.
Чишмә булып типсәм дә –
үкенмәм.

...Шул мизгелме –
бер гомерме дисәң,
шул бер мизгел – булыр гозерем.
Үкенечле бер өн булыр иде –
үткән булса синсез гомерем.

*1998*

## ***Кизләү суы, чәй суы***

Чәй суында ай яктысы, ай яктысы –
Чәй суына килгән сылу – Чишмә кызы.

Вак-вак басып уза кызлар – сыгыла Бүле басмасы,
Җилфер-җилфер уйный җилдә ефәк калфак тасмасы.

Чияле чиләкләрендә чишмә суы – чәй суы,
Сокландыра яшь кызларның чәй суыннан кайтуы.

Күңелендә чишмә чыңын кабатлый иркәсенә,
Сыгылмалы көянтәсе сарыла җилкәсенә.

Бер үк кизләү, бер үк кызый – суның тәме бер түгел,
Дәртләнә дә, сызлана да, моңлана да бер күңел:

– Чәй суында ай яктысы, ай яктысы –
Чәй суына килгән сылу – Чишмә кызы.

*1998*

## ***Синең күзләр***

Синең күзләр зәңгәр күккә ятыш,
Кара күзләр зәңгәр алмалы,
Синең күзләр сихри күлләр булды,
Кергән идем – чыга алмадым.

Синең күзләр – ике елтыр кизләү,
Күңелемдә зәңгәр эзләре,
Инешләрдә, моңсу томаннарда
Зәңгәрлеге синең күзләрнең.

Күзләреңдә төнен кояш нуры,
Ай нурлары сирпи көндезен,
Әйтерсең лә синең күзләреңә
Алма булып иңгән күк йөзе.

Синең күзләр зәңгәр күккә ятыш,
Кара күзләр зәңгәр алмалы,
Синең күзләр сихри күлләр булды,
Кергән идем – чыга алмадым.

*2003*

*** * ***

Кил әле, таң гөлем, кил әле яныма,
Йөрәккә ут салып, бер елмай,

Ал кояш нурлары сирпелә йөзеңнән,
Бердәнбер тиңдәшең – тулган ай.

Син генә канатлы итәсең елмаеп,
Сүзләрең – челтер-су инештән,
Чәчемә чәчләрең сыйпалган мизгелдә,
Син үзең канатлы фәрештәм.

Кил әле, сөеклем, кил әле бер үбим,
Үбешеп яшиләр, дисеннәр.
Иренең иренгә тигәнче исерәм
...Мәңгелек мәхәббәт хисеннән.

*2003*

## *Җанкисәгем Венерага*

*«Франческо да Милано» канцонасына*

Кояш нуры күктә,
Бәллүр сулы чишмә,
Зәңгәр моңсу күзләреңдә
Мәхәббәтем чиртә.

Күлдә ике аккош,
Бәхет юрый пар кош,
Хисләремнең кайтавазы –
Күк йөзендә балкыш.

Җирдә әле матурлык аз түгел,
Матурлыкка бишек безнең күңел,
Мәхәббәтне таный безнең күзләр,
Көмеш чыңлы булсын безнең сүзләр дә.

Язлар килә, чәчәк ата гөлләр,
Сандугачы белән кайта җәйләр,
Алтын-көмеш коя безгә көзләр,
Мәхәббәткә генә илтсен эзләр дә.

*2004*

*** * ***

Һәрнәрсәнең ахыры бар,
Һәрнәрсәнең – үлчәме,
Һәрнәрсәнең үз көе бар,
һәрнәрсәнең – үз яме.

Иге-чиге юктыр сыман –
Күңел күккә ашкына,
Чиксез, үлчәмсез күңел дә
тулып таша еш кына.

Һәрнәрсәнең үз вакыты,
Вакыты белән көе,
Килә вакыт – күз дымлана,
хәтта җылы сүз тиеп.

Һәрнәрсәнең үз вакыты,
Вакыты белән яме,
Ләйсән итеп тойган вакыт
көзнең вак пәрдәләрен...

*2007*

*** * ***

Дөреслектән дөреслеккә
Күчешнең бар төрлесе,
Нокта, өтерле күчешләр,
Ноктлы-өтерлесе.

Күп ноктлы күчешләрне
Күперсез үтү кыен,
Дөреслеккә тозак тора
Куелган нокта саен.

Сорау, өндәүгә төренеп
Дөреслек килә икән,
Дөреслекне дөреслектән
Аерып тора читән.

Өндәүле сорау эчендә
Дөреслек тоташ томан,
Сораулы өндәү артында
Дөм кара упкын сыман...

Дөреслектән дөреслеккә
Күчешнең бар төрлесе,
Кыя булып аерганы,
Җайлысы – күперлесе.

Дөреслектән дөреслеккә
Күчешнең бар төрлесе,
Хакыйкатькә илтә шуның
Бары мәхәббәтлесе.

Дөреслекнең орлыклары
Мәхәббәт сүзләрендә,
Күренмәсә дә, хакыйкать
Мәхәббәт үзәгендә...

*2007*

## ***Мәхәббәт***

Уйласаң,
мәхәббәт өч төрле.
Илаһи мәхәббәт – Аллага.
Хакыйкать юлында бердәнбер таяныч –
Аллага мәхәббәт, мәхәббәт – Аллага!

Икенче мәхәббәт – ул сөю
Гаилә корырлык ишеңне.
Канатлы мәхәббәт – ул сөю тиңеңне,
Бу сөю – фәрештә итүче кешене.

Өченче мәхәббәт – дөньяга,
Дөньяга мәхәббәт – ярату!
Дөньяда тигезлек – яратып ярала,
Дөньяның кендеге, барлыгы – ярату!

Уйлансаң,
мәхәббәт мең төрле...

*2009*

*** * ***

Кышкы урман. Аккош күле.

Җем-җем килә ап-ак кар.
Чаңгыларда оча күңел,
Тып-тын бүген каенсар.

Кайнар йөрәк тибешендә
Оча сыман чаңгылар,
Гүя карда тасма-эзләр
Карлар эреп салына.

Чаңгы эзе – хис кыллары –
Тоташтыра хисләрне,
Кояш сыйпый чаңгыларны –
Күңелнең хозур мәле.

Кышкы урман. Аккош күле.
Ап-ак карда пар тасма.
Ике йөрәк салган эздән
Бәхет килә, кар таслап...

*2010*

*** * ***

*Вакыт – елга,*
*мин – көймә...*
*киресенчә түгелме:*
*мин – елга,*
*вакыт – көймә?*
*Акмыймы соң мизгелләр*
*зиһен тарткан көйгә?!*

*1996*

### *Әнием*

Бураннарга кереп исән-имин чыгам,
Уйларымда булгач гел Әнием,
Дәрьяларны үтәм, кичәм исән-имин,
Күңелемдә булгач син, Әнием.

Әнием минем –
ак канатым минем,
Әнием минем –
моң канатым минем.

Чәчләреңнән сыйпыйм ерак-еraклардан,
Көмеш чәчләреңә кирәкми шәл,
Юлларыңны югалтмыйсың, ялгышмыйсың,
Ай-кояшлы күңелеңә кирәкми шәм.

Әнием минем –
ак канатым минем,
Әнием минем –
моң канатым минем.

Акыл белән, бәгырь белән тоям, Әни,
Аңлашырга диеп дәшә күңел,
Мин бит җиргә, Әни, син китергән өлеш,
Безне аерулар мөмкин түгел.

Әнием минем –
ак канатым минем,

Әнием минем –
моң канатым минем...

*2001*

### *Әй, дәрья*

Дәрьяларда ай-кояш бар, ай-кояш,
Дөньяларда ниләр бар, дип, кил, сораш.
Дөньяларда таптым сагыш, таптым моң,
Әти, җаным, киңәшергә, ахры, соң...

Минем яну-көюләрне ни басар?
Безнең алда күрешүләр ни гасыр?
Чишмә-судыр дигән идем бу дөнья,
Юк, түгелдер көмеш агым, бу – дәрья.

Дәрья чиге коеп куйган кыядыр,
Нечкә күңел җан-рухларны тоядыр.
Ачы яшем түгелмидер һич юкка,
Тамчы-тамчы дәрья җыела җан-рухтан.

Юк өсте дә, юк асты – тирән икән,
Бер керәм дә чыгамын димә икән.
Сыкрансам да кайчак, әй, дәрья, диеп,
Язмыш баса: бу – үзең, дөньяң, диеп.

*1994*

*** * ***

*(Акрошигырь)*

**Ә**биләр чуагы бер килер таҗ булып,
әлегә табигать әзерли сәхнәсен:
көмеш кыллар бишек-көзне
элә каен-усакларга,
әле ялкын үрләмәгән
җәйне сагынып җилфердәгән яфракларга...
Кыр казлары әле җирдә,
урман әле кияр-кимәс аллы-гөлле хәситәсен...
Миләш – кызгылт, балан – әче,
сөбханалла, күз тимәсен...
**Н**урларда чайкалыр пәрәвез...
Хатирә-яфраклар: яшеле-көрәне – төрлесе,
пәрәвез – көз-күңел көзгесе...
Төенләп ден салган күпме җан иясе,
күпме күз, күпме йөз – янәшә...
Сагышлар – томан-су, яшьмени – таңгы чык,
куеның дөньяга ай-кояш өләшә.
**И**ң татлы мизгелләр, күңелең мәккәсе,
йөрәгең гомерлек кылган хаҗ –
**Е**лдан ел илаһи кыллардан толымлап үрелгән
тыныч көч, көчле рух...
чагылыр көзгедә
**М**әңгелек моң булып
әбиләр чуагы – алтын таҗ...

*1995*

*** * ***

*(Казыкшигырь*)*

**Ә**зерме син, зиһен,
акчарлактай
ике дәрья дулкыннары арасында
йомшак канат кагышыңа буйсындырып бер итәргә
ике яклап үтә нечкә хатирәләр тибрәнүен?..
**Т**ын бер дөнья ике дәрья арасында:
Йотты мине фикерләрем – төпсез упкын,
төпсез упкын.
Упкын түгел, бишек мәллә: төпсез бишек –
бер халәттән бер халәткә тибрәлүем...
**И**стә! Истә-ә! Истә-ә-ә!..
Тышсыз үзәк – биксез йозак – йөгәнсез ат –
баусыз таган...
Вак йолдызлы кара күктә буйдан-буйга
**Е**ллар аша күңелләрне камаштыра
Сыңар мизгел ялтыраган ут-аҗаган...
**М**ин бармы соң...
Бу дөньяда?..

*1995*

*** * ***

*А.Арслановка*

Ак битләрне каурый-каләм бизәсә дә,
Уйламагыз шигырь яза шагыйрь диеп,
Алданмагыз, сүзләр сүзгә иярсә дә,
Күңлегезгә хуш килерлек вәзен киеп.

Юк, тырышмыйм ошасын дип бирәр кемгә,
Юк, мин язмыйм, язам диеп бер-бер шигырь.
Шырпы суырам бәгыремнән рифма берлә,
Сызлауларым басылсын дип, тынсын бәгырь.

*1994*

***Ялгыз имән***

*Остазым профессор Рәис Бохараевка*

Салмак кына имән саллар ага,
Борма сулар чайкый салларны,
Бер киселгәч, имән дә йомычка,
Эретәмени сулар моң-зарны!

Имәнлектә имән имәнмени,
Ялгыз иман – имән, ичмасам!
Идел ярын коча тамырлары,
Тыгыз ботакларга күк кысан!

Учын салган имән текә ярга, –
Бармак-бармак имән тамыры,
Утлы яшен күпме сүгенгәндер,
Тимер бу, дип, шайтан алгыры!

Пычкы теше сынып калган эзләр, –
Бирешмәгән, салга акмаган,
Кәүсә чатнап үзәк өтелгәндә,
Ныгый гына барган чатнаудан.

Идел кадәр Идел ярын тота
Тере субай – ялгыз имәннәр.
...Ә елгада сал-сал имән ага, –
Имәнлектә кичә күргәннәр...

*1994*

* * *

*Р.Фәйзуллинга*

Бәягезне беләсез Сез –
Бәяләнмисез.
Ил язмышы иңегездә –
Эреләнмисез.
Чүл-сахралар кичсәгез дә –
Дөяләнмисез.
Ак шигырьнең ак юллары
кайчак сала җанга яра –
Юк, акланмыйсыз.
Җил ягына кыстыргалап
салам-рифма, –
Юк, вакланмыйсыз.

...Атмаса да сәгать саен таулар ватып,
Чыкмаса да минут саен лава-хисләр – йөрәк хаты, –
Үз көчен һәм егәрлеген вулкан белә,
Шул вулканның чын бәһасен
күрә белгән икәү генә:
чын дус һәм чын дошман.

*1993*

## *Рәхмәт*

*Флүскә*

«Әйе» һәм «юк» димәскә,
Ак-карага тимәскә»...
Рәхмәт әле Флүскә,
Төшерде шуны искә.
Бу уенны ишеткән бар,
күргән бар,
уйнаган бар –
аңлаган юк,
сеңдергән юк,
уйланган юк.
Уйландырдың.
Суганны чишендергәндәй
Тунадың, тирене салдырдың.
Арындым сорыдан, ачылды үзәгем ак төскә.
Ак икәнен бу ак төснең
аңлый алдым кара төстән.
Карасын таныдым ак төсләр чигендә.
Бусы – ак,
ул – кара.
Хәзер кил бирегә. Кил, кара.
Шул ук төс, шул үзәк, шул ук күз,
Каршы як ноктадан күзәтү:
Бу – кара, теге – ак.
Бер нокта ласа бу – ак-кара!
Бер нокта – ике як:
Ак-кара, кара-ак...
Тәгәрмәч-тормышта койрыклы нокталар:
ак – соры – кара – соры
ак – соры – кара – соры...
Юк бит моның ахыры!
Әйләнә буенча әйләнә-әйләнә
нокталар тасмага әйләнә...

Ак диеп әйтеп өлгердем,
Кара булды әйткәнем,
Карасы дип әйткән идем –
Үзем агын шәйләдем.
Рәхмәт әле Флүскә,
Уйландырды дөрес тә,
«Ак-карага тимәскә»,
Ак-карага тимәскә...

*1995*

*** * ***

*Флүскә*

Дон Кихотлар ничек булмасын ди,
Тегермәндәй булгач замана,
Ташларында кеше язмышлары,
Берәү – түзә, берәү – зарлана.

Җил каршымы, әллә җилгә каршы,
Дон Кихотка кыйбла билгеле!
Гайрәт чәчә, өнди, халкын дәшә, –
Ә нәтиҗә бер үк:
И тиле!

Әй, Дон Кихот, алҗытма атыңны,
Бер кәмиттер бу чор, йә уен...
Аңлый инде, үзе сизә шуны,
Килешүе әмма бик кыен...

*1994*

*** * ***

*Р.Хариска*

Җир өстендә
чак-чак кына бөтерелгән
орчык башы –
чишмә булып килдем,
Дәрья бул, дидегез – ышандым, күндем.
Орчык-чишмә
бөтерелде күңелемдә,
Очлы башы тиде, ахры, җан-диңгезгә...
Бу ташкынга йөрәк кенә
инде иярсен,
Гомере буе Сездән
сүз көткәндер диярсең.

*1993*

*** * ***

*Ркаилгә*

Мин – диңгез дулкыны,
түз елга!
Түзегез сугылган ярлар да.
Үзем дә кыйналам ярларда,
үзем дә сыкранам елгада.
Ни кылыйм – сыймыйм ла елгага...

Ни кылыйм – сыймыйм ла елгага...
Төшкәнмен җил куган болыттан.
Мин дәрья айкарга яралган,
диңгезгә, дәрьяга юл тотам.

Гаеп юк сездә дә, миндә дә...

Гаеп юк сездә дә, миндә дә,
ишкәкле көймәләр,
бигайбә! –
тактагыз тактага тузганда,
кораблар йөртәсе иңнәрдә.
Түз, елга, әзенә, күп түздең...

Түз, елга, әз генә, күп түздең,
ишетәм туфан-су тавышын.
...ярларың тын алыр беравык,
җайланыр бервакыт агышың...
Мин – диңгез дулкыны,
түз елга.

*1996*

*** * ***

*(Триптих)*

*Фәизгә*

**1**

Җидегән йолдыз чүмеченнән
Миңле йолдыз тамды...

Без йоклыйбыз әле,
миңле шагыйрь,
Син уяндың...

Гәүһәр булыр:
егет – алмаз.
Күпләребез йоклап уза
Син яшисен.
Кем әйталыр, күрмим, диеп –
Юк, әйталмас!
Табигатең шулай синең –
эндәшмисең...

Юл дәвамы түгел –
Юллар чаты булган
Без күрешкән мизгел.

Кай арада юллар чуалды...
...Күк гөмбәзен кисеп
Моңлы йолдыз тамды...

**2**

...Кай арада
Дөнья чүрәләнде* –
аста булды өсте...
...Күк гөмбәзен кисеп
Моңлы йолдыз төште...

...Ә гаилә –
Ике канатлы кош.
Кошмы соң ул,
күнә алса бер канатка?
Дустың – кораб. Ә син – дулкын.
Бәлки, киресенчә.
Дус – дусмыни,
әгәр югалтуга килешалса?

...Әйтмәс идем сирәк диеп
күрешүләр.
Кулга – куллар,
Хәлгә – хәлләр.
Элгәре соң
еш булдымы
уйга фикер
кушылулар?..
Сизәсеңме, якынайдык
чиксезлектә.
Уйга уй бар.
Җанга җан бар.
Өзелмәс җеп –
фикерләрдә очрашулар...

...Кай арада
Дөнья чүрәләнде –
асты булды өстә...
Күрешүләр күкнең
чүрәсенә күчте...
**3**

Җиләктәшләр.
Бер аланда, Тәңре кушып.
Шулмы фарыз –
бигрәк лә тиз
тулды синең тырыс...

Безнең яшәү –
ике халәт:
Тән-Җан бергә икән –
ояң – дөнья.
Тәнең гүргә иңсә –
йә Тәмуг, йә Җәннәт.
Кайсың майа*,
Кайсың вакыйг?
Кайсың фани,
Кайсың бакый?
Синме киттең,
Минме калдым?
Түгел микән киресенчә?

Кайсыбыз жәл
сиңа, әҗәл?
Аянычмы, куанычмы
Китүчегә
синең әмәл?
Ком сәгате әйләнгәли,
Өсте – аска, асты – өскә.
Бергә чакта бу сораулар
киләмени искә!..
...Җәясен югалткан ук.
Уксыз җәя.
Чүкечсез
тимер башмакта яткан
ярым әзер кылыч.

...Өзгәләнә бәгырь.
Ә мин – тыныч.

...җыел, җиләк,

тулма әле, тырыс...

*1998*

*** * ***

*Ф.Зөлкарнәйгә*

Төнге күккә төрдем
хисләремне –
таңга очты
кара карлыгач.
Көн аклыгын кушып
үрдем хисләремне –
ук икәнен белдем, атылгач.

...хисләремне
таң алдыннан сөйлим,
ул карлыгач
уктай булсын, димен.

*1997*

*** * ***

*Х.Бигичев матәменә*

Ап-ак карлар
явып үтте җиргә,
Ак кәфенгә төреп
соры көзне.
Ап-ак карлар җәеп
эзләренә
Искәрткәндер, ахры,
Тәңре
безне.

Яп-якты Ай
йөзде кичә күктә,
Кичәге Ай
бүген – кара тамчы.
...Күк катына алды
язмыш-лачын
Көмеш телле
мишәр сандугачын...

*1998*

*** * ***

*Л. Зөлкарнәйгә*

Шигырь түгел, затлы сырамыни!
Сүзләр түгел, балык канаты!
Тел өстендә
эретә-эретә генә,
Тәмен тоеп кына кабатлый.

Сүзнең төсен,
эчен,
тышын сизәм:
Йә йомарлап бирә,
йә турап, –
Авыз суын китерерлек итеп,
Балык канатыннан
татлырак.

Әйдә, дустым, тагын бер дустыган*
Гәрәбәдәй сыра эчикче...
...Итекчеләр читек ясаганда,
Сыра белән сыйлый читекче...

*1996*

*** * ***

*Л.Зөлкарнәйгә*

Кояш яктысыннан берәү
күләгәләр коя...
...кечкенә бер күләгәгә
меңләп сылтау сыя...

*1996*

*** * ***

*Укытучым Сәит абыйга*

Гомер-яфрак алсулана,
Аңлый барам, остазым
Бер сүз әйтә, –
Йөзне тыңлый,
Әйтәләр: сүз остасы.

*1993*

## *Кырыгыңда очрашу*

*Илсурга*

Иске зират – тып-тын дәрья,
Чоңгылларда дөнья зары,
Салмак кына, дулкын-дулкын
Коя гомер елгалары.

Чоңгылларда
Өзгәләнгән фани дөнья йомгаклары,
Җан дәрьясы – чиксез җиһан –
Җыя тора орлыкларын...

...Язын туфрак басылуын
Сизә каен тамырлары,
Ак тузларда уйный җилләр
Бездән килгән зар-моңнарны.

Мизгел,
гасыр,
йә мәңгелек –
Ни бар сездә бер-бер даим?
...Җилгә ялгый ак тузларын
Баш очында моңсу каен.

*1993*

*** * ***

*Аликка*

Өметсез – шайтан, дисезме? –
Димәк, мин шайтан инде,
Гомер үргән өмет-баулар
Сузылган айдан инде...

Без татарга һич килешмәс
Элмәк итү бауларны,
Айны элмәккә алыйк та
Эретик зар-тауларны.

Өмет бауларын иштек без,
Кушып күңел кылларын,
Баулардан үреп ятамын
Көрәш чыбыркыларын,
Яшәү чыбыркыларын.

*1994*

*** * ***

*Ш.Рамилгә*

Җидегә ярылам.
Бер булып сыймадым җилгә дә...

...Сыер көтүе челлә чәйни.
Тургай. Күктә. Шул ук нота. –
Чирек гасыр бер ноктада...
Чалкан ятам.
Һава – тыгыз ястык.
Күк гөмбәзе –
әйләнеп капланган вакыт касәсе.
Дөньяның юк ни ачысы,
ни төчесе...
Кояш зеңләп якыная.
Нур-тамчылар тибеп яба күз кабагын.
Чикерткәләр скрипкада
иң биеген ноталарның
күтәргәннән күтәрәләр.
Менә-менә там-там сугар,
менә-менә там-там бәрер...

...Дүрт кат дөнья.
Бер кат күңел.
Бөкресе дип уйлаганым
кай арада канат булган.
Кайсы тауга, йә кыяга сугылсам да –
таныш каурый.
Таныш каурый.
Эздән килгән ак кошларга
Сусаганда чишмә булып
Каурый саен ал тамчылар.
Җиде күктә Яшәү ташы* –
Үти** акчарлагы...
Юллар берме? Бер дөньямы?

*1995*

*** * ***

*(Акрошигырь)*

«**Җ**е» дигәндә җан да, җен дә, җил дә,
җәһәннәм дә шунда, җәннәт тә...
җиһан айкап исә җитез җилләр...
җил генә бар җирдә,

җил генә бар җирдә...
җилдән йөрәк, җилдән бәгырь,
уйлар – җилдән...
**Ә**ллә кайдан әллә кая
узып барыш дулкын-дулкын,
фикер-фикер, күңел-күңел, җилкә-җилкә...
**Л**ә илаһы,
тартылса да төрле җайга:
кылы кылга
көйләнгәндер бер уңайга, бер үзәккә,
өзелә дә, ялгана да: кыллар хәрәкәттә...
көйне көйгә ялгый-ялгый...
тәкбир әйтә-әйтә.
**И** дөньяда тибрәнүнең тибрәнүгә ялгануы!
Күрер күзгә керпе сыман күңелләрнең
**Л**еп-леп итеп тибеп торган
нокталарда бер-беренә кагылуы!..

...**Э**нәле җеп бата-калка
буын-буын катламнарны тегә-тарта,
энәсезе – ком өстендә кәлтә-елан...
**Н**әкъ шулай ук җеп киерткән энә:
тишә-ялгый
кылны кылга, җилне җилгә...
ә җепсезе –
**Е**лтыр сынлы, сукыр күзле:
бер мизгелдән эзсез сүнгән чаткы сыман...
...**К**айчандыр бер
или-или
җил-иләктә калыр бездән нечкә кыллар...
**Ә** җилләр агышы ялгана көйләргә...
...кылларда төенләп гәрәбә төймәләр...
төймәгә төйнәлгән
аң-фәһем, моң-хисләр вә аһ-зар...
**Ш**аять, бер хуш килер:
җил-иләк төбендә
төерле-төерле кыллардан тәсбихләр...

*1995*

*** * ***

*(Акрошигырь)*

*Р.Абзаловка*

**А**л кулыңа моңлы тальян-дустың,
**Б**армакларың тиеп сыйпалсын,
**З**иреклелең вак-вак дулкыннары
**А**к төймәләр буйлап чайкалсын...
тулган күңел, әйдә,
чайпалсын.
**Л**аеш шулпасын да Чишмә-йортның
**О**ныттырмый, хисләр чишелә...
**В**акыт өйгән еллар, юшкын сыман,
тальян көйләреннән ишелә...

**Р**әшәләре Бүле буйларының
**И**делсуда саклый чыраен,
**Н**игез ташын сыйпап үткән җилләр
**А**вылына ялгый малаен –
**Т**альян гармун кочкан агаен.

**А**й,
күңелнең нечкә халәтләре!

**Б**олгар канлы кыпчак егете
**Ы**руг буйлап үзен,
җанын чәчә,
**Й**әшәсен дип яшьнәп өммәте.
...үзе баскан текә үрләрдән
яшь бөркетләр чөю күкләргә –
чынга ашкан
остаз өмете...
**А**рышларның тулган башакларын,
**Б**ез беләбез, талгын җил бөгә,
**З**еңләп чыга тальян талпынуы –
**А**ңа җил ни,
аңа ни йөгән!
**Л**язем шулдыр – язмыш арбасында
үз кулыңда
тормыш дилбегәң!
**У**к очканда өнсез очамыни?!
**Л**әкин тавыш арттан сузыла,
**Ы**ргыл күккә,
Чишмә азаматы,
**Н**ык эзләрдән тарих языла...

Бу көз – синең ил-ир булып
туган фасыл:
**А**лда әле акыл йомгакларың киләчәккә таратасы,
онықларның
җеп очларын югалтмавын кайгыртасы...

*1995*

*** * ***

*(Р.Миндияр концертыннан соң)*

Безнең гомер –
дөнья кабыннан алып кабызылган шырпы:
әлеге мин каләм тибрәткән,
син укып фикер көйрәткән мизгел –
янып торган ут өлеше...
бөгәрләнеп суынып барган күмере –
узган гомер...
Бер берәүнең бармак очына кереп югалган өлеше –
яшисе калган гомер...

*2004*

*** * ***

*Улыма*

Син күк булсаң –
нәфес бер кош булсын,
кош сайравы тулсын күңеленә.
Нәфес күге җирне капласа да,
Булма бер кош нәфес күгендә.

*2006*

### *Безнең җизни мунчасы*

Чәт-чәт! Ah-oh! Чәт-чәт! Чәт-чәт!
Менә оҗмах, менә хозур, менә ләззәт!
Буыннардан и тарала җанга рәхәт –
Чәт-чәт! Рәхмәт! Чәт-чәт! Рәхмәт!

Уңнан сулга, сулдан уңга
Зыр-зыр куып парны,
Яңа каен себеркесе
Эретә аһ-зарны.

Башта сыйпап чыга, аннан – чукып,
Очына аркада – ләхәүлә!
Әйтерсең лә очкан гәүдәң күккә,
Җаның гына ята ләүкәдә.

Яна арка,
Яна колак,
Түз-түз-з, йөрәк!
Әйдә, җизни,
Чәпә ныклап, аяк терәп!

Томырасың чүмечтән су кызган таш-ш-ка,
Күтәрелә пары – җаны чыж-ж-лап таштан,
Күз йомыла, сулыш – тирән, йөрәк – дөп-дөп,
Утырасың миллек иснәп, һушлар китеп.
Түшәмдәге алтын сагыз куыклары
Нарат исле, урман исле итә парны.
Карлы-бозлы инеш суы ләгәннәрдә,
Салкын сыра ташып тора касәләрдән.
Яшәрә тән,
Яңара хис,
Җайлана җан,
Чолганам да купшы парга, ишек ачып,
Ай нурында җем-җем килгән көрткә чумам!
Йөрәгемдә – тау бөркете, мең яшәрлек,
Сөякләрем шундый йомшак – бау ишәрлек.
Тәм сизәсең – гүя җәннәт бакчасында,
Чабынып кара безнең җизни мунчасында!

Бу дөньяда могҗизалар сигез икән,
Мунчаң, җизни, могҗизага тигез икән!

*1985*

## *Ташъязмалар*

*(Татар теле турында уйланулар)*

### 1

Түрк кара камыг будун анча тимис
иллиг будун әртим
илим әмти каны
кәмгә илиг казганурмән тир әрмис.
(Төрк халкының бөтенесе шулай диде:
«Дәүләтле халык идем,
кайда инде дәүләтем?
Кем дәүләте өчен хәзер тырышам?»)

*Орхон[1] язмаларыннан.*
*«Зур язма», VIII гасыр*

**Кереш сүз урынына**

Борын-борын заманда,
Казан атлы калада,
Бер көн бер ел торганда,
Бер ел гасыр булганда,
Хәләле дә, хәрәме дә

Бер кочакка тулганда,
(Хәер, алар һәрчакта
Бергә бугай кочакта),
Баш исәнгә юанып,
Казанында болганып,
Яшәгән, ди, торган, ди,
Татар атлы бер халык.

Бу халык булган эшчән,
Тәм таба белгән эштән,
Тик берчак хәтәр давыл
Акылын алган савып,
Шул ара әмәл табып,
Күршедән акыл алып
Кышын урак урган, ди,
Җәен буран куган, ди,
Аннан тагын көн дә төн –
чит-ят гореф-гадәте,
чит-ят килеш-килбәте
Сеңгән җим белән бергә.
Аңы тел җуяр хәлдә –
Намы җан бирер мәлдә...

Давыл булган бик көчле,
Түбәтәен йолкышлы,
Миен-аңын эчешле.

Тимер бөгәр беләкләре,
Өзелеп сөяр йөрәкләре,
Моң тулы күңелләре
(Алсак авыл җирләрен)
Ни гаҗәп – исән әле.
Көрәшләрдә кем батыр,
Сугышта шаһит ятар,
Геройлыкка дан сатар
Иле югын онытып? –
Кыйбласын җуйган татар.
Җыр-бию дисә халык,
Сыздыра гармун алып,
Унга түгел, меңгә бүлә,
Җанын уртага салып.
Бар дөньясы – җыр-моңы...
Саумы, татар, акылың?
Җир шарын, татар илен
Шакый акыл гасыры!
Уянмый, йоклый халык,
Дилбегә, йөгән алып,
Күрше көлә бот чабып,
Кидереп сиңа камыт.
Акыл дигән чәчкә-гөл,
Акыллы җанга сизгер...

...Укучым, зинһар, гафу ит,
бер балык башы дисәң,
Тагын бер фикер әйтәм дә
сүземне дәвам итәм.

Ни кылыйм, үзең беләмсең,
сызласа әгәр тешең,
Күргәнең күрмәс буласың,
Түземең, хәлең җуясың,
Йә тешең суырып аласың
(Шул чакта тешсез каласың,

Йә инде ят теш куясың),
Йә эзлисең бер чара,
Терелү өчен дәва.
Менә шул, миңа калса:
Татарның сызлый аңы,
Акыл-зиһен сызлавыннан
Үз башын чабар чагы.

**2**

**Ташка мәдхия**

«Йәгирми күн олырып, бу ташка бу тамга күп,
Йолыг Тегин битидим» (Егерме көн утырып бу
ташка бу тамга салып (мин) Йолыг Тәгин[2] яздым).

*VIII гасырның 34 нче елында*
*Билге каган[3] ташъязмасыннан*

Ташка рәхмәт, рәхмәт хәтер өчен,
Таш маңгае саклый сырларын,
Бу сырларда төрки бабаларның
Ташка күчкән өмет-кыллары.
Ташка рәхмәт, комга әйләнмәгән,
Әзме тигән яңгыр, боз, җиле...

Бу таш түгел, бу бит җанлы ядкарь,
Бу таш түгел, бу бит төрк теле.

Кемдә акыл? Адәм, синдәме ул?
Әлифбасын сыйдырмаган башлардамы?!
Әллә
    хәреф йөзен югалтмаган
Гасырлардан килгән ташлардамы?
Кем күңеле таштан, ташмы таш күңелле?
Адәм, күңелең таштан түгелме?
Кемдә хәтер, адәм, синдәме ул,
Йә таштамы исән ул хәтер?
Нәрсә хәтәр бүген?
Ден салганны көтми,
Бикли адәм җанын – шул хәтәр.

Ник соң хатны ташка язган дисәң,
Җавап табу моңа бик җиңел:
Нәрсә исән бүген?
Ташлар исән,
Ташны сайлау тикмә хәл түгел.
Булган агач, әзме тире булган,
Парчасы да – булган барчасы,
Без татарга җитсен диеп хәбәр,
Кирәк булган ташка язасы.
Күкрәгенә ташның шатлык-хәсрәтләрен,
Батырларның исемен уйганчы,
Хәрефләрен тапкан, тапкан таман имла,
Әлифбасы булган ап-ачык.
Шуңарчы да такталарга сызган,
Тиреләрдән дәфтәр ясаган,
Күмер, акшар – әзме эз салгычлар –
Вакыт корты – еллар ашаган.
Чынаякка тамга сырлар яткан, –
Сүзләр – ширбәт сөтле чәенә,
Сөйгән яры сызган теләкләргә
Кемдер чәйдән күбрәк сөенгән.

Җирдән килгән – җиргә китә торган,
Күктән иңгән – күккә юнәлгән,
Әйтсәм әйтим, җирдә, суда, көлдә
Башың-күзең, татар, күмелгән.
Уйлап баксаң, ул күмелгән ташлар,
Андагы сүз, хәбәр, истәлек,
Татар, сине күккә күтәрерлек,
Татар, сине татар итәрлек.

Олуг Хем[4], Би Хем[5], Урхун[6] –
Сулары елгыр, салкын,
Ташъязмалы елгалар
Сагынадыр төрк халкын.

Енисей да дибез, Орхон дибез,
Күлтәгин[7] ташларын шәйлибез.
Тагын шул ун-унбиш ташъязма,
Чәйнибез шуларны, чәйнибез.
Рәхмәт сиңа, олуг Йолыг-тәгин,
Синең кулың җиңел булганга,
Үз илеңне, халкың сөеп язган
Язмаларың ташта сакланган.
Белсәк тә без, белгәнебез – учта,
Тау кадәрен без бит белмибез.
Сизенсәк тә – сизгәнебез учак,
Янартаулар утын без бит сизмибез.
Күпме ташлар җиргә-гүргә иңгән,
Азмы ташлар суда югалган,
Моңга манма күпме ташъязмалар
Түшәлгәндер ваклап юлларга...
...Кем теләми – (сәбәп төрле булыр),
ул аңламас мине бу мәлдә,
(дәлилләрең таулап өймә дә).
Кем уйлана, үзе эзли җавап,
дәлилләрен йөзләп, меңләп таба
дастаннардан,
китап, ташлардан.
Шөкер әле авыз итәм дисәң,
Күчтәнәчләр әзрәк сакланган.

...Язганнарым сиңа түгел, битараф җан,
Синең күңел кымшанмас та, кая аңлау,
Татар булып төрк нигезгә битарафсың,
Сәҗдә кылу юнәлешең ни тараф соң?
Җаны булган бер уйланыр, ачылыр да, –
Тик...
соң булыр милләт диеп ачынырга.

**3**

**Вакыт – игәү,**
**халык – таш,**
**ил-йөзеккә асыл каш**

Ни газизрәк – бу ватанмы?
Аһ, туган каүмем газиз!
Ул мөкаддәс кан белән ул
Изге сөткә ни җитәр!..
Сөт калыр, ватан китәр!
Сөт калыр, ватан китәр!

*Дәрдемәнд*

Бер алмазны ком итеп тә була,

Җәүһәргә дә нигез шул алмаз,
Кырлар салсаң чарлау җаен белеп,
Мәңге яшәр алмаз, югалмас.
Вакыт – игәү, игәү тешләренә
Халыкмы ул, телме – барыбер,
Вакыт белә чарлау, игәүләвен,
Исән калу ягын үзең күр.
Асылташ та булдың игәүләүдән,
Чаткы очып торды күп гасыр.
Йөзек кашы булып яшәр өчен,
Табылмады җайлы кысасы.

Йә зур булды кыса – тулды чүп-чар,
Асылташны кайчак җуярлык,
Йә бу кыса кысты шулай итеп,
Ком бөртеге генә сыярлык.

Уйлансам да, бире җавап булмас,
Кысага да сылтау риясыз,
Вакыт күргән, Вакыт тәңгәл белә –
Кайсы чордан милләт кыйбласыз...
Тарих калсын галим, тарихчыга,
Тиз утырмас бәхәс – вак эзләр,
Гасырлар да үтәр, меңәр еллар,
Яңа милләт янә эз эзләр.
Тарихчылар әйтә тора сүзен,
Авыз итеп Вакыт сереннән,
Ә дәүләтләр тәсбих төймәседәй
Тезелә бара төрки җебенә.

Кыйбла юкта җил дә исми хәтта,
Җилгә кыйбла – һава җылысы.
Төрки халык дәүләт-җирен җуйган,
Алмаштыра торгач кыйбласын.
Тәңре үзе кыйбла булган чорда
Табигатьтән килгән көч-ирек,
Җиргә, суга, утка, агачларга
Туганлыгын белгән күк төрк.
Илаһи көч төрккә күктән – Тәңре биргән,
Аннан Ислам кергән – татар, Алла, дигән,
Соңрак татар җанын Иблис алган икән,
Ул Тәңредән көлгән, Аллага тел тигән.
Кыйбласыз калмаган: каештан шәп йөгән,
Остазын тартырга камытын да кигән...
Бер кергәч тәртәгә – ат булгач мәртәбәң,
Бер – чыбыркы, бер – торба: атка тагын ни кыйбла?!
Типкәләмә тәртәгә, алҗыма дулап-дулап,
Сындырсаң да тәртәсен, дуласаң-типсәң дә син:
«Нишләмәкче, татар-ат, что тебе ещщё, дурак?!»
Атка тел кирәк түгел, пошкыра бел, кешни бел,
Кешнәү – димәк, йөк җиңел, пошкыру – торба* җиңел...
...Ахры, беркөн калыр телдә шул ике исем-фигыль.

...Вакыт – игәү. Игәү тоткан куллар
синең кулмы татар, ач күзең?
Асылташның көзге-кырларында
Чагыламы, татар, үз йөзең?
Вакыт – игәү,
ә бу игәү үзе
Нидән пәйда булган дигәндә,
Уйланулар, хәтер, сызланулар,
акыл-кырлар ята игәүдә.

Акыл юкта – юк игәү дә, игәүләү дә,
Кызыгыйммы мин мизгелләр санаганда
Мәңгелектә яши биргән Җүләрләргә?
Сайлый калсаң алсыз-артсыз, моңсыз хәят,
Чабам дисәң, халкым, вакыт канатларын,
Бул бер кантар, бул бер агач, бул бер бөҗәк,
Җуй акылың, оныт илең, оныт барын.
Игәү дә юк, Вакыт та юк, юк Халык та:
Бар Мәңгелек! Шул халәттә! Шул минуттан!
Бу җәһәттән мин сайлыймын – Игәү,
Вакыт сине, димәк, иң элек,
Мәңгелекме, Мәнлелекме дисәң –
Минем сүзем кыска: Мәнлелек!

## 4

## Тел чишмәсе...

Әйе, бу, Тәңре, синең
Безгә белемсез серләрең;
Без, зәгыйфь коллар, беләлмибез
Каанлык серләрен...

*Һ.Такташ.*
*«Җир уллары трагедиясе»*

Элгәреге төрк кавеме – мәҗүсиләр...
Дәлилле дә кебек иде шушы сүзләр,
Тик бервакыт
тамчы-тамчы җыелды да уй-фикерләр,
Инеш булып чылтырады яңа хәбәр.

Бөек күк-төрк каганаты[8] җирләрендә,
Төрк халкының үзәгендә, йөрәгендә,
Дзэн-фәлсәфә* – җан-фәлсәфә туган икән,
Җан-шигърият җан азыгы булган икән,
Шигъри юллар аталганнар коан** диеп,
Ә татарга килеп җиткән ул кан диеп.
Кем әйталсын, бәлки кыска-серле – юллар,
Канга манып, КОАН итеп язылганнар?
Ә каганат? Тамырына кем күз салган?
Кан сүзеннән түгелмени: каан-каган.
Кан кешенең җан йөрткече булган кебек,
Коаннарда эретелгән ДЗЭН-ҖАН җелек.
Шулай булгач, төрки телнең нигезләрен
Җан-шигърияттән, коаннардан бит эзләрлек.
Татар теле, төрки телнең күп серләрен,
Тирәнгәрәк батыруын фикерләрне,
Ахры, шул ук фәлсәфәдән эзләү кирәк.
Җан телендә аңлашучы бүген сирәк,
Коан юлларын ачу өчен, аңлау өчен,
Адептлар* да куя кайчак еллап көчен.
Саклый икән гасырларда дзэн-җан серен
Дзэн-Җан дигән серле япун монастыре.
Кичер, Тәңрем, серләреңнән авыз итсәм,
Мин бер тамчың, фал салырга җөрьәт итәм:
Төрки телгә Җан-шигърият көмеш чишмә,
Татар теле шул чишмәдән инеш икән.

## 5

## Рун язуы**

Энҗе алмаслар югалмас

Һәм ятып калмас – үтәр.

*Дәрдемәнд*

Холыклары кискен, үткен булгач,
Тамгалары очлы уклардан,
Яшен булып яткан кайсылары,
Кул бармаган койрык, чукларга.
Каләм эзе, йомшак затлы дәфтәр
Еллар белән бергә тузса да,
Язган инде кайгы-хәсрәтләрен,
Шатлыгын да язган, нәфрәтләрен,
Кирәк икән, каурый каләмен
үз канына манып булса да.

Рун язмасы – уңнан сулга,
күз алмасы – уңнан сулга,
Бу уңайга җайлы итеп
сул кул белән ята язма:
Язган-сызган капланмасын,
Һәнҗәр, камчы тотар өчен,
Көчле, җитез уң кул калсын.

Тормыш үзе гамәл иткән язу җаен,
Авазларга бәйли барган угын, аен,
Мохит биргән төрккә тәүге дәресләрен,
Җисемнәрдән шәкел кылып хәрефләрен.
Тау елгасы – уңнан упкын, сулдан упкын,
Яшәүгә тиң күчү юлы – басма күпер,
Бу күперне ничек булсын хәреф итми,
Ничек инде шул уңайдан итмик шөкер.
Ике яклы ыргак ята җөмләләрдә,
Дулкын булып күчкән дәрья хәрефләргә,
Балык чиртми каламыни әлифбада,
Тау-елгалар кичкән бит ул төрек бабам.
Алган ул таш йә тиредер (шул пергамент),
Язган хатлар, тасвирлаган чоры гамен,
Урхун елга буйларында җанын телеп,
Хәрефләргә утызлап сын, җанын өреп.

**6**

**Әлифба**

...Индейцы майя своими же руками уничтожили собственное письмо, поверив какому-то жрецу, устами которого «глаголил сам бог» и нет сейчас майя. Каждый несет свой крест...

*А.Мартиросян. Из кн.: «Маштоц»*

Себер буйлап, Идел буйлап, диңгез буйлап
Татар ия төбәкләрдә
Чират, чират, чират.
Утыз гасыр язган-сызган
Төрки ир-ат
Зар төерен йота-йота,
Кыпчак-җирдә, Идел-йортта,
Гарьлегеннән башын бөгеп,
Яңабаштан әлифбага басты чират.
Иван бабай[9] мәсәленнән өч җан кеби
Тәмам талды әлифбаны
Өч тарафка сөйри-сөйри.

Өч чиратта татар варисы.
– Нихәл, татар?
– Ярый, ярыйсы.

Мәскәү бәе кәләпүштән иде,
Йоталганча сезгә ирек, диде,
Кайтмасмы дип ден саклаган имла,
Чират бастым әле, шаять, читтә калмам.
Кашгарый[10] да, Кол Гали дә, Исхакый вә Тукай,
Язган көйгә укырлар дип өмет иткән бугай.
Һәр йозакның үз ачкычы, бу бер гади мисал,
Җыйган акылың ничек ачмак, әгәр имлаң җуйсаң?
Ун дистәләп гасыр,
Дүрт дистәләп буын,
«Әлиф», «би», «ти», «си»дән
Алган ислам нурын.
Коръән Кәрим берлә
Иңгән хәрефләре,
Гарәп имласыннан
Изге аятьләре
Уңнан сулга яткан
Салмак бер көй сыман,
Теге, горур вакыт,
Теге, тымат* заман.

Гасыр белән гасыр
Күрешкәндә берчак,
Саба җиле булып
Килгән иде форсат,
Шәмаилдән ары
Сүнде гарәп сыры,
Ислам агачының
җанлы тамырлары.

...Хәер, моңсу истәлекләр
канатлы ат кебек,
Очты нәсел-ыру буйлап
хәтер-арба җигеп.
«Әби җаным, әйтмәссеңме,
Дөресме соң күрдем,
Нацар Убый[11] чишмәләре,
күк йөзләре көлдә?»
«Дөрес, балам, күргәнсең син
Нигез тузган көнне,
Сөннәт бабаң[12] китапларын
Утка тоткан көнне»,
«Әби җаным, өйрәт инде,
Ошбу имла җаен»,
«Юк, кирәкмәс,
хәрәкәләр
хәтәр ул, улкаем».
Бабам кулы сырлап барган хәрәкәле имла –
Төрмә төргән, еллар кичкән ядкарь минем кулда,
Хәреф җыям уңнан сулга, ирен кыймылдатып,
Чыккан бер сүз йөрәгемне ала чымырдатып...

...Сүз каттым мин башка якка,
Көнбатышка карап
Татар өчен имла диеп
Яңалифкә чират.
«Яңалифкә – яңалыкка, тәрәккый офыкка,
Латин язма – рун нигезле, шуны да онытма!
Яңалифкә күчү түгел, кайту була, димәк,
Рун язмасын кайтарабыз бүгенгегә көйләп.
Җирдә, айда – санак кайда, шунда телгә оя –
Имлаларың санак өчен таман булса гына».

...Уйнап тора кирилл аты,
Сыек сырты – әлифбасы,
Койрыгында тигәнәктәй
алты хәреф ярты гасыр
киләчәккә җилтерәтә
горур татар әлифбасын.
Кирилл аты тибә каты,
Кирилл түгел, кырыл! атлы.

...Чират, дидем,
Өченчесе –
чират түгел, җигүле ат,
Чук койрыклы күрше аты,
Шыгыр-шыгыр арба җиккән,
Арбасында яткан көйгә
татар тәсбих тарта икән:
«Әлхәмделилла»,
«Кругум җиткән»,
«Кругум җиткән»...
Алда сазлык, уңда сазлык,
сулда сазлык, артта сазлык:
Җиткән генәме соң – ашкан чиктән!
Бер юл кала – өскә таба,
Өскә таба, хәтерләсәң, тулпар чаба.
Өскә таба!
Өскә таба!
Тулпар атка
бирсә канат
очу көчен,
Таман имла – шул ук канат татар өчен.
«И тагын шул имла бозу, җәдит диеп», –
Арбадагы аркадашлар бара көеп,
«Кирилл-имла телгә үтте ике буын,
Әйдә, калсын варисларга ядкарь булып,
Форсат булса тарих үзе табар җаен,
Надан булып калмабызмы буын саен?»
...Шул арбада йоклый татар тәсбих тотып,
Шул арбада йоклый татар телен йотып,
Шул арбада йоклый татар, тәре аскан,
Шул арбада йоклый татар, дене качкан.
Вакыт-вакыт уянгалый дистәләбе,
Этә-төртә сөрән сала: «Тор, җәмәгать!
Уян, татар, бетә милләт, бетә лөгать».
Әллә җилдән, әллә сүздән вакыт-вакыт
Күз кабагы тартып куя кайчак кылт-кылт.

Уянуга, күреп хәлең, очар котың,
Уянма да,
Йокла, татар, тыныч йокы!

Йоклый татар,
Телгә баткан «кырылл»-кармак,
И суыра телне кармак җайлап-җайлап,
Теш суырту яман нәрсә, тик юк шигем,
Тел суырту – иң ачысы, һич юк тиңе.
Инде шул да уятмагач, татар, сине,
Ахры, Тукай сорау куйган алдан сизеп[13],
Үзәк өзгеч җавабын да үзе күреп.

Күп калмады
Исхакыйның фаразына[14],
Йөз ел җитте
Ике йөз ел барасына.

Әрнеп әйтәм,
Түгел көлү, түгел коткы:
Юк, уянма,
Йокла, татар, тыныч йокы!..

**7**

**Татар теле**

Киселде башлар, тиделәр,
Тик телгә тидертмәдек...

*Х.Туфан*

Сабантуйда алкышлардан тыгыз җәймә –
Шул түгелме чабышкыга бәхет мәле!
Вак-вак кына уеп бара аяклары,
Әйтерсең лә токмач кисеп шул җәймәдән.
Яшел үлән – үтә яшел, җилләр йомшак,
Ат яллары ятьмәсенә капкан кояш,
Тояклары гүя гармун төймәләре –
Баскан саен гүли мәйдан – бәйге-көрәш.
Бәйге аты – сөлек сынлы, баш – болытта!
Аяклары – җәя дә кыл, юк юл бирү!—
Маңгаенда ярылып ята беренчелек,
Ай тамгалы кашка уктай – җиңү, җиңү!
...Соңгы мизгел,
Әйтерсең лә дары буйлап ут өермә –
чаба атлар!
Алкыш тулы мәйдан гүя дары базы:
Тулпар атның күкрәгенә тасма тигәч,
Мәйдан дәррәү шартлар...
Татлы мизгел керфекләрне сыйпаганда,
бу ни хәл бу?!
Гамьсез гавам, күз алдыңда
Иң алдагы бәйге атын
аркан атып
ектылар да,
кысып, буып,
бугазына терәделәр үткер пычак...
Фараз иткән бер зур түрә:
– Һич юк шигем, җиңә, дигән, минем рысак...
Тып-тын халык, елтыр-елтыр – бугаз эзли кәкре пычак.
Бир бер мизгел! Йолдызларны тулпар узар!
Мәйдан кысан, дөнья кысан, җиһан кысан...
...Сизәсеңдер, и укучым, җепләр каты:
Татар теле шул ук тулпар, бәйге аты.

**8**

**Мәгънә – дәрья,**
**Балык булып фикер йөзә...**

...Тел ясалмас, гәр туган сүз ятмаса үз ибенә...
...Тел – вөҗүд*, сүзләр бәдәндер, сарфы** вә тәркибе*** – рух

*Дәрдемәнд*

Әйдә, Җаным, икәү бергә
Канат бирик Җанлы телгә.
Без өч кунак ошбу тәндә,
Без өч хуҗа ошбу тәнгә,
Үз холыклы, үз мәгънәле,
Җаным син дә,
Мин фәкыйрь дә,
Җанлы тел дә.

Тел ул – Һава,
Тел ул – Диңгез,
Тел ул – Җир дә!
Кошлар кебек тезмә-тезмә
оча сүзләр Тел күгендә,
Балык булып фикер йөзә
Тел диңгезе төпләрендә.
Рәт-рәт булып аваз, сүзләр җиргә төшә,
Тел җирендә шау-гөр килеп милләт үсә.
Күзаллагыз, йөзем ничек үсәр иде,
Таянырга бер-бер терәк булмаганда,
Чал тарих та, милли аң да шул ук хәлдә,
Җанлы телне терәк итеп алмаганда.

Дала киңлекләре бер зур казан төсле,
Кайнап торган шулпа – гомум төрки теле,
Шәкелләргә тула, сайлый кулай вәзен,
Телнең җаны булып – дала фәлсәфәсе.

Җөмләләре –
сыгылмалы ныклап үргән
чыбыркыдай
салмак кына әйләнә дә тел очында,
Әйтер сүзнең азагында
көтмәгәндә чатнап шартлый,
йә тавышсыз, иpләп кенә төшә сыртка,
йә булмаса йомшак кына сыйпап ала,
Күп сорамый чеметкәләп алырга да,
Сузылып ята тыныч кына кайчагында,
Соң мизгелдә төп фикергә мөхер суга,
Чыбыркының шартлаткычы – фигыль-фәрман.
Бөтен яме, көче-тәме шушы кылда.
Җөмләләрнең тел чугында юк ниндие:
Кыскасы да, озыны да, катлаулысы һәм гадие
Җанлы телнең төпсез серле сандыгында.
Камышлыктан аучы көткән киек сыман,
Килеп кунды шушы җөмлә тел очына:
«Авылга, урманга, җимешкә, миләшкә кайтканда,
бакчада кояшта рәхәттә ятканда,
Чишмә[15] буйлап алып китә фикерләрем – юктыр чиге:
авылдагы шәүриндәге – инештәге – көмештәге –
ак нурдагы
ялтырауның – сихеренең – тәэсиренең –
файдасының – күплегендә юктыр шигем!»
Йомшак та син, телем,
җәеп сузыкларың,
Кырыс та син, телем:
кыска фәрманнарың.
Төгәл дә син, телем,
Тирән дә син, телем.
Синдә туа, ныгый
җаны мөтәтелнең*:
«Ни белән
ниләрне
нибары
ничектер
ниеннән
ниткәндә
нигәдер
нителде», – дигәндә –
Мәгънә-дәрья бире,
Кара сүтеп-үреп!

**9**

**Татар теле әйтер: «Ядәч!» – дип**

...Сөт имешкән һәмдәмемдер*, кан әнисемдер телем,
Җан биреп күнмәм хәрим** вә асылдан тәгърибенә***

*Дәрдемәнд*

Аккош кала аккош булып,
Канатлары чатнап сынып
Ятканда да дулкын кочып.
Тел бит ул – җан, тел бит ул – моң,
Үксер дөнья, тел югалса,
Соң булыр, соң...
Телсез – милләт, денсез – мәчет булмас,
Телсез милләт шытмас яшьләрдә,
Килер заман, терсәк тешләр идең,
Терсәгең дә булмас тешләргә!

И туган тел, и асыл тел,
Яклауга син мохтаҗ –
Иң бөек яд,
Иң затлы таҗ,
Мәңгелек хаҗ.

Татар телен күмер итсә күңел,
Оныгымда булса телгә чик,
Татар диеп эндәшмәгез миңа,
Ышанмагыз миңа мишәр дип.
Татар теле үги бала булып
Күкрәгеңдә үксеп ятканда,
Килешәме тылмач кирәкми дип
Дөяләнеп йөрү татарга.
Тылмач кирәк үз телеңнән, татар,
Күңелеңдә «кырылл» тамгасы,
Татар телен ваклап-күпләп сата
Читләр түгел, татар баласы.

Нигә, Тәңре, төрки телнең биләве аһ-зардан?
Ни дип, Тәңре, син шул телне
бирдең икән мин татарга?
Әллә берчак булдымы төрк үз теленә лаек?
Ышандыңмы, бу милләттә өмет-куәт тоеп?
Юк, ялгышмас бөек Тәңре,
Түкмәс мәрҗән җилгә,
Тәңре биргән илаһи тел
Яшәр азат илдә,
Яшәр иңгән җирдә,
Яшәр, татар, синдә!
...Ышанасым килә, ышанасым килә.

Булган җаның салып түбәтәйгә,
Тапсаң үзең эзләп әҗәлең,
Татар, сине җәлләп яшем чыкмас,
Татар теле булыр иң җәле!
Күмелсәң дә – үзең, күмдерсәң дә,
Тик үзеңдә моңа сәбәп бит.
Ә тел – изге,
Язмыш: «Бәхәс!» – дисә,
Татар теле әйтер: «Ядәч!» – дип.

**10**

**Тел һәм Үрмәкүч**

... Мөддәгыйләр* рәдденә** гәр җитмәсә сүзем дәлил,
Түккәнем күз яшьләрем җитсен алар тәэдибенә***

*Дәрдемәнд*

Килде заман, сизәсеңме, татар, телләр
Чират тора бүген сират күперендә,
Яңа гасыр алыплары – компьютерлар –
Телләр сайлый тәңгәл итеп шәкеленә.

Нейтрон бомба шартлаудан да дәһшәтлерәк,
Күренмәс газ тасмасыннан күпкә зәһәр –
Җир шарында компьютерлар-үрмәкүчләр
Көне-төне армый-талмый үрә челтәр.

Пәрәвезгә бөҗәк түгел, адәм түгел,
Җыела бара хәбәр, фикер, хәтта күңел,
Челтәрдәге аң-белемгә хуҗа кемнәр? –
Үрмәкүчкә таныш булган җанлы телләр.

Өйрәтмәсәң Үрмәкүчне үз телеңә,
Киләчәгең ачык, татар: юк – бүгеннән!

Юл бирелсә, димәк, бүген – мәңлелеккә,
Санак илтер Татар телен – мәңгелеккә.

*1994 – 1995*

**Аңлатмалар**

[1] Орхон – Улан-Батор (Монголия) шәһәреннән 400 км ераклыктагы (көнбатышта) елга исеме.
Орхон язмалары – Орхон елгасына койган Кокшин-Орхон яры буендагы таш баганага рун хәрефләре белән язылган төрки язмалар.
[2] Йолыг Тәгин – Күлтәгиннең туганы, ташъязмалар авторы.
[3] Билге каган – (Белүче, акыллы каган), Күлтәгиннең абыйсы Илтәреш каганның олы улы каганлыкка утырганда (716 – 734) алган исем.
[4] Олуг Хем – Өске Енисей елгасы.
[5] Би Хем – Зур Енисей, Енисейның Тувадагы өлеше.
[6] Урхун – Орхон елгасы.
[7] Күлтәгин – күк төрк каганатында гаскәр башлыгы.
[8] Төрк каганаты – VI гасыр урталарында хәзерге Төньяк Монголия җирләрендә оешкан, Каспий диңгезеннән Корея култыгына кадәр җир биләгән дәүләт.
[9] Рус мәсәлчесе И.Крыловның «Аккош, кысла һәм чуртан» исемле әсәренә ишарә.
[10] Мәхмүд Кашгарый – «Диване лөгатет-төрк» әсәренең авторы.
[11] Нацар Убый – Кызыл Чишмә авылының иске исеме (Чувашстан республикасы, Батыр районы).
[12] Сөннәт бабай – Сөләйманов Сөннәтулла Сөләйман улы (Кызыл Чишмә авылы мулласы, 1937 елда совет властеның үлемен көтә дип репрессияләнгән, 1989 елда акланган, соңгы хаты Екатеринбург төрмәсеннән 1939 елда килгән).
[13] Г.Тукайның «Татар халкы үлгәнме, әллә йоклаган гынамы» исемле мәкаләсенә ишарә.
[14] Г.Исхакыйның «200 елдан соң инкыйраз» исемле әсәренә ишарә.
[15] Чишмә – Чувашстандагы Батыр районы Кызыл Чишмә авылы (элгәреге атамасы – Нацар Убый).

## *Тамырлар*

**1**

...Кызыл Чишмә. Арт бакчада.
Бәрәңгедә халык.
Әти шунда,
Шунда әни,
кызым, улым.
Бакча тутырып
җир елмаямыни –
Сызылып яткан буразналар
бәрәңгегә тулы...

...ә бәрәңге
уңмас кебек иде –
язын яңгыр иште,
җәен челлә кисте,
көз кергәндә генә,
җуеп үз фасылын,
җиргә ак кар төште...

...ә бәрәңге уңды...
вакытында җиргә яткан орлык
тамырланып калган икән
вакытында,
вакытында тойган икән
җир җылысын,
вакытында
кирәккәчә сабакланып,
чәчәген дә вакытында аткан булган –
җир алмасы...

...ышангандыр туасына,
сыена белгән,
язын орлык булып җиргә яткан,
алмасына үзен ризык иткән
бәрәңге-күз анасына.
...Хәзер инде үзләре үк әзер
Җим булырга баласына...

Уйларымнан
кинәт искән
Җил аера...

...Җилкәм тоя,
иңбашыма
чәчен тидергәндәй бер зат.
Кул-битләрен ялый, тия колагыма...
Күрәм –
Коңгырт күзле
Чем-кара ат –
Әле генә сука тарткан
карт алаша түгел –
биеп торган
ут-аргамак...
Ун гасырлар үтеп килгәнмени
Алмас хан тулпары!
Биләр якын – ул йөрәктә,
Биләмәсе уч төбендә – авылымнан
Бер йөз чакрым...

...Сизми калдым,
ничек атланганмын –
Инде куллар каеш йөгәндә,
Әйдә, тулпар,
Алыш җилләр белән,
Әйдә бер кагылыйк
Безне танып белгән
җирләргә...
**2**

Җил-җил Җил исәдер лә,
җир-җир Җир оча бирә,
чор-чор Чор үтәдер лә,
чаң-чаң Чаң суга йөрәк.

Гасырга гасыр ята,
Гавам имтихан тота,
Файдалан бу форсаттан –
Кыйблаңны барла,
татар!

Җилләр исә,
җилгә – исү кыйбла,
Курай тишекләре –
йолдызлар...
Галәм көйли –
җилләр хәбәр сөйли,
Татар моңын суза кубызлар.

Җил булмаса – орлык ерак очмас,
Җил булмаса – кайдан хәрәкәт?
Җилкәннәрен киерсенгә дөнья,
Җилләр өрә җиргә бәрәкә*...

Җитез дә син, салмак та син,
Җил – бер хәтер, тоташтан.
Кылган шавы, әрем исе
Кайдан килеп тоташкан?

Җил тасмасы чал тарихтан,
Чын тарихны җил белә.
Туза ташлар – уза гомер,
Исән-имин – җил генә.
Биләр, Болгар, Юкәтауның[1]
Тирбәткән бишекләрен,
Шул ук җил-давыл туздырган
Пайтәхет[2] ишекләрен.

Җил бүген дә шул ук җил ул,
Шул ук җил галәм сөрә.
Җил, сиңа сүз –
сиңа мөнбәр,
Суз тасмаңны,
сүз сөйлә!

**3**

Әйтте җил:

Җи-и-ил, җил, җил-л-л мин,
Җи-и-л мин, җил мин.
Җил-җилбәзәк, җил-давыл да,
Мин күпйөзле, күпкыллы,
Кемгәдер йомшак канат мин,
Кемнеңдер соңгы тыны...

Ә Милләт ул – шул ук болыт, –
Мин куган якка оча,
Күкләр күкрәп, яшен бәргәч,
Яңгыр булып җир коча.
Хәтта мин анык әйталмыйм:
Кайдан төрки яңгыры?
Ул заман, каян иссәм дә,
Күрдем төрки яугирен.

Төрки тамыр –
төрки телгә
Хәтерлим чолганганым,
Шул тамырның
сынап беләм
Ун мең ел чыдаганын...[3]

**4**

Әйдә, тулпар, туздыр ялларыңны,

Уйнат җилне нечкә кылларында.
Җил хәбәрдар төрки тамырлардан –
Җитсен хәбәр татар улларына.

Җил сөйләде:

– Бөек иде бу халык,
Горур иде бу халык,
Җиде күктән куәт алып,
Җиде ил[4] корган халык.

Иске өй иркен иде лә,
Меңәр чакрым киңлекләр.
Скиф[5] илендә җилдән җитез
Атлы төрки-егетләр.
...Рун[6] язмаларын шомарттым,
Хәрефләре – ук та ук.
Төрки-татар иле үсте –
Әйтерсең лә уттан ут...
...Иске эв* тузды кинәттән,
Тузды
Кыйбласын җуеп.
Ут-анасы куәт өрде,
Һун-Сөн дәүләтен җыеп!
Сөн[7] сагышы
елга булып
Ялгый татар җирләрен,
Сөн яугире җанын йөртә
Бүген татар ирләре...

...Куәте-көче болгарның
Кыпчак-төрки дәрьядан,
Сызгыра торган уклары
Оча бер үк оядан.
Әй, татар!
Төрки-кыпчаксың –
Атилладан[8] калышма!
Әйтсеннәр:
Үлсә – пәйгамбәр,
Гыйфрит үзе – сугышта...

Әйтсәң иде, и Атилла,
Юл күзләгән балаңа,
Кайда булды илгә кыйбла
Син яшьнәгән заманда?

Әйтте Атилла каган:

«...һәй, мишәр-болгар-татар!
Һәй, углан, төрки бала!
Мин – синең кыпчак бабаң!
Бишенче йөз – далада.
Бу заманнар – җирдә –
Кыпчак!
Бөркет – хуҗа
Һавада!
Мәшрикъ-мәгъриб арасында,
Ялгап күккә ялларын,
Очты атлар, төрки аты –
Таратып чиксез далага
Төрки-Һун хыялларын...
Бу заман, каян баксаң да,
Төбәлде күзләр миңа.

Дәүләтем – дөнья үзәге,
Мин үзем
идем –
Кыйбла!»

Җиһан ир син Атилла!
Үлемсез төрки бабам!
Ул бит синең замана.
Ул бит минем замана.
Ул бит безнең замана!
Шушы чордан күңелемдә
Татар таңы аллана...
Төрки-Кыпчак-Болгар-Татар –
Ул бит – без бит,
балалар!
Ни бәхет – татар туганбыз –
Рәхмәт Тәңре-Аллага.
Шөкер Тәңре-Аллага!..

Олуг Хем, Бий Хем, Урхун –
Сулары елгыр, салкын,
Ташъязмалы елгалар да
Сагынадыр төрк халкын.

...Алтын Урда – Олы дәрья –
Йөзләп халык – елга.
Татар булып туды шунда
төркиләр: кыпчак-болгар.
Дәрьяларны диңгез итте,
Диңгезләрне – дәрья.
Күктә – кояш, Җирдә – Бату[9],
Булды дәүләт – дөнья.
Дәште-кыпчак далаларын
текте күкрәгенә,
Бизәк чикте Урда-илгә
Болгар җепләреннән...
Нигезләре тирән, тымат булгач,
Ник соң тузды йортың, и татар?
Ник соң һаман җир-су, кыйбла диеп,
Татар җанын телә
шул аһ-зар?..

Табигатьтән иңгән самимилек, –
Әйткән сүзне
аткан ук, диде.
Күршесенең чуклы сүзләреннән
Ил башына йөгән хуш килде.
Туган белән туган арасына
Ат кылы да сыймый дигәндә, –
Төтен булып керде дошман-шымчы...
...Татар һаман шул ук биләүдә...
Җиде дәүләт бер үк язмыш күрде,
Үзе кыйбла булды һәр дәүләт.
Татар йорты үсә-туза торды,
Йә җәһәннәм булып,
йә җәннәт...
Гади булды, артык гади булды,
Үзәгендә иде самимилек –
Гөлчәчәк бит
үсә чәчкә булып
Чәнечкесе барга иң элек!
Татар горур, татар затлы, саллы,
Күңелдә – дәрт, сөю – йөрәктә,

Халык булып мәңге яшим дисәң,
Чәнечкеле дә бул син – кирәктә.

Бу бөек сер – татар яши
Җиде сүнеп җиде янган учак сыман.
Җиде буын үтәр-үтмәс –
Сайлау:
Яшәү белән
Үлем арасыннан...
...Ш-ш-шанлы Биләр,
Бөек Биләр –
Гүя Коръән сүрәсе.
Саф Чирмешән[10] суларында
Унынчы йөз шәүләсе...

**5**

Җил уйнады тулпар ялларында,
Җил көйләде күчеп кылдан кылга,
Хатирәләр буйлап алып кайтты безне
Бөек Биләр кыйбла булган чорга...

Әй, Алмас хан[11], Алмас хан,
Хәнҗәр, җәнҗал алмас хан.
Иң бөек эш ни булыр?
Диде бөек Алмас хан:
– Иң бөек эш шул булыр –
Болгарга пает* булыр,
Гауга, бәхәсләр тынар,
Биләр Пайтәхет булыр.

– Иң тугры эш ни булыр?

– Иң тугры эш шул булыр –
Биләр-йортта таң туар,
Сәбәбе Ислам булыр.

...«Ямь-яшел Җаушер буе,
Юк бер киек, юк бер җан.
Сихри тынлык – юк бер өн» –
Төш күрә, ди, Алмас хан...
«Ай-кояшсыз – нурлы күк,
Күк читендә – ал шәфәкъ,
Алма битле ал шәфәкъка
Үрелә кич – күкчәчәк.
Яшел келәм, алсу офык,
Шәм кебек рәт-рәт бина,
Күңел-бишек чөя сыман
үземне күк катына.
Шундый рәхәт, имеш, җәй...
Күңел нидер сизгәндәй:
Күк йөзендә ак болыт
Күренә аккош булып,
Зәп-зәңгәр күк гөмбәзенә
Эленгән балкыш булып.

Очмый,
төшә салмак кына,
Тавыш-тынсыз, җайлап кына.
Канатлары ни төс димсең?
Тәңгәл көмеш төс кенә,
Күкне каплап төшеп килә

Аккош шәһәр өстенә...»
Юраучы фәкыйрь-әдип
Әйтте сүзен болай дип:
– Бу шәһәр булыр Биләр,
Аккош – ак бәхет, диләр.
Манаралы ак бина,
Ак бинада – ак мөнбәр,
Ак чалмалы аксакал
Сихәтле юлга өндәр.
Ерактан килгән илче –
Хак юлга үткәрүче,
Аккош булыр Дин – Ислам,
Илеңне күтәрүче...

**6**

– ...Юл бирегез! Борылыгыз! –
Галиҗәнап Алмас-хан!
Йә бүрек төшә баштан,
Йә җаның күккә ашкан!

Өзеп базар шау-гөрләвен,
Тутырып бар дөньяны,
Яңгырый Шәһре Биләргә
Алмас патша фәрманы:

– Чистарырга-чистартырга!
Тазарырга-тазартырга!
Килә Багдад илчеләре[12]
Ислам динен яңартырга!..

**7**

Җыеп чүлләр эсселеген,
Татып дала көнчелеген,
Урманнар шавын төреп,
Җитмеш көн вә төн йөреп,
Йөзләгән халык күреп,
Көйләрен җанга үреп,
Күктән төшкән ай булып,
Җанга яткан май булып,
Сәкалибә[13] җиренә
Керде дөя кәрваны.
Барып ирешкән, димәк,
Болгар патшасы зары:

«Бу хәзәрдән[14] тәмам гарык,
Җелеккә үтә талап,
Дине дә ят, сүзе – нахак,
Әсирлектә багалмам.
Нәфесләре бу хәзәрнең –
Идел-елга буедыр,
Йөрәк парәм – кызымны
Кол итүдә уедыр...»

Тагын шулай фикер йөртә,
Зирәк патша Алмас:
«Олы казан төпләрендә
Ит чи килеш калмас»...

Әйтте җир:

– Минем хәтер катлам-катлам,

Син сулыйсың – мин тоям,
И мәгърур болгар баласы –
Кальбеңдә төрки тамгасы,
Төрки катламда ояң.

Ислам гөмбәзе тимәсме
Төрки җепселләреңә,
Төрки тамыр киселмәсме
Ислам шәкелләрендә?

Диде Алмас олуг хан:

«Җир-ана, аңлыйм ла мин,
Утлы дәва бу.
Йөгән сыман
Мәгърур Болгар баласына.
Әмма бүген
Дин дә түгел,
Хәтта ден дә түгел,
Сайлау бара
Үлем белән
Яшәү арасыннан.
Бөек Тәңре –
бабалардан
Төрки җанда – бер Алла,
Алла-Тәңре бер ул диеп,
Ышанам,
халкым аңлар...
...Төркиләрнең Ияләре,
Мәҗлес-Сабантуйлары,
Чолганып руза-мәүлидкә[15]
Табар юлын-җайларын.
Җан-бәгырьләр әрнесә дә,
Киселмәде кылычтан,
Ислам саклаган тамырны
Яңартырбыз, тырышсак...»
...Әле дә бит без татарга
Бертигез – Тәңре-Алла...

Үз фикерен Суаз халкы[16],
Әйдә, бәян кылсын.

«Тамырлардан аерылса,
Бөре ничек ачылсын?
Яфрак булып ачылганчы,
Кайдан ризык-рух алсын?
Яфракка да тамыр кирәк,
Табигать – юк! тамырсыз.
Тамыры киселгән куак –
Суаз халкы – рухларсыз».

Алмас хан:

«Сорауның башка ягы бар –
Әгәр кояш булмаса?
Яфрак булып ачылсаң да,
Гомерең кыска ласа.
Куак әйбәт мисал, ләкин
Адәм өчен килешми.
Буй җитеп тә – йөрерсеңме
Имчәк имгән килешли?»

Күз аллары караңгы,
Әмир күккә карады.
Күктән көтте сүз-тамга,
Бер-бер өн көтте җанга.

Күкләрдән килде аваз:

«Бу – бәхәс гомер-гомердән,
Бәхәс-ташлы юлыгыз.
Иң яхшысы: Кояшка да
Рухка да дус булыгыз.
Тәңрегә юл җиңел түгел –
Ия-рухлар – ярдәм.
Кыйбла – Тәңре,
ә юл килә
Рухлар-Ияләрдән.
Алла юлы – Мәхәббәтле –
Тәңгәл җаннар Җанга.
Тәңре кушып, Олы җаннар
Тамар, Җиһан, сиңа».

Күк сүзләре колакта да –
Тик мәгънәсе... еракта.
Кояш
болытта әле,
Заманның
көйсез
мәле.

**8**

...Чиктән чиккә күз кирәк,
Күзләү өчен үр кирәк,
Үрдән үргә манара –
Офыккача манзара,
Ук күзле яугир күрә:
Болгарга кәрван керә!
Әй, ут-сакчы, сал утың,
Дөрләсен-янсын утын,
Корганнан корган күрсен,
Болгар илгә җан керсен.
Үрдән үргә илт, хәбәр,
Үрдән үргә кит, хәбәр,
Пайтәхеткә җит, хәбәр:

– Килеп җитте илчеләр!
Көтеп алган илчеләр!
Рәхмәт, Тәңрем!
Аллаһы әкбәр!
Аллаһы әкбәр!..
...Бөек Биләргә җитәргә
Ике фәрсәх[17] юл кала
Илчеләрне сәламләде
Алмас патша, олылап.
«Ходага шөкер, шөкер», – дип,
Сәҗдә кылды Илпәрвәр.
Чәчелде илче ирләргә
Җиң эченнән тәңкәләр...

**9**

Олы мәҗлес Биләрдә:
Болгар иле мәш килә,

Бәйрәмгә чакырылды
Падишаһлар һәм биләр.
Ибне Фазланга рәхмәттер,
Ул – гади бер сәркатиб,
Калдырган күргән-белгәнен
Язмасына беркетеп.

«...Тантаналы бәйрәмнәрдә –
Кара төстәге кием,
Ак чалма акыл билгесе, –
Олы бүләкләр, диеп,
Хәлифәдән тапшырылды
Ошбу затлы нәрсәләр.
Зеңләде күккә сибелгән
Меңләп көмеш тәңкәләр.
Биеп тора тимеркүк ат,
Затлы ияр – сыртында,
Бу тулпар бәхет китерер
Алмас патша йортына»...

Тугыз йөз дә егерме ике –
Май уртасы Биләрдә.
Табигать тә яшелләнгән,
Табигать тә бизәнгән.
Ап-ак чәчкә – тау битләре, –
Алмагачы, чиясе,
Бәгырь пышылдый колакка
«Аллаһ әкбәр!» – диясе.

Әле алда өч гасыр бар –
Болгар иле үсәсе,
Агач ничек үсәр иде,
Булмаса нык кәүсәсе.
Бөек Болгар җирләрендә
Юк түгел иде чәчәк,
Ботак-чыбык яфрак ярды,
тик...
Буталчык киләчәк.
Кәүсә эзләү соңгы заман
Булды төрле тарафтан.
Хәзәр, Табгач пышылдавы
Җыялмады бер сафка.
Тәңре юлы йөрәктә дә...
Калмаган
язма тәртип.
Булмагач канун-тәгълимат,
Илне ничек үзгәртик?
Илгә ничек аң кертик?
Илгә ничек ден кертик?
Илгә ничек җан кертик?

**10**

...Чәчәкләрдән бал җыярга
Бал кортлары бик маһир,
Бал кортына ни кирәк?
Бал кортына ил кирәк,
Балга кәрәз-күз кирәк,
Илсез-кәрәзсез булганда,
Зират кына тал-тирәк.
Зиннәтле тауар кылырга
Болгар-төрки бик маһир.
Болгар-иргә ни кирәк?
Болгар-иргә ил кирәк,

Күңелгә канун кирәк,
Җан аша кергән канун –
Көчле илгә шул терәк.

...Алмас патша аягүрә,
Барча халык – аякта,
«Аллаһу әкбәр!», «Аллаһу әкбәр!» –
Кайтаваз тирә якта.

Хәлифәнең хатларында
Әйтерсең лә бәлзәм.
Күңелләргә агылгандай
Ошбу хаттан зәмзәм:
«Минем илем урман булса,
Болгар булыр алан.
Багдад-Биләр шулай яшәр:
Ана белән бала...»

Бакчачысы Ислам булды
Болгар Дәүләт бакчасының,
«Бер Алла!» дип типте кальбе
Мәҗлестәге барчасының.
«Алла бөек!», «Аллаһу әкбәр!» –
Җир тетрәде алкыштан,
Ислам нуры Идел-йортта, –
Нишан* басты Алмас хан.

Шул мизгелдә
могҗизасыз буламыни,
Аяз күктә яшел, кызыл...
балкыш уйный.
Килде тавыш –
Әйтерсең лә унлап көйне
Үрде бергә –
бер толымга
Ислам дине...

**11**

...Алмас әмир тәхетендә Ай үзе кунган сыман,
Дәвам итте олы туй – Болгар ил туган заман.

Уң кул – падишаһ-биләр,
Сул кул – кунак-илчеләр.
Хыял түгел, бу – хәят,
Берләшә ил, ниһаять.
Алтын дага ялт та йолт,
Дәва сиңа, Болгар-йорт.

...Сөҗү* үтте күңелләргә,
Әмма балдан түгел,
Догаларны ширбәт итеп
Канатланды күңел.

**12**

...Бишләп үргән чыбыркы.
Биш каештан үрелгән,
Биш каешның бишесе
Биш каеш – берәм-берәм.
Берәм-берәм булалмас
Биш каеш – биш чыбыркы,
Берәм-берәм булалмас

Биш каеш – бер чыбыркы.

Биш кавемнән бер милләт
Булалмас берәм-берәм,
Биш кавемнән биш милләт –
Биш чыбык, берән-сәрән.

Бергә-бергә үрелеп
Туса туар бер милләт.
Татар чыбыркысына
Болгар – бер каеш, димәк...

**13**

...Кызыл Таудан[18] баккан идем,
Күрдем сихри манзара:
Затлы кәләпүш диярсең –
Ап-ак чәчкәдә – кала.
Калкан булып пайтәхеткә –
Шәһәр тирәли үрләр,
Тәсбих төймәләре сыман
Акбүз атта яугирләр.

Алмас хан төшенә кергән
Шәһре Биләр шул икән,
Өч гасырга оя корган
Аккош-бәхет шул икән.

**14**

Бу шәһәр генә диярсең – барча дөнья сыйган,
Бу дәүләт кенә диярсең – куәт биргән җиһан.
Сәүдә юлы үзәгендә Бөек шәһәр – Биләр,
Мәшрикъ-мәгъриб кисешендә – кыйбла шәһәр – Биләр!
Кәсеп белән, Тәңре кушып, баеган халык, диләр,
Олы затлар, юмарт байлар – шуңа, имеш, Биләр.
Акыл белән, белем белән килгән хөрмәт, диләр,
Билекварлар – билекләләр, шуннан килә – Биләр.
Кызларының чәче – алтын, зәңгәр кизләү – күзләр,
Акбүз атта болгар ире – сиңа калкан, Биләр...

**15**

...Шәһәрнең күз алмасы –
Затлы Корымлы* үзәк,
Шәһәрстан күкрәгендә тибә горур йөрәк.
Манарадан – уч төбендә тышкы шәһәр – рабад.
Күңелләрне сыйпый җиле – сызылып килә сабаһ.
Корганнардан үтә күзләр, үтә балбаллардан,
Тарих җиле хәбәр сөйли ата-бабалардан.

Тирә-якта хәтфә кырлар, албастылы урман.
– Ми-ха-ха-хай! Йөрәккә май – атлар уңнан-сулдан.
Җир тетриме? Күк күкриме?
Юк,
Көмеш тояклары
җир-бәгырьгә
тиеп ала
Җитез тулпарларның...

Ялларында әрем-кылган исе –
Ярсый күңелләрем,
Төрки җанның ат җанына
Тоям үрелгәнен.

Тулпар атның канатлары –
Җанкисәгем, сизәм...
Атлар исән,
Татар исән –
Түзәм әле,
Түзәм!..

Көмеш тояк,
Тыбы-дып! Тыбы-дып! –
Кальбем тоя –
Ярымайлы ат тоягы
Җиргә бәхет уя...

**16**

Кәрвансарай базарында
Кайный алу-сату,
Бу мәйданда уртак канун –
Базар халкы – тату!
Тауар ишләр мактый малын –
Гореф-гадәт читтә,
Төрки телне белдең икән –
Файда әйбәт чиртә.
Бөек шәһәр кочагында
Гөрли Олы-базар!
Олы-базар! Мәшһүр базар!
Дөнья сыйган,
Ил туенган
Алтын казан!
Алтын казан!

Рун тамгалар, Рун язмасы –
Чүлмәк яме,
Төркиләрне саклап килгән
Ыруг шәме...

– Ефәк! Ефәк!..
– Кемгә чүлмәк! Чүлмәк! Чүлмәк!..
– Алка – Йөзек – Беләзек!
– Алка – Йөзек – Беләзек!..

Дүрт як дөнья үзәге,
Бөек шәһәр йөрәге.
Бу – кайнап торган казан,
Бу казан – Ага-Базар!
Базарга килгән илләр,
Чит илләр гизгән биләр.
Дистәләп гасыр үтсә дә,
Яңара шул мизгелләр:
«Болгар-Биләр диясез,
Болгарданмы киләсез?
Болгар елкыларын һәйдәп,
Һинд илләрен гизәсез»...
Таң җиледәй Чин ефәге,
Күзне буа алтын,
Гүя тылсым тартмасында
Гөрли базар халкы.

Әрмән, чуваш, бортас, урыс –
Санап чыгам димә!
Рус-викинглар[19], хәзәр, румнар
Коллар алып килгән.

Берәү мактый читекләрен,
Берәү кыстый чәйгә.
– Тиеннәрең[20] сал билеңнән!
– Боерың! Әйдә! Әйдә!
Базар гөрли мең тавыштан –
Кызыл-сары-яшел...
Өзелмәс туй Болгар-йортта –
Яши болгар, яши...

**17**

Кыйбла эзләп торасы юк,
Үзең булгач түбә! –
Кирәк дисәң, ач күзеңне –
Мохит тулы үрнәк...

...Биләр – дөнья күчәредәй,
Башка халык – тәгәрмәч,
Уңга-сулга чабасы юк,
Дөнья шулай көйләнгәч.

...Булган бит ул шундый вакыт,
Татар булган түрдә...
...Ахры, Тәңре артык сөйгән, –
Сирәк чыккан Тәүбә!
Шөкер кылу булган сирәк,
Ваемсызлык илдә –
Кичер, Тәңрем, төрк баласын,
Хәтсез сәбәп, уйлый калсаң...
Йа Аллаһым, соң булмасын:
Тәүбә! Тәүбә! Тәүбә!..

**18**

...Ап-ак таштан Җәмигъ мәчет[21] –
Шул тарафка юл чыгам.
Кәрвансарай күк катында
Эленеп калган сыман.
Ике меңләп мөселманның
Җанын коча бу мәчет.
Җәелә азан моңнары,
Кичке намазга дәшеп...

Ибне Фазлан язганнардан
Тагын авыз итик,
Ниләр күргән безнең илдә,
Без дә күреп үтик.
...Кецалькоатель токымы –
Елан –
изге санда,
Бу – канатлы изге елан
Килгән Ацтыклардан*.
Уннан артык елан кайчак
Агач ботагында,
Биләр халкы
муллык күрә
Елан ыславыннан.

**19**

...Көннәрдән бер көн
гүяки
Өнсез калды шәһәр.

Йорттан йортка үрмәләде
Шомлы хәбәр:
Ишеттеңме?
Хан кызы бит
чирләгән.
Табиблар хәлдән тайган, ди,
Чара таба белмәүдән.
Файдасы юк,
китергәннәр
Даруның мең дә берен,
Хан табибы әзерләгән
Зур тирйакның[22] бар төрен.

Түзсә түзәр
Таш йөрәк:
Урак-айдан
Нечкәрәк –
Таң йолдызы –
Хан кызы.
Ут йота Хан,
Бичара,
Дөнья – буш,
Дөнья – кара.

Хан елады ачынып,
Әйтте җаны ачылып:

«Тәңрем, кыл бер-бер ярдәм,
Йолып ал кызны гүрдән.
Вәгъдәм –
мәңгелек колың
Мин – әмир,
Кылсаң юлын».
Әйтте сүзен ил-каган.
Тып-тын халык.
Тын җиһан.
Кинәттән җилләр исеп
...Аңкыды каен исе.

...Пәйда булды Дәрвиш,
Кулларында...
Каен себеркесе...

Чактымыни кара елан!
Әмир басты торып.
Кулда кылыч, күзләр – яшен,
Ташлый хәзер
турап.

– Син нәрсә, карт!
Әмиреңнең
Кайгысыннан
Көләсеңме?!
Кылычыма каршы дүркә*
Күтәргәнсең,
Беләсеңме!

«Сабыр, ханым,
Күрәм.
Аңлыйм,
Ни кылганым
Беләм.

Мин бер фәкыйрь,

Мин бер мескен,
Хода кушкан колы
Эшнең.
Мин ышанам.
Син дә ышан,
Ышануда иң зур дәва.
Син ышансаң, Ходай кушып,
Ышаначак балаң.

Ә хәзер
куш, яктыр мунча,
Тереләчәк Алтынчәчең,
Алла кушса.

Әмма әле терелүнең
Бер сере бар тагын да,
Булу кирәк шул минекнең
Сөйгәне кулларында.

Ә хәзер –
Хуш».

Юк үзе дә, юк эзе дә.
Карттан бердәнбер билге –
Алтын Тәхет янында
Кала
...Чулман минеге.

...Үтәп куйган шартларны,
Күреп бар чараларны,
Чыж-ж-жлатып
йомшак парын,
Чабып ярын, аппагын,
Ике сәгать дигәндә,
Ике күгәрчен кебек,
Кайтып керәләр, парлап,
Пайтәхеткә нур сибеп,
Хан кызы, хан кияве –
Җанга рәхәт сөйләве.
Ил күрмәгән туй булды,
Ханның күңеле тулды,
Хак дин диде,
Дин-Ислам,
Көн-төн яңартты иман.
– Бу дингә
Сәҗдә кылам,
Мәңге яшәсен Ислам.
Бу – тугъры дин,
Бу – хак дин,
Биләргә таман,
Амин!..

**20**

...Бөек Биләр – серле Биләр –
Риваятьләр арканы[23].
Биләр чоры – кыйблаи чор –
Язмалардан отканым...

**21**

...Алыш-биреш,
Мирдә тәртип,

Әзер кунак ашы.
Биләр-Суар арасында
Азан яңгырашы.
Һәр ай нурын манарага
Бәйли барган сыман,
Бер-бер артлы үсте күккә
Айлы мәчет – урман!

Бишек җырын ишеткәнче,
Дога керде җанга,
Һәр сәгате яшәвенең
Ачык мөселманга.
Өс-баш пөхтә, фикер якты,
Халык киде читек,
Сугышырга килгән урыс
Әйтте: «Давай, китик!
Безгә тиңнәр дала тулы,
Эзлик лә башкасын»[24].
Китте кайтып
Килгән гаскәр,
Бәйләп чабатасын.
Зур мәчетләр, таш йортлар да
Әз дип әйтмәс идем,
Затлы мунча аеруча
Бизи Болгар илен.
Йомшак җиргә төшкән орлык
Үсеп киткән кебек,
Үсте фәннәр, үсте сәнгать,
Үсте болгар-төрек.

Уникенче-унөченче гасыр агышлары,
Бирде илгә тулы касә
Шатлык-сагышларын...

...Иште давыл, басты сулар –
Җуелмады җәүһәр-сүз –
«Кыйссаи Йосыф»[25] китабы
Сигез гасыр үлемсез.
Кол Гали күңел табибы,
Тел табибы – Кол Гали.
Җан табибы, тән табибы –
Таҗетдин әл-Болгари[26].
Зур Тирйак – дару китабы
Кемгә ярдәм итмәгән.
Ун гасыр тарих аркылы
Балкый китап киштәдә.

**22**

Илкам ибн Сәлим хан[27]
Төш күрә:
Биләр халкы –
Урамда яше-карты,
Сәҗдә кыла тезләнеп,
Курку алган йөзләрен.
Шом биләгән Биләрне.
Шом бушаткан өйләрне.
Һавалар зеңләп тора,
Гүя меңләп сыбызгы,
Чиный, безли, сызгыра.
Дөнья – күкәй сарысы,
Сап-сары – көн, сары – су.

Җир – сары, халык – сары,
Ахырзаман шул микән –
Шулмы дөнья ахыры?
Кояш зеңләп зурая,
Зурая, якыная...

Болгар иле – батыр ил,
Өченче йөз балкыр ил...
Тик...
Төш кадалды җанга –
Бу хәбәрме, тамгамы?
Кемгә серне сүтәсе?..
Кайдан нәрсә көтәсе?

**23**

Биләр – шәрекъ гүзәле,
Биләр – мәгъриб газәле,
Хәнҗәр-пычак кайраучының
Көймәс димсең үзәге?
Монгол-татар яу чаба,
Төрки төркине чага,
Биләр – бик татлы җиләк,
Уяу буласы кирәк.
Карурманда тамгалар
Мәгълүм болгар иренә,
Яшерелгән, тамгалап,
Юллар болгар илендә.
Җир астыннан юл китә,
Җир астыннан юл килә,
Җир асты юлы белән
Тоташкан Болгар-Биләр.

...Офык югалган мизгел,
Таулар югалган мизгел,
Кырлар югалган мизгел,
Дошманга дошман укмашып,
Күкне каплаган мизгел.

Төш күрде Болгар ханы –
Килдемени төш раска?
Дөрли Биләр,
Яна Биләр,
Охшап кара кояшка.
Ак күгәрчен, күк күгәрчен
Оча чолганып утка!
Кошны чыра итүченең
Үзенә юл – тәмугка!

**24**

...Мең ике йөз утыз алты[28]
Көзләр иде Биләрдә,
Бәхет тулы гөлбакча
Калды сыкрап сөйләргә.
Таш өстенә таш төште,
Уклар акты болыттан,
Гүя җилләр кылычтан –
Кырды илне берочтан.
Биләрсуга[29] карамыйм,
Биләрсулар – кып-кызыл.
Хәлләр ни дип сорамыйм –
Җир астында ул-кызың.

Төштә күргән төш иде –
Өн булса да бик разый...
Тузып меңгә атылды
Бөек Биләр йолдызы.

**25**

Очты болгар очкыны,
Дүрт як – кыйбла чаклары,
Меңләп чакрымнар үтеп,
Кабынды учаклары.
Идек абый-сеңелле,
Идек күрше йә дуслар.
Очтык оя тузгачтын,
Канаты көйгән кошлар.

Кайтыр иде иленә,
Кайда татар хуҗа ил?
Ятар иде җиренә,
Кайда татар хуҗа җир?

Кайтыйм дисәм, юк илем,
Кайгы-сагыш – күл, имди,
Башым исән – юк халкым,
Инде хәлем бел, имди,
Сак-Сок булдык читләрдә,
Күрше булдык читләргә.
Сак оясы җирләрдә,
Сок оясы күк каты,
Булса булсын җаным фида –
Җитим Биләргә кайтып.
Тамыр диеп тибә кальбем,
Тамырлар синдә, Биләр,
Изге Чишмә[30] чыңлавында
Саклана безнең көйләр!

**26**

...Шәһре Биләр каласында
Кырык гәүһәр бар, диләр,
Кырык гәүһәр арасында
Җәүһәр бикә бар, диләр.
Җил җилешми – җитезләр,
Ай ярышмый – ай-йөзләр,
Йолдыз күзле бу кызлар,
Биләр-йортта – йолдызлар.

– Без – кырыкбыз, кырык кыз!
Бердәм бер тән булыйк без,
Бердәм бер җан булыйк без.
Җәүһәр сүзе – утлы сүз:
Дошманнарны турыйк без!

Яугир киеме авыр,
Авыр булса да киик,
Аякны кыра тимер,
Тимер булса да түзик.

Олы тауга меник без,
Тау-манара төзик без,
Чокыр тулы су булыр,
Дошман гүре шул булыр.

Шәһәргәчә чакрымнар,
Шәһәрне саклый кызлар...
Корабның төбе төшкәндә,
Коткарырмы ишкәкләр...
Кызлар булды ак каен,
Кырылып беткәч иркәкләр...

Кырык каен, кырык кыз –
Шуңа ул Кызлар тавы.
Җәүһәр җырын җырлый сыман,
Җилләрдә – каен шавы.

**27**

Хуҗа-ияләр тавында[31]
Мәрҗән[32] – болгар шәһәре,
Энҗе кебек йортларын
Саклый тау ияләре.

Тау башында ак чалма –
Ак чалмада зиннәтләр,
Тырышмал хан[33] сараенда
Кыйммәтләрдән кыйммәтләр.
Челләдә – җил җиләсе,
Үләндә – чык тезмәсе,
Шәфәкъка кунган йолдыз,
Нараттан тамган сагыз,
Беренче Чәчкә балы –
Тырышмал хан кызлары.
Унике бөртек энҗе –
Берсеннән-берсе чибәр,
Унике бөртек энҗегә
Йолдызлар гашыйк, диләр.

**28**

Йолдызлар гашыйк, диләр дә,
Кайда соң егет-биләр?
Сөюдән күпләр җүләр,
Албасты аулый, диләр...

Иштирәк – иң батыры,
Нәркис – иң-иң матуры.
Егет гыйшкы Нәркистә,
Нәркис гыйшкы – Иштирәк.
Алла сайлаган парлар –
Мәрҗәндә сездәй сирәк.

Иштирәк әйтте сүзен:
Туй буласы бу көзен!
Нәркис чибәр көн дә төн
Әзерли туй күлмәген...

**29**

Алтынланып көз килде.
Туй буласы көн иде...
...Дәрли Биләр, яна Мәрҗән –
Ник дөньяга килгәнеңә
Үкенерлек өн иде.

Бер имәнгә – йөз балта,
Бер йөрәккә – ун пычак.
Яңгырга чыдый учак,
Җилләрдән дөрли учак.
Давылга-өермәгә дә
Бирелмәс иде учак.

Туфан-су басты өстән,
Гарасат төште күктән...
...Учак әле өскә калкыр,
Форсат килеп бер,
төптән.
...Кинәт күрде Иштирәк:
Нәркисе – йолдыз күктә.
Көт, сөеклем, түз мизгел,
Туй итәрбез биектә...

**30**

...Без, без, без идек,
Без унике кыз идек,
Базга төштек – бал ашадык,
Келәткә кердек – май ашадык,
Кара сыерның каймагын
Кап та йот –
Һоп!

И, Нәркис түзәмени!
Янарчәчәк, төпчек гөл
Көлешми-серләшмичә
Торамыни бер мизгел!

– Алтмыш алты кыз булып,
Мәдрәсәләр үттек без,
Уникебез бертуган,
Дуслык анты эчтек без.
...Без көлешеп йөргәндә,
Кинәт килде җил-давыл,
Ябырылды илбасар –
Өс-аслы дошман явы.
Тәңрем-Аллам, ди-дия,
Каргыш чиктек дошманга.
Хода, коткар, дия-дия,
Укыдык таңнан-таңга.
Дошман көче – кылганда,
Ятсын кылган тузанга,
Кылган янсын далада,
Ләгънәт яусын һавадан.
Кылган көче көл генә,
Дошман сүнсен көл белән,
Очсын җилгә көл булып,
Буылсын төтен булып.
Әфсен-төфсен, таң килсен,
Дошман-явыз җан бирсен!

**31**

...Мәрҗән иде гөлбакча,
Ул инде күмер генә...
Мәрҗән иде зур шәһәр,
Калды кисәү-көл генә.

...Бардыр, Тәңре, бер сәбәп,

Бардыр гаеп кайдадыр,
Ал, Син безне күкләргә,
Безнең күңел айдадыр.
Унике сын булганчы,
Унике йолдыз булыйк,
Дошманга кол булганчы,
Ай-кояшка кыз булыйк...

**32**

...Кызыл Чишмә. Арт бакчада.
Бу – төш.
Гаилә белән
Бәрәңге
Утыртабыз, имеш.

Җилкәм тоя,
Иңбашыма
Чәчен тидергәндәй бер зат.
Кул битләрен ялый, тия колагыма...
Күрәм –
Зәңгәр күзле
Ап-ак
Акбүз ат...
Юк... Ат башы...
Ап-ак фәрештәдәй.
Үзе тыныч, үзе йөгәнсез.
Күк – түбәсез.
Ат күзләре – диңгез.
Күңел капкаларым –
Келәсез...
Салмак кына
Төштән айнып киләм.
Уйнап этәм читкә Ат башын.
Шундый тирән, мәнле карашы...
...Хәтер-тамга булып
Йокы канатында
Өнгә күчте
Ап-ак яллы
Атсыз ат башы...

И балалар!
Бөек Атлар Рухы
Ак юл итә безгә ялларын.
Йөзләп гасыр
Җирдә төрки Рухы,
Күңелләрдә – Татар заманы.

Кояш биргән
алтын җепселләргә
Төркиләрне
Тәңре теркәгән,
Өзгәләнгән нурлы
бу тәсбихны
Ялгау өчен чара күзләгән.
Җан-буддадан
Җан-кыл алып баккан,
Хач кылларын
Биргән кыпчакка.
Зур тәсбихны
Тоталмагач нурлар,
Мәҗүсилек тоткан

Пычакка.

Биләр чоры –
Диңгез дулкынында
Өскә күтәрелгән корабтай.
Ислам дине өч-дүрт
гасыр буе
Көндез кояш булган,
Төнен – ай.
Әйтерсең лә
дулкын баскан кораб –
Болгар иле төптә югалган...
Су өстендә такта кисәкләре
Кораб булып йөзә-болгана...

**33**

...Татарга өмет багларга
Ике тамга төгәл, имди,
Гүя хәбәр бирә безгә –
Риваятьләр тәңгәл, имди.

Татар-төрки күтәрелгән заман
Күтәрелгән, диләр, Хәзәр-су.
Каспийда да, теге чордагыча,
Күтәрелә икән
Хәзер су.
...Әмир әйткән Биләр тузган көнне:
– Эзсез йотсын мине Җир-анам,
Әгәр беркөн Биләр бөреләнсә,
Мин кайтырмын әле, багалмам.

Өмет туса болгар үсәсенә,
Мин әйтермен: Болгар! Мин исән!
...Кыпчак-болгар-татар ил-җирендә
Мин – Алмагач!..[34]
...Талгын җил исә...

**34**

Күкләр, татар, азмы кисәтте,
Ачып, алда күрәсеңне:

Хакыйкатькә чыкма каршы –
Әйт үз дөресеңне.

Мәхәббәттән булма олы –
Сайла сөясеңне.

Хакыйкатькә каршы чыккан Алып та юк!
Ияләргә каршы чыккан халык та юк!
Алмагач ап-ак чәчәктә – их, алмасын аласы...
Чәчәкләргә мурта килми – кайдан килсен алмасы?

...Яши Татар! Ияләр дә исән!
Аңлашырга араларда юк Камнар[35].
Ияләр дә ятим, адәмнәр дә –
Унлап гасыр яралардан... җан тама!

**35**

...Аптыраган үрдәк
Арты белән суга чума, диләр,

Азмы, татар, шундый күлләрең?
Күл дигәнең әзме сәхрә булды,
Азмы йотты дөнья чүлләре?
Татар җире безнең бәгырьләрдә,
Чулман-Идел безнең кан юлы,
Кыпчак далалары – бәгъре,
Болгар – кальбе,
Ул җир һаман хәтәр каюлы.
Мәгъриб-мәшрикъ безгә кыйбла булмас,
Җир өсте тар бүген татарга.
Әмма күкләр, татар, сиңа ачык,
Галәм ачык тулпар-атларга.
Акыл-хисләр, йөрәк талпынуы
Кыйбла итсә йолдыз-күкләрне,
Әле Сак-Сок булып йөргән татар
Өстән күзәтәчәк күпләрне.

**36**

Җайлый-ялгый өзгәләнгән җепселләрне,
Дәва булып бәгырь ярасына, –
Болгар рухы
Бөек Биләр кочагында –
Изге Кыйбла
Мәнле татар баласына.

*1998 – 1999*

**Аңлатмалар**

[1] Биләр, Болгар, Юкәтау – X–XIII гасырларда гөрләп үскән болгар шәһәрләре. Биләр хәзерге Алексеевск районы җирендә урнашкан, IX–XIII гасырларда Болгар иленең башкаласы булып, заманында дөньядагы иң зур шәһәрләрдән саналган Бөек Биләр шәһәре. Үзенең зурлыгы һәм халык саны буенча Биләр урта гасырның Киев, Новгород, Париж, Рим, Бохара, Сәмәрканд шәһәрләренә тиң булган.

[2] Пайтәхет – пает тәхет, түбә тәхет, ягъни башкала.

[3] Биредә Америкада (бүгенге Мексика тирәләре) 10–15 мең еллык тарихи эзләре булган майа, ацтык халыкларының теле нигезендә төрки тел булуына ишарә.

Кайбер мисаллар: майа халкының мифик герое: Кецалькоатель – Кецле-куатле (*миш.* әйтелеше). Риваятьләр буенча, ул тудырган балаларның исемнәре: Балам-Кице (*миш.*: Кеце Балам), Ики-Балам (Ике Балам).

Таң белән кич арасы: Кин (көн, *миш.*: кен).

Цолкин (цуалкин, ягъни цуалган (*миш.*: буталган көн) – Венера планетасы елы белән санаганда, һәр 61 ел саен Җир календарена 4 көнлек төгәллек кертелә торган ел.

Канкин – кан көне (майа календаре буенча, 2012 елның 23 декабре – майалар ышануынча, җирдә тереклекне юк итәрлек зур һәлакәт буласы ел).

Ацтыклар үз илләрен Анаһуак (Ана куак) дип атаганнар.

Безнеңчә, төп шәһәрләренең исемендә дә төрки тамыр: Теночтитлан, ягъни Тыныч сүзеннән: әйтик, бер варианты – тыныч тот олан (аның урынында хәзер Мехико шәһәре). Гомумән, мәгънәсе ягыннан да, яңгырашы белән дә төрки-татар сүзен хәтерләтә.

[4] 1) Скифлар иле (б.э.га кадәр VIII–III гасырлар, Кара диңгез буе);

2) Һун-Сөн иле (б.э.га кадәр һәм б.э.ның II–III йөзләре, хәзерге Төньяк Кытай, Тува, Енисей (Урхун – Үр Хун) елгасының югары агымы тирәләре, моннан 2 мең еллар элек Урта Азия, Әфганстан, Пакыстан, Төньяк Һиндстан җирләрен берләштергән Кушан империясе төзиләр);

3) Атилла чорында иң зур көч туплаган төрки-кыпчак иле – Дәште Кыпчак (Кыпчак даласы) (б.э.ның III–V гасырлары, чикләре: Көнбатышта – Алып таулары, Дунай (Истр) елгасы башланган җирләр, көнчыгышта – Байкал күлен узып, көньякта – Босфор, Кавказ таулары, төньякта – Мәскәү, Ока – Ука елгалары);

4) Күк Түрк каганаты (б.э.ның VI–VII гасырлары, хәзерге төньяк Монголия җирләрендә урнашкан, Каспий диңгезеннән Корея култыгынача җир биләгән);

5) Урта Идел Болгар дәүләте (VII – Бөек Болгар дәүләтен төзүче Кубрат ханның улы Кодрак хан өммәте Идел-Кама-Зөя буена килеп урнаша, IX–XIII гасырларда Идел буенда Бөек Болгар иле үсә);

6) Алтын Урда дәүләте (XIII–XIV гасырлар, Көнбатыш Себер, Төньяк Хорезм, Идел буе Болгар ханлыгы, Кырым, Төньяк Кавказ, Дәште Кыпчак керә, Урыс кенәзлекләре буйсына);

7) Казан ханлыгы (XV–XVI гасырлар).

[5] Скиф – б.э.га кадәр VIII–III йөзләрдә Ауразиядә бик зур территориягә таралып яшәгән төрки халык. Безнең фаразыбызча, иске эв = иске өй (йорт), борынгы (элгәреге) йорт мәгънәсендә. Әйтик, мисал өчен, бүген дә шул мәгънәдә кулланылучы атамалар: Иске Казан, Иске шәһәр (Төркия).

[6] Рун – борынгы төркиләрдә киң кулланылган, XIII гасырларгача актив кулланышта булган хәрефләп язу.

[7] Татарстан белән Башкортстан арасындагы Сөн елгасына ишарә.

[8] Сүз IV–V йөзләрдә яшәгән (395 – 453), Байкал күле тирәләреннән Урта диңгезләргәчә сузылган Бөек кыпчак дәүләтенең патшасы булган Атилла хакында.

[9] Бату – Батый (1208–1255) монгол ханы, Чыңгыз ханның (Тимучин) Алтын Урда дәүләтен төзүче оныгы.

[10] Чирмешән – Биләр шәһәре янындагы Кече Чирмешән елгасы. Элеккеге атамасы – Җаушер. Безнең фикеребезчә, Яу җире, ягъни яу булган җиргә ишарәдер.

[11] Алмас хан – X гасырда Болгар дәүләтендә Ислам динен дәүләттәге төп дин дип кабул итүче хан.

[12] Багдад илчеләре – 922 елның май урталарында Багдадтан килгән илчеләрне кабул итү тантанасына, Ислам динен рәсми кабул итү күренешенә ишарә. Шул вакыйгага һәм шул чорга караган мәгълүмат, нигездә, илчелекнең сәркәтибе Ибн Фазлан язмаларыннан.

[13] Сәкалибә – болгар-кыпчакларны, гомумән, Идел-Чулман елгалары тоташкан җирдән төньяктарак яшәгән халыкларны фарсылар шулай дип атаганнар. Кайбер татар галимнәре *сәкалибә* – болгарларның гарәп телендәге икенче атамасы дип дәлилли.

[14] Хәзәр – VII–X гасырларда Хәзәр (хәзерге Каспий) диңгезе буенда көчле дәүләте булган төрки халык. Идарәче даирәләрдә төп дин, рәсми дәүләт дине итеп иудаизм саналган.

[15] Мәүлид – мөселман бәйрәмнәре.

[16] Ислам кабул ителгәндә тәңречелектә калган кабиләгә ишарә.

[17] Бер фәрсәх – 6 чакрым тирәсе.

[18] Кызыл Тау – Биләргә Алексеевскийдан килеп керү ягында Хуҗалар тавыннан көньяк-көнчыгыштагы тау.

[19] Викинглар – хәзерге Скандинавия халыкларының борынгы бабалары.

[20] Тиен – иң кечкенә акча берәмлеге, мөгаен, иң арзан тире тиен тиресе булып, башка тиреләрнең бәясе шул тиен тиресе саны белән билгеләнгәндер.

[21] Җәмигъ мәчет – Көнчыгыш Ауропадагы иң борынгы мәчетләрнең берсе, берьюлы ике мең мөселман гыйбадәт кылырлык мәйданы булган гыйбадәтханәле мәчет.

[22] Тирйак – болгар чорында киң кулланылган дару әзерләү ысуллары.

[23] Аркан – биредә: сере ачылып бетмәгән, яшерен мәгънәле дип аңларга. Хәзерге көннәрдә дә, әйтик, АКШта яшерен, эзотерик, мистик оешмаларны *аркан,* диләр. Татарда аркан – ишеп эшләнгән, бер башы элмәкле озын юан бау икәнен искә алганда, тиешле нәтиҗәләрне укучы үзе дә чыгара алыр.

[24] Тарихтан 1184 елда Киев воеводасы Владимир гаскәренең Биләргә җитеп тә сугышмыйча кире борылып кайтып китүе мәгълүм.

[25] «Кыйссаи Йосыф» – XII гасырда болгар шагыйре һәм яугире Кол Гали иҗат иткән дастан.

[26] Таҗетдин әл-Болгари – шул ук чорда яшәгән, Зур Тирйак рецептларын язып калдырган табиб.

[27] Илкам ибн Сәлим хан – XII йөз башында идарә иткән Биләр ханы.

[28] 1236 елның көзендә, бер еллап камап торганнан соң, Батый хан гаскәре Биләр шәһәрен яулап ала һәм яндырып юк итә.

[29] Биләрсу – Биләр шәһәре аша аккан елга исеме.

[30] Изге Чишмә – Хуҗалар тавы итәгеннән агып чыга торган көмеш сулы чишмә. Бер риваять буенча, Хуҗалар тавына урнашкан Мәрҗән шәһәре башлыгы Тырышмал хаҗи, кызларының дошман кулыннан һәлак булуын күреп, шул таудан аска сикерә, шуннан Изге Чишмә тибә башлаган, имеш.

[31] Хуҗа-ияләр тавы – Биләр шәһәре (бүген – Биләр авылы) янындагы тау шулай атала. Тау – авылның төньяк-көнбатышында. Риваятьләр буенча, шул тауга Биләрдә яшәгән изгеләр күмелгән.

Бер риваять буенча, Биләрнең 40 кызы, шул тауда кальга төзеп, шәһәрне дошманнардан саклаганнар, шунда һәлак булганнар. Шуңа да бу тауны Кызлар тавы дип тә йөртәләр.

Икенче бер риваятькә караганда, бу тауга дошманнар 12 кызны тереләй күмәргә теләп, кызларның үзләреннән туфрак ташытып тау өйдерткәннәр, шуннан Кызлар тавы атамасы калган.

Хуҗалар тавының исеме мәҗүсилеккә, төрле ияләргә табынуга барып тоташа дип фаразларга нигез бар. Тау иясе, ягъни хуҗасы, су иясе, ут иясе һ.б.лардан тауны Ияләр, ягъни Хуҗалар тавы дип атаганнар.

[32] Мәрҗән – Риваять буенча, Хуҗалар тавы башында урнашкан, Тырышмал хаҗи идарә иткән шәһәр исеме.

[33] Тырышмал хан – Мәрҗән шәһәре ханы.

[34] Риваять буенча, дошманга каршы сугышта Биләр ханы Илкам каты яраланып, җан бирер алдыннан үзенең кая күмелгәнен сер итеп калдырырга куша. Бер вакыт җитеп, форсат килеп Болгар халкы яңадан көч алса, мин үзем үк алмагач булып җир астыннан калкырмын, ди ул... Шунысы хикмәтле: Татарстан туган елны, чынлап та, казу эшләре алып барылган җирдә алмагач үсеп чыга...

[35] Кам – борынгы һун-төркиләрдә дин башлыгы, ияләр-рухлар белән кешеләр арасында арадашчы булган.

## *Иске Казан*[1]

*(Цикл)*

**1**

Риваятьләр берсен-берсе этә,
Дистәләгән бәхәс[2], сүз-дары –
Иске Казан кайчан, кайда булган?
Кемнәр салган нигез ташларын?
Үзенә бер кәркеш* һәр риваять,
Кәркешләрдән аркан үрелә,
Әйтерсең лә тарих арканында
Иске Казан кайта бүгенгә.
Һәр риваять үзенчә хак сөйли,
Иске Казан үсә, җанлана,
Һәр риваять илтә хакыйкатькә,
Ә хакыйкать – бары Алладан.

**2**

Биек тауга[3] менеп лә кара син як-якка.
Аста казан – тынган кайнавы,
Божра-кальга алтын тотка булган казанга,
Меңләгән сер монда – сер тавы!
Шәһре Болгар[4] – Иске Казан арасында юл –
Тормыш юлы булган берзаман,
Безнең күңелләрдә югалмаган бу юллар –
Язгы талчыбыктай җанлана.

Чакрым саен горур манаралар рәт булып,
Йөз чакрым юл – юлмы байталга!
Тулпар атлар, артлы чана, чыңлый кыңгырау,
Ой-һай, сәлам, яңа башкала!..
Урау булсын, йотсын офык, күмсен бураннар –
Өзелмәгән юллар гомердә.
Казан ханлыгының хөр дөньясы, моң-рухы
Болгар көйләреннән үрелгән.

**3**

Иске Казан алтын бишек булган[5]
Моң канатлы татар теленә,
Утлы чорлар кичеп исән телем
Мохтаҗ бүген татар сүзенә.
Болгар-йорттан тамыр алган өммәт –
Идел-йортта – татар милләте,
Иске Казан – илгә төрки казык,
Гасырлардан килгән өметем.

**4**

Хакыйкать һәм мәхәббәттән
Үрелгән безнең җиһан,
Бәрәкәт иңеп күкләрдән
Яралган җир-су, инсан.
Һәр тибрәнү, һәр талпыну
Бәйләнгән хәтер-җепкә,
Хәтер йомгак чолгап килә
Үткәнне киләчәккә.
Хәтер яшәтә күкләрне,
Җир – хәтер күчәрендә,
Кеше булып яши кеше,
Хәтер яшәсә генә.
Хәтер-читлек – эчке дөнья,
Хәтер-ятьмә – мир сөрә,
Хәтере нык халык кына
Киләчәк таңын күрә.
Күк-җиһаннан иңгән кавем –
Җир-ана кочагында,
Өзгәләнгән хәтер үзе
Төрки-татар сагында.
Борынгыдан түгел эзләр.
Эзләр – Җир үзәгеннән,
Җир тарихын язып булыр
Төркиләр эзләреннән.
Барысы да элеккечә,
Котлы тау[6], Казансуы[7],
Көтә Биек тау татарның
Хуҗа булып кайтуын.
Хәтер бар яткан ташларда,
Бар хәтер искән җилдә.
Хәтта таш та булмас адәм
Хәтер югалган илдә.
Тауларда тирән хатирә,
Табигатьтә нык хәтер,
Хәтер барда, өмет тә бар,
Татар үз сүзен әйтер.

**5**

Арча[8]-Биектау[9] кырлары хәтерле урман шавын,
Тоташ урман таудан тауга – Биектау карурманы.

Көмеш тасма, көмеш елга, карурманга муенса,
Арчадан Иске Казанга агыла көмеш кыйсса.
Ап-ак томан арасыннан ага елга, ага су,
Хатирәләр ага шулай, күңел шуңа ямансу.
Хатирәләр төрле-төрле, сагышлысы – тоташтан.
Кайсы ташны кузгатсам да, татар каны укмашкан.
Борынгыдан урман шавы кушылган аккан суга,
Карурман инде югалган, моң-шавын саклый елга.
Булган заман, Шүрәлеләр[10] гөрләткән урман түрен,
Ак Бүре[11], өммәт анасы, үз иткән татар җирен.
Күктә кошлар, суда балык, чәчәкле аланнары,
Кызыл төлке нәкъ бередә уйнаткан балаларын,
Аллы-гөлле күбәләкләр – күңелдә бәхет-рәсем...
Бу хатирә тамырлардан, төрки кан хатирәсе.
...Әмма бүген бу күренеш гүяки бер әкият,
Күптән җырда ул урманнар, әкияти риваять.
Котлы таудан ерагайган, саегып, Казансуы,
Татар кальбендә – карурман, язмаларда – ярсуы!

**6**

Мең ике йөз кырык өчләр дөньяда[12].
Татар иле уртасында Бату хан[13],
Ил үзәген, ил уртасын бизәрлек
Җир-су баглый пайтәхеткә Саин хан!
Ата-камнар* камлавында ачыла
Изге җир-су – Алтын Урда[14] үзәге.
Котлы тауда оя кора ак бөркет –
Иске Казан – Алтын Урда бизәге.

**7**

Илдә тәртип, мирдә тәртип, халык тук,
Алтын заман. Бату сүзе – аткан ук.
Хан шәһәре гүя оҗмах бакчасы,
Мәңгелеккә көйләнгән күк барчасы:
Хан сарае, Олы базар, Ак мәчет,
Азан моңы таралрадыр нур чәчеп.
Тормыш тигез. Гүзәллектә фикер-уй.
Сабан тәмам – халык гөрли – сабантуй![15]

**8**

...Ышанасы килми бу хәбәргә,
Аксак Тимер[16], имеш, җимергән,
Болгар таҗын кара күмер итү
Кирәк идемени Тимергә?
Юк, ышанмыйм, төрки канын төрки
Койгандыр дип, куркмый Тәңредән,
...Әмма тарих төгәл белә шуны:
Шәһре Болгар сүнгән әрнүдә...

**9**

Йөзләп гасырлар элек,
Җиһанда булган төрек,
Атлантлар[17] корган оя,
Көч-куәт биргән кояш.
Бу халык булган бөек,
Бу халык булган тере,
Белемле булган, көчле,
Күк капусы ачкычлы.
...Ут булып чыккан гауга,
Эреп, таш аккан таудан,

Гарасат йоткан җирне,
Туфан-су баскан илне.
Күкләрдән иңгән давыл,
Төркигә салган саум.
Йа оя, төрки оя...
Син кая хәзер, кая?
Йа оя, төрки оям...
Йа Җиһан, бөек Җиһан,
Йа Җиһан – Кояш йорты,
Йа Кояш, якты Кояш,
Йа Кояш – күкләр уты.
Йа оя, төрки оя...
Син кая хәзер, кая?
Йа оя, төрки оям...
Күк Тәңре, Җир-су, Умай[18]!
Кыл очында җан бугай,
Буыла, кими тугай,
Күлләргә чумалмый ай,
Йа оя, төрки оя...
Син кая хәзер, кая?
Йа оя, төрки оям...
Күк Тәңрем, илдә хәтәр,
Ялганмый, эри хәтер,
Җиһанда син бар һәм бер,
Көч иңдер, куәт иңдер!
Көч иңдер, куәт иңдер!
Йа оя, төрки оя...
Син кая хәзер, кая?
Йа оя, төрки оям...

**10**

Ундүртенче гасыр ахырлары.
Афәт уты чолгый Болгарны...

...Казан ханлыгына казык кага,
Габдулла хан[19], синең улларың,
Батый эзе тоныкланган вакыт,
Җиде буын – җиде борылыш,
Ике туган Алтын-Галим[20] бәкләр
Татар-йортка өрә яңарыш.

**11**

Элеккечә тыныч булмаса да,
Казан ханлыгында күк аяз,
Тынычлыкка калкан булып баса
Гаскәр башы Мулла Хаҗитаз[21].
Юккамыни гыйшык уты яна,
Ике йөрәк яна дөрләтеп,
Шәрекъ кызы Гайшә-бикә[22] белән
Туй итәләр дөнья гөрләтеп.
**12**

Бәхет капкалары
Ачылган киң итеп,
Туй гөрли, күңелләр хуш кыла,
Былбыл кош – яр Гайшә,
Лачын кош – Хаҗитаз,
Ике яр мәңгегә кушыла.
Туй гөрли җир тулып,

Туй гөрли ил тулып,
Күк тулып яңгырый алкышлар,
Җил-җитез егетләр,
Ай-сылу кызлары,
Туй итә пар килгән аккошлар.
Җыр-бию, сый-хөрмәт.
Ил башы – кодалар,
Иминлек хакында барлык уй:
Иң чибәр ул – Гайшә,
Иң батыр – Хаҗитаз,
Мәхәббәт чәчәге – кызыл туй.
Болгардан моң алып,
Казанда яр табып,
Булдыгыз бертигез яр-ярлар,
Тиң булып, пар булып,
Мәхәббәт, хөрмәттә
Гөл-гомер итегез, яр-ярлар.

**13**

Йолдыздан йолдызга
Чиксез күк җәелгән,
Зәңгәрсу биләүдә Җир-бакча,
Мең телле бер халык –
Җир халкы биләүдә,
Тәңредән рух иңә җан аша.
Бер халык – мең аваз,
Һәр аваз – алтын нур,
Нур сибә татарлар дөньяга,
Күңелдә алсу таң –
Иделдә, Уралда,
Татарлар төзегән ояда.
Казансу сулары
Иделгә кушыла,
Ярлары бормалы-бормалы,
Йөрәктән йөрәккә
Юл салып, моң салып
Казанга җан өргән Болгарым...
Бер халык – мең аваз,
Һәр аваз – алтын нур,
Нур сибә татарлар дөньяга,
Күңелдә алсу таң –
Иделдә, Уралда,
Татарлар төзегән ояда.

**14**

Бер сүнеп, бер янган милләтем,
Болгардан киселгән өммәтем,
Биек тау башында Казаным,
Искереп яңарган өметем.
Казансу агыла офыктан,
Дулкыны кагыла күңелгә,
Татардан татарга йөгерә
Кушылып меңьяшәр Иделгә.
Иске дә, яңа да түгел ул,
Бер янган, бер сүнгән күңел ул,
Биек тау башында Казаным –
Учаклар кабызыр күмер ул!..

**15**

Татар җаны кыл өстендә бүген,
Татар иле – тузган корт иле,
Йортсыз-җирсез чаба киләчәккә –
Шундый булмыймыни шыр тиле.
Көннән-көнгә кояш байый тора,
Таңнар атмый татар илендә,
Тел терәге – татар авыллары
Уты сүнгән шәмнәр хәлендә.
Былбыл теле былбыл сайрап яши.
Татар теле яши татарда.
Татар телен йотмый дөнья комы,
Татар телен йота татарлар.
Бу әрнүле сүзләр агу түгел,
Әче дару, татар, җаныңа.
Бар теләгем яшәү уты салу
Чыңгызлардан[23] килгән каныңа.

**16**

Чиста күңел, изге гамәл, ачык фикер –
Табигатьтән аермадың, Аллам, шөкер.
Мәхәббәттән калдырмадың татар халкын,
Горур иттең, матур иттең яшен-картын.
Болгавыр чак болгатса да ачы җилләр,
Капласа да татар илен яңгыр-болыт,
Тайгакларда югалтмадың кыйбла юлын,
Тайгакларда таянычың – сабыр холык.
Сагышлардан сагышларга салды язмыш,
Юк түгелдер үкенерлек ялгышлыклар.
Чишмә суын кой суыннан аерабыз –
Тәүбә диик, тәүбә итсәк, Тәңре саклар.
Нинди серләр саклыйсың син, туган җирем?
Күргәнсеңдер манарадан Болгар илен.
Сизмәдем дә, кай арада истең соң син,
Тарап үттең тамырлардан, Вакыт җиле?

**17**

Муллахаҗи зиратында[24] хәтер җиле,
Исә җилләр сызып-өзеп җан кылларын,
Моңлы татар көйләреннән тезмә сыман,
Казансуның рун язмалы[25] дулкыннары.
Скиф уклары[26] сызгыруы сеңгән сиңа.
Хан чишмәсе[27] ургып чыга күкрәгеңнән.
Иске Казан, изге Казан – син Пайтәхет,
Изге ядкарь Алтын Урда күкрәвеннән.
Дистәләп моң, телне кушып, кайнап бергә,
Туа татар Алтын Урда Казанында.
Мәңге яшәр татар, Тәңре кушып, җирдә
Тугъры булса изге Иске Казанына.
Татар телле Алтын Урда башкаласы –
Әле дә ул яши татар йөрәгендә.
Алтын Урда кальбе булып Иске Казан
Тибә бүген Татарстан күкрәгендә.

Иске Казан. Изге Казан –
Алтын Урда хатирәсе.
Иске Казан, Изге Казан –
Төрки-татар хәзинәсе.

**18**

Татар кайта, татар рухы тула казанга.
Яшь рух кайта, өмет яңара.
Иске Казан колачларын җәйгән яшьләргә,
Җанны җанга вакыт ялгарга!
Яңа кальга[28] бизи бүген Иске Казанны,
Димәк, әле исән тамырлар.
Димәк, әле риваятьтән үреп диварлар,
Рухны яңартырлык дәрман бар!

**19**

Эчке Казан[29] булып, алтын казык –
Иске Казан яши татарда.
Шәһәр түгел элек, татар үзе
Асылына тиеш кайтырга!
Кайтыр Биләр[30], кайтыр Болгары да.
Асылына татар кайталса,
Иске Казан үсәр, янә ныгыр,
Аң-зиһенен татар җыялса.
Идел-Урал горур бөркет булыр,
Канатларын җәер диңгезгә,
Борынгыча очар салмак, иркен,
Мәгъриб-мәшрикъ күген тигезләп.
Ике канат – берсен-берсе кага.
Ике дөнья, капма-каршылык,
Урта кирәк, алтын урта кирәк,
Ул урта бар – исән ул халык!
Шигарләрдә батыр булып түгел,
Шигырьләрдән күчик шөгыльгә.
Гамәл кирәк бүген, төгәл гамәл!
Балаларда өмет, акыл һәм телдә!

*2010*

**Аңлатмалар**

[1] Иске Казан – тарихта Газан, Болгар әл-Җәдид, Казан, Иске Казан, Өске Казан, Эчке Казан исемнәре белән билгеле. Иске Казан исемен кулланышка, беренче булып, XVIII гасырда шул төбәк кешеләре сөйләвеннән чыгып, сәяхәтче, рус офицеры Н.Рычков кертә. Бүгенге Казаннан Казансу елгасы буйлап өскә таба 40 км да Биектау һәм Арча районнары чигендә Камай авылы янында урнашкан.

Даими рәвештә фәнни эзләнүләр биредә 1928 елдан гына башлана. 1972 елдан башлап 1988 елларгача Иске Казан җирендә татар археологы, тарих фәннәре докторы Равил Фәхретдинов эзлекле казынулар алып бара.

[2] Дистәләгән бәхәс – Иске Казанның кайда һәм кайсы чорда булуы хакында әле бүген дә хәтта галимнәр арасында да фикерләр бәхәсле. Археолог Равил Фәхретдинов Иске Казанны бүгенге Биектау районында урнашкан Камай, Рус Урматы һәм Гайшә авыллары белән бәйли. Узган гасырларда Көнбатыш Европа һәм Россия сәяхәтчеләре, татар фольклорчылары Иске Казан хакында халык арасында шактый риваятьләр җыялар. Ул тарих төрле кульязмаларда, халкыбызның язма әдәбиятында да чагыла. Әлеге язмаларда, XVII йөзнең азагы һәм XVIII йөзнең башында гына төзелүенә һәм андагы кайбер мәгълүматның каршылыклы булуына карамастан, Казан тарихының башлангыч чоры хакында кызыклы мәгълүматлар бирелә.

Иске Казанның урынын археологлар ике җирдә дип билгели: беренчесе – Иске Казан (Камай) шәһәрлеге булып, ул Казан суының уңъяк биек ярында 6 гектардан аз гына күбрәк мәйдан биләп тора; икенчесе – Рус Урматы авыллыгы, анысы Биектау районының Камай авылы белән шул Рус Урматы арасында, Казан суы елгасының сулъяк үзәнлегендә, аның Урмат дигән тармагы буйлап 124 га мәйданны били.

Бистәнең көньяктагы борынгырак өлеше XII гасырның азагына, болгар халкының Казансу тирәләрен үзләштерә башлаган заманга туры килә. Шәһре Биләр туздырылганнан соң, чагыштырмача тынычрак, урманлы төньякта, тау башында кальга барлыкка килә. Бу кальганы 1243 елда Бату хан төзеткән дигән риваять тә язмаларда бар. Тиздән ул яңа шәһәрнең сәяси үзәге булып китә. Ә инде үскәннән-үсә барган астагы ачык өлеше һөнәрчеләр бистәсенә әйләнә. Әлеге күренеш XVII йөзнең азагында тупланган «Дәфтәри Чыңгызнамә» дигән тарихи язмада сурәтләнә.

[3] Биек тау – Казансуның биек уңъяк ярындагы тау. Иске Казан кальгасы урыны.

[4] Болгар – Бату хан, Биләрне алгач, Идел елгасы буенда Ибраһим авылы урынына ясак җыю үзәге итеп төзегән кальга, 1241(46)–1395(6) елларда Алтын Урдада Болгар Улусы башкаласы була.

[5] Халыкта Казан арты сөйләме бүгенге татар әдәби теленең нигезе дигән фикер яши. Минемчә, бу Иске Казанның кайчандыр Казан ханлыгы башкаласы булуына тагын бер дәлил. Башкалада рәсми кәгазьләр язылган, рәсми кәгазьләр теле дәүләт теле буларак, диалектларда сөйләшүче халыкларга да норма, мәҗбүри, ягъни әдәби тел булган.

[6] Котлы тау – Тәңрече руханилар – камнар камлавы нәтиҗәсендә күрсәтелгән, җаны, коты бар дип саналган тау.

[7] Казансу – Арча районында башланып Идел елгасына коя торган елга.

[8] Арча – Казаннан төньякка 60 км да урнашкан Татарстан шәһәре, район үзәге. 1552 елда Казанны яулаганнан соң Явыз Иван гаскәре, Арча кальгасын алырга барганда, Иске Казанны тар-мар итеп үтүе билгеле.

[9]Биектау – Казаннан төньякта урнашкан Арча белән чиктәш район үзәге.

[10] Шүрәле – Тукай әкиятләрендә тасвирланган, халык хәтерендә урман сарыгы дип сакланган, озын мөгезле, озын бармаклы, шыксыз маймылны хәтерләткән урманда яшәүче җан иясе.

[11] Ак Бүре – татар әкиятләрендә, халык авыз иҗатында киң таралган, кешеләр белән табигать арасында арадашчы, кешеләргә ярдәм итеп торучы, табигатьне саклаучы, кирәктә кеше кыяфәтенә дә, бүре кыяфәтенә дә керә торган мифик җан иясе.

[12] 1243 елның язында Бату хан хәзерге Венгрия, Чехия җирләренә барып, анда качып киткән хан Катян гаскәрен, каршы чыккан

тәречеләрне дә туздырып, Казансу, Идел елгалары тирәсенә әйләнеп кайта. Алтын Урданың төньяк чикләрен ныгыту өчен Казансу ярында кальга, төньяк башкала салу өчен урын карый башлый. Башкала өчен иң кулай урын итеп камнар бүген Иске Казан дип мәгълүм булган тауны күрсәтәләр. Бату хан шунда кальга төзи. Бу кальга Алтын Урда ханлыгының өч башкаласыннан берсе була, ягъни көнчыгышта – Каракорым, көньякта – Сарай, ә төньякта – Иске Казан.

[13] Бату хан – Чыңгыз ханның оныгы, Иске Казанга нигез салучы.

[14] Алтын Урда – Чыңгыз хан төзегән XIII–XIV гасырларда Идел буе Болгар ханлыгын, Көнбатыш Себер, Төньяк Хорезм, Дәште Кыпчак, Кырым, Төньяк Кавказ, рус кенәзлекләре җирләрен биләгән дәүләт.

[15] Сабантуй – татар халкының иң зур бәйрәме булган, чәчү тәмамланганнан соң үткәрелә торган сабантуйлар кайда, кайчан башланган? Сабантуйларны даими рәвештә, дошманнан курыкмыйча үткәрү өчен тынычлык һәм шул тынычлыкка гарант булырлык көчле дәүләт булуы шарт. Әлеге шартларны Бату хан һәм аның дәүләте булдыра. Шуннан чыгып, сабан туйны татарлар, зур итеп, нәкъ Бату хан Иске Казанны башкала итеп төзегәннән соң, ягъни 1243–1245 елларда уздыра башлаган дияргә нигез бар.

[16] Аксак Тимер – XIV гасырда яшәгән Урта Азия хакиме (1335–1405).

[17] Атлант – Атлантика океанында су астына киткән Атлантида материгында 20–50 мең еллар элек яшәгән төрки телле халык.

[18] Умай – илаһи көч (Бөек Ана образында. Мишәр-татар авылларында сөйләшкәндә сүзләрне, җөмләләрне ялгагыч сүз буларак «амый» сүзе еш кулланыла. Мисал өчен: «Выт амый, ышансаң – ышан, ышанмасаң – юк, булды инде, амый, шындый хәлләр», «Кит, амый, юкны сүләмә!»)

[19] Габдулла хан – Шәхре Болгарның соңгы әмире. 1395(6) елда Болгар шәһәре яуланып туздырылгач, әсир төшкән әмир Габдулла үтерелә.

[20] Алтын-Галим – туздырылган Болгардан качып китеп, Иске Казанны Казан ханлыгы башкаласы итүче Габдулла ханның уллары.

[21] Мулла Хаҗитаз – Муллахаҗи – Алтын бәк белән Галим бәкләрнең ярдәмчесе, гаскәр башы.

[22] Гайшә-бикә – Габдулла ханның кызы. Муллахаҗига кияүгә чыга.

[23] Чыңгыз – Бөек Чыңгыз ханга ишарә.

[24] Муллахаҗи зираты – халыкта Муллахаҗи Казансуның биек уң ярында Иске Казан кальгасы янында җирләнгән дигән риваять яши. Хәзер шул урында чардуган тотылган, янында гына мәчет төзелгән.

[25] Рун язмасы – төрки-татар Тәңречелек чорында кулланган имла рәвеше. Татарның төрле чорларда язуда шулай ук уйгур, гарәп, латин, кирилл имлаларын куллануы да мәгълүм.

[26] Скиф уклары – Иске Казан музеенда биредә табылган скиф уклары да бар.

[27] Хан чишмәсе – Иске Казан кальгасы җирендәге җиде чишмәнең берсе.

[28] Яңа кальга – 2010 елда Таттелеком ААҖ генераль директоры Лотфулла Шәфигуллин тырышлыгы белән Иске Казан музее территориясендә элеккеге эскизлар нигезендә агач кальга төзелде. Биредә фестивальләр үтә, киләчәктә сәләтле балалар катнашында кальга эчендә һөнәрчеләр шәһәрчеге үсәчәк.

[29] Эчке Казан – язмаларда Иске Казан белән беррәттән Эчке Казан дигән исем дә чагыла. Кайбер тарихчылар гомумән Иске Казан ул Эчке Казан дигән атаманың тора бара үзгәртелеп язылган варианты дип фаразлыйлар.

[30] Биләр – VII–XIII гасырларда Идел буе болгар ханлыгының башкаласы булып, 700 га җир биләгән, 50 000 (150 000) халык яшәгән, шул чорларда Ауропада Константинопольдән кала икенче иң зур шәһәр саналган.

## *Аю каны*

*Ишет улы – Көләй улы – Һади улы –*
*Ялмәт улы – Әбузәр улы – Әхсән улы –*
*Сөләйман улы Сөннәт бабам истәлегенә.*

**1**

Урды шашып
кызыл саплы комсыз чалгы
сайлап-сайлап тыгызларын кузакларның,
Куырылды табадагы борчак сыман
гамьсез авыл.
Агачларны агачларга үрде давыл,
кискәләде күкне, җирне
агачларның шыгырдавы.
Аждаһадай бер өермә:
шунда мылтык, шунда кылыч,
шунда адәм, шунда әләм,
шунда аты һәм эте дә...

**2**

Ләң-ләң килде ау этләре,
Юк, өрмәде, ләңгелдәде әйтерсең лә
оятыннан.
Бу каралык каршысында,
син – ак, урман, кара урман.
Жәлләү дә юк, юк кызгану –
Кан эчендә, кара кан эчендә аю өне...
Дары түгел көпшәләрдә –
сунарчылар дене.
Ах, булсачы
төшкә сыймас бер төш кенә!
Тик төш түгел, өндә,
Өнгә төбәп

Мылтык арты мылтык атты...
Аю каны акты, акты
тамга салып
Ләң-ләң килгән этләргә дә,
Өн туздырган читләргә дә...

**3**

Тамгалардан юк котылу!
Күктә яна якты йолдыз,
Кабынуын күрмисең дә...
Килә бер көн,
Канлы тамга кисеп төшә шәҗәрәңне,
И яңа җан, сәбәбен син белмисең дә.
Белмисең дә ни гаебең –
Башың тормыш ачысында.
Урман булып шауласа да сунарчылар,
Нәсел-нәсел авып килә гасыр буйлап
аю каны тамчысыннан...
И сунарчы, бичара җан!
Йә китапка, йә тормышка бирсәң дикъкать,
Ми киштәңә кунмый калмас иде, шаять,
Мәсләгеңә мән салырлык
Бер хакыйкать:
Халык бит ул – шул ук халык, һаман халык,
Халык бит ул – җил-тегермән,
Кайдан давыл –
шунда кыйбла,
Ни уенда – шул телендә:
«Ишеттеңме, тегесенең муены сынган?
Алла бар шул, сунарчының кулы корыган».

**4**

Аю канын юа-юа үкси урман,
Юаталмый үксез урман ятим аю балаларын.
...Чалыш күзле тимер читлек
йомарлады сабыйларны.
Хуш карурман! Хуш карурман!

...Төшкә керә Малдыйдагы*
яфраклардан тел очына тәгәрәгән
чык-тамчылар,
Истә һаман –
Карлы суын чәчрәткәндә
тамчыларга кунган балкыш
истә дә бит... –
Уен түгел,
Баштанаяк йотты кәмит ...
Урман шавы урынына кул чабулар,
Алдау-йолдау, сүгү-сугу, шикәр-кәнфит.
Тимер читлек, тимер таяк, очлы кадак,
сызгырулар, алкышлар да...
Уйнаса да онытылып, юк ышану:
аю, аю!
Арт аякта торганда да, чинап туплар куганда да:
әнә аю! аю! аю!..
Өйрәнсә дә түгәрәккә,
әйләнсә дә мәтәләкләп,
Елан булып шуышса да, –
Тимер таяк төште җайлап,
Бәгыренә юлны сайлап.

Ахры, кәмит язмыш диеп,
Гомер итте аю, биеп...

**5**

Читлектә дә аю булып калды аю,
Читлектә дә бу аюдан туды аю.
Рәхмәт сүзем табигатькә – канун тымат:
Читлектә дә, кәмиттә дә, иректә дә
эттән – этләр,
коштан – кошлар,
ә аюдан аю туа.

«Тимер таяк, очлы кадак, саклан, улым,
Түгәрәккә беркетелгән нәсел-ыру,
Ипләп атла, бик чыгарма чылбыр чыңын».
...Урман канлы булып чыкты яңа буын.

**6**

Муендагы корыч чылбыр чылбырмыни,
Каныңдагы чылбырлардан арыналсаң!
Карурманга юллар әле өзелмәгән,
Күңелеңә читлек куеп өлгермәсәң...

Ботарланды күңелдәге пәрәвезләр,
Йөрәк тарткан карурманга ятты эзләр.

**7**

...Аю каны тамырларда,
Канлы эзем бозлы карда.
Чәнечкедәй ташлары да
Табаннарны кисә-ерта...
Юк теләгем туктарга да,
Юк теләгем кәмит уйнап,
Җылы кәмит читлегендә йокларга да!
Күпме чабам, чабам, чабам...
Кайдадыр өн. Табам, табам!
Шунда каның, шунда рухың, аю бабам.
Тирә-якта һаман суык, һаман да боз,
Чабам-уйлыйм, уйлыйм-чабам –
Нинди тынчу тирә-якта, нинди борчу тирә-якта,
Әллә мохит үзе кәмит, әллә мохит – әллә ләхет,
Гамь йөрәктә, моң еракта,
Кайда соң ул җелекләргә сеңеп калган
кара урман, ул карурман!
Урман әле һаман алда, урман әле һаман алда...
Ахры, бабам, каның тамган
карурманга җитә алмам...
...Өмет синдә, өмет синдә,
синдә, балам!
Бер нәрсәдә һич юк шигем!
Кәмитчеләр барабаны
биетсә дә яшьрәк чакта,
Ул исерткеч кул чабулар,
бию көе, кәнфит-мазар
Зиһенемне капламады,
әллә кайдан, тамырлардан
күтәрелде бабам каны,
урман каны, аю каны!
Мин тапкан юл – карурманга,
Эзләремне дөрес салам –
туры кыйблам!
Ылыс тәмен алып килгән

Һавадагы дымсу җилдән,
Карурманым – туган йортым, тоям, тоям...

**8**

Үзем чабам, үзем уйлыйм, үзем аңлыйм:
Татар җире – шул карурман!
Карурманны тоя табан,
Карурманда эзем салам.
Ташпулатлар яр буенда
нарат, чыршы урынында...
Тынын җуйган таш чабактай
таш улакта ята Болак.

...Кая чабам? Кая, Кая?!
Шул түгелме минем урман?
Аңым белән бар җитәсем,
Җаным белән бар җитәсем.
Кәмит – артта, өмет – алда, мин – иректә!
Тик нигә соң йөгерүем торган саен хәтерләтә
шул кәмитне,
кул чабулар, алкышларга,
«хи-ха-ха»га чатнап тулган түгәрәкне?!

**9**

Кайда кыйбла? Кайда урман? Кем иректә?
Мин читлектә, мин – читлектә!
Бу читлекне күрә алмас маңгай күзе,
Күренмәс ул ачылмаса күңел күзең.
Сунарчылар уйный кәмит бу читлектә,
Аңлап кара, кем ирексез, кем иректә.
Зур читлектә бу зур кәмит,
Зур кәмиттә теге кәмит,
Шул кәмиттә теге читлек,
Шул читлектә без буй җиттек,
«Аяк-кулда юк богаулар,
безнең кыйбла ирек!» – дидек.
Күпме чаптым, ә як-якта –
Янә кәмит,
Янә читлек...

**10**

Бер урманнан тамыр алган,
бер урманнан бәгырь алган,
карурманда бер өн салган,
шул урманда каны тамган
Нәсел башы аю бабам.
Карурманга мин җитмәсәм,
Юл үтәргә сиңа, балам,
Сиңа, балам!..

*1994 – 1995*

## ***Әтиемә җиде рәкәгать****

Кыйблаи җан вә мөгаллим – әтиебез бире,
Мәңгелектә күрешергә
насыйп итсен иде Тәңре...

*Ташка язылган сүзләр*

Иң татлысы сүзнең –
телгә чәчрәп чыкмас,
Иң асылы сүзнең – тирәндә,
Иң саллысы сүзнең

язма булмас,
Тынын кыса язма-биләүләр.

Затлы сүзләр мәгънә-җептә була,
Җеп өзелсә, сүзләр тарала,
Затлы сүз ул
фототасма сыман –
Яктылыкка чыкса – карала...

Мәгънәле сүз –
зиһен канатында каурый,
Мәгънәле сүз –
хәтер-сандыкта...

Уй-кысага кысылмаган мәгънә,
Тел-пычкыда киселмәгән мәгънә –
сүздән түгел тышчаң –
...тынлыктан...
Әйткәннәрдән сабак алып
үземә дә,
Тәмам, диеп,
Уйларымны сүзгә җигү,
Бу гамәлгә
нокта кую
кирәк иде...

Тик
дәшмичә
торамыни
хәтер,
Хәтта күздән
бәреп чыга
кайсы фикер.

Дөрес, диик,
башта әйткән сүзләр,
Күпьяклы бит һәрчак
дөреслек,
Уйларымны төгәл биралсамчы,
Хис-тойгымны кушып язалсамчы,
Аллаһ бирсен миңа
хирыслык.

Хакыйкатьнең киресе дә дөрес,
Киресе дә аның – хакыйкать.
Дәвам итәм ошбу язмамны –

Әтиемә җиде рәкәгать...

*****

...Нихәл, Әти?
Җан җепләрең тоям,
Йомшак, җылы, нурлы
балкыштай.
Җан җепләрең мине чолгаганмы,
Әллә минме сиңа уралган?
...Минем күңел
аерылган коштай,
Каңгыл-каңгыл,
Хәтер елгасында
Каурыйларын сылый
ярларга...

Баян белән бергә
Ятим тальян
Очырттылар ничек
«Күбәләкне»!
Тальян гармун
Ничек өзгәләнде
әйтерсең лә
...әти кочагында –
әйтерсең лә тальян
Шәүкәтле...

Казан кунагының җитез бармакларын
Әтинеке диеп
белептер,
И моңланды гармун,
И ярсыды,
Ахры,
хуҗам кайтты
диептер.
Гармун теле –
күңел төпләреннән
Тарта хиснең
көмеш чыңлысын,
Гармун теле
бәйли хисне хискә...
Бәгыремә тегә... соңгысын...

Көтеп алды тальян
билләрендә
вак-вак басып
бармак биюен.
Әйдә, тальян,
уйна өзеп-өзеп,
Сал уртага яну-көюең.

Акты көйләр
йә таң җиле булып,
Йә күректән
ташты шашынып...

...Әнә ...Әти...
үзе түгелме соң?
Кайтып килә тиз-тиз, ашыгып...

Әзме төннәр безне ялгый, Әти,
Төшләр керә, керфек какмыйча.
Шигырь-җырлы табын җыелганда,
Түзәмени Әти, кайтмыйча...

– ...Бу юлларны, улым,
Языйм әле үзем,
Җан түрендә
Урын җаныма,
Синең күзләр аша
Илдән сагыш җыям,
Синең йөрәк белән
сагынам...

Икеләтә хәтер,
икеләтә фикер,
Нәсел-тамырлардан
фатихалы, шөкер...

– Әти, ник үзгәрдең,

кырыс карагандай.
– Хыял-фараз кылып,
арттырма син, малай...
Һичкем юрамады
янә туарсың дип,
Синең сулыш белән
әле суларсың дип...

– Йомгак-күңел, әти,
Чорналмаган иплəп,
Синнән көтәм киңәш,
Синнән көтәм сихәт.
Өйрәт яңабаштан
Моңга
Минем җанны,
Сына кат-кат ныклап
Булган-булачакны...
Уйна, тальян,
Уйна,
Моңың исән, шөкер,
Синең аһәң белән
Җанлы
минем хәтер...

Курай моңын йотып тынган
Факир еланыдай,
Язмыш үзе
Җайланган күк
Гармун уйнавыннан.

Гармун көе ятты җайлап,
Сихри келәм булып...
Келәм түгел, асылда, ул –
Ике дөнья юлы...

Уйна, тальян,
уйна,
уйна!
Тукыл, келәм,
Тукыл!..
Шул келәмгә җанын үрә,
Сәҗдә кылып,
Угыл...

**2**

Ярый әле
яшим
Истәлекләр белән,
Мин фәкыйрьне
Хәтер яшәтә,
Кайсылары
сырлар өсти сырга,
Тирәнгәрәк төшсәм –
яшәйтә.

Киләчәк тә яши күңелемдә
Кичәгенең өмет-күләгәсе булып,
Әйт, нәрсә соң
Яши хәтерсез дә?
Кайсы мизгел?
...Тарих булды инде
бүгене дә...

Истәлекләр алар –
Вакыт баскычлары,

Хәтердәге
Кыска гомерләрнең
бүлмә ачкычлары.

Йөрим хәтер буйлап,
Үтәм бүлмәләрне,
Ачам-ябам берсен,
Сүтәм
кай-
бер-
ләрен,
Кайсыдыр бүлмәнең
Табалмыйм ачкычын...
Бәдән – җирдә казык,
Шунда йомгак очы.
Йөрим әле,
йөрим,
Йомгак
сүтелгәнче,
Йөрим әле,
йөрим,
Вакыт
ишелгәнче,
Үзем генә түгел,
синең белән, Әти,
Синең истәлекләр
яши миндә, яши...
Әйтерсең кан белән
йөри буыннарда
Ярты гасыр элек
багышланган язма...

Укыйм шуны.
Язмаларда
Синең кулың сызган сүзләр:

...«Төн караңгы,
Ай да бүген
Әллә кайчан ятып йоклаган,
Күкнең йөзен болыт каплагандай,
Йөрәгемне сагыну каплаган»...

Һәр иҗеге сагыну тулы җыру,
Язмышыма ачкыч бу юллар,
Минем күңел – тибрәләсе бишек –
Мин туарга әле – өч еллап...

Җирне каплап алыр иде,
җәйсәң
сагыш-моңын –
Болыт артларында
йөзгән чагы
көләч айның...

Дәвам итәсең син:

...«Йөрәгемдә булган
матур уйлар
Сиңа омтылалар туктаусыз.
Тагын күпме вакыт, йөрәгемне телеп,
Тилмертерсең мине җавапсыз»...

...«Хатлар килмәсә дә,
Һаман язам,
Яратуым көчле булганга;
Һәр көн сине уйлыйм,

Кайчак елыйм,
Күңелкәем ташып тулганга»...

Ай-һай, Әни, салгансың ут-ялкын,
Егет тә бит – авыл асылы...
Хәтердәге серле бу бүлмәләр
Миннән соң да әле ачылыр...

Кара тышлы язма китап,
Вак шакмаклы битләре,
Алма йөзеңә сыйпала
Канәфер чәчәкләре.

Чәчкәгә чәчкә тәңгәл дип,
Үргән эти хисләрен.
Болытлы күргән чаклары
Йолдыз тулы кичләрен...

Затлы китап язмалары
Мәрҗән муенса сыман,
Кырык дүрт сәнә җемелди –
Гүя кичә язылган...
...«Нигә күзең болай серле,
Елмаюың сөйкемле,
Таң алдында алсуланган
Шәфәкъ нуры шикелле.

Син минем күгәрченкәем,
Син бит сандугачкаем,
Син минем йөрәгемдәге
Кара карлыгачкаем»...

...«Диңгез өсте матур, тын булса да,
Дулкын какса, көймә капланыр;
Сиңа булган керсез мәхәббәтем
Йөрәгемдә мәңге сакланыр».

...Төн йолдызлы бүген,
Ай тәрәзгә карый,
Гүя ул да укый язмаңны...
Ай нурында сүзләр –
Сиңа илткән эзләр,
Мин кунагы
синең дөньяңның...

Монда кердең исә –
Адашмамын димә...
...Күңелдәге дөнья –
Бүлмә арты бүлмә...

**3**

Фани дөньялардан,
кинәт түгел,
Без китәбез икән
Боз сөңгесе сыман
тамчы-
тамчы.
Яшәү дә юк,
Үлем дә юк,
Бар тибрәнү,
Шул истәлек
Эрегәнче,
Кыйпылганчы...

Без китәбез икән
Тамчы-тамчы, –
Киткән саен
Безне танып белүчеләр,

Олыгая минем хакта
Хатирәләр, –
Гүргә күчкәч
Яшьлегемне күрүчеләр...

...Ләйсән сыйпый
Көмеш чәчләреңнән...
Кара толымнарың
Истә, Әни, истә...
Моңсуланып әйткән сүзләрең дә
Бик еш төшә искә:
«Улым, син бит килдең
Яшьлегемнән, – дидең... –
Тормыш – алсу таңлы,
Дөнья тылсым иде...
Синең хәтереңдә
Яшим синнән дә яшь,
Нинди булган булсам,
Килен булып төшкәч...
Хәтер картаймый да...
Төпчегемә исә
Гомер яктысыннан
Шәфәкъ нуры төшә...»
Тоныклана хәтердәге
эзләр,
Яланган
сөяк
шикелле
шомара бара
сүзләр...

Яшим әле бүген,
Шөкер әле яшим...
Шөкрана көннәр, айларга...
Яшимме соң, яшибезме, Әти?
Бар ул җавап,
Әмма...
Кайларда?

Безнең гомер –
Кисәк-кисәк булып,
Безне белгән-күргәннәрнең истәлеге.

Боз-сөңгеләр эрегәндә,
Тамчы-тамчы
Хатирәләр җыясыңдыр
Син дә, кальбем...

**4**

Дүрт фасыл ул –
Бер-бер артлы түгел –
Бер вакытта икән
Дөньяда.

Бербөтеннең мең кисәге булып,
Дөнья үзе
Безнең уйларда.

Дүртпочмак ул – дөнья,
Дүрт фасыл да сыя.
Бер үк вакыт –
Кемдер
Җырлый-җырлый
Җиләк җыя җәйге болында,
Кайсылары,
Яңгыр-җилне сүгеп,
Салам өя арыш кырында...
Урамнарны кочкан бураннары белән
Матур кышлар бире,
Ак кар дисәң, –
Ап-ак күбәләкләр –
Ачык, гади сере:
Күппочмаклы
Дөнья, –
Хәтсез
фасыл сыя...

Боз сөңгедән
соңгы тамчы –
Кемнәргәдер
Тәүге тамчы
гомерендә...
Кемнәргәдер
Язлар килә шаулап...

Дөнья сәхнәсендә
Адашканбыз,
Йөгерәбез
Җәен – ак кар,
Кышын чәчкә даулап...

Кайдан килгән гадәт?!
Күзәтәбез көзгеләрдән
Йөзебездә
Фасыл чагылышын.
Күрә белсәк икән
Ошбу көзгеләрдә
Түгел маңгай сырын –
Истәлекләр сынын...

**5**

Мәрәй-максат – рәшә,
Ә чынбарлык менә... янәшә.

...Көпшә тузды,
Ядрә атылмады,
Эреп юкка чыкты рәшәләр.
Көпшәләрдә күпме дары,
Ядрә иде...

Тик... кызганмыйм,
Юк,
Шөкер итәм –
Әти-бабай, сездән дәва килде –
Иман тулы хәтер-касәләр.

...Сорамагыз миннән
Еллар санын,
Мин... оныттым,
Әллә
...Белмәгәнмен аны.

Миңа – ун да,
йөз дә,
кырык та.
Күп нәрсәне
Күргәндә үк
Онытам,
Ә күпмесе,
күбрәк –
күптәнгесе,
Чыгамыни истән,
Кырып та...
Бу дөньяның
Алды да – арт,
Арты да – ал...
Алда – зират,
Артта – балбал...
Ара якын –
Юллар ерак.
Эзлим сине,
Эзләреңнән йөрим
Төнне айкап...
Көндез
Мин юк,
Син дә, Әти,
Белмим кайда.
Шау-шу, шау-шу, шау-шу...
Дөньяда – шом,
Күңелдә – шом.
Тынгы буламыни:
Күз алдында халык –
Кибеп барган саз ләмендә –
хәлен җуйган балык...
Көндез бик куркыныч,
Көннәр –
тайгак, тайгак...

...Ничек кенә өзгәләнми былбыл,
Елаганын кемнең күргәне бар... –
Өзгәләнә сайрап!
...Истә калган соңгы биюләрең,
Үлсәм, үлим
Җырлап,
Биеп
диюләрең...

Ышана да, ышанмый да кеше,
Читтән эзли әзер оялар.
Киткән юлын кайткан юлга ялгап,
Нигезенә ятып уйлана...
Кая барма –
Бердер дөньялар.
Кайда да шул
Фани дөньялар...
Үскән җирдә – туфрак,
Каккан җирдә – казык –
Юккамыни чарлап,
Телгә керткән халык...

**6**

Бишни карандаш эзләре,
Уңып барган кәгазь,

Яңа ауган чыршы исен
Саклый соңгы вәгазь.
Кәтеринбур, Кәтеринбур,
Җилләрең –
явыз-зарлы,
Кайсы куакка сыенган
Бисмилла
авазлары?
Сагынулары мендәр булган
баш очында,
Юрган итеп ябынгандыр
хыялларын.
Төшләрендә
Остазбикә-Галиябану...
Себер таңы балкыш булып
Кабынса да,
Күздән ары үткәндер шул
Соры булып укмашканы
Буяуларның...
Түзалмаган,
Ярылгандыр
Үзәкләре
Чатнап,
Сөннәт бабам
Елаганда
Себер агачларын
Кочаклап.

...Ундүрт әле Сиңа ул чак,
Егет инде
егет,
Акны кара
иткән заман –
Җәлләнмәгән дегет...
Бер фикерне куам баштан:
Көзге чебенмени!
Ахры, язып котылмасам,
Үзе китә белми.
Минем язмыш –
Шул ук чатта,
Кызыма да
ундүрт тула...
Йә, әйтелдең, тәүбә, тәүбә,
Югал инде, югал...

...Юллар елан булган чаклар,
кая бассаң – шунда чаккан,
бирешмәгән, бөрешмәгән,
шул ук төптә, шул кәсептә,
Иман – төптән, моң – Чишмәдән...
Кырау сугамыни утны –
Яшьлек бит ул – уттан,
Тәүлегенә айлар сыйган,
Елын көннәр йоткан...
Сугыш кыры – тимер сандал, –
Кылыч була
чыбык,
Ир уртасы –
кайттың исә,
Исән-имин чыгып.

Җил-давыл дип,

Боз-яңгыр дип,
Япмагансың
Күңел ишекләрен,

Шигырь булып үсеп чыга
Син Остаздан
Безнең җанга
иңгән
Татар иҗекләре...

Акланыйм дип батмагансың
Ак күбеккә,
Аклансыннар
Бәгырьләре
Кара мунча ташы булган
Адәмиләр.
Корым белән каралмый ул
Ак фикерләр,
Ак хис-тойгы,
Ак гамәлләр.

...Әүлияләр тарихына
күз салсагыз –
Әллә кайчан
Ул инсаннар
Яшәгән, ди...
Ә нигә дип ерак барасы?
Әзмени ул – әти-әнисен
Әүлиягә саный баласы.

Минем өчен
Син әүлия, Әти...

**7**

И мин фәкыйрь,
Хәтер җепләреннән
Язма үрдем –
Ашсын дип Әтигә,
Бер башында – Әти,
Бер башында – үзем,
Шул да тансык
Бәгыре ятимгә.

Сүзләрнең бар
Мәгънә ягылганы,
Әти сүзе –
Тоташ
мәгънәдән.
Хәтер төпләреннән
күтәрелә сүзләр:
Колак йоткан –
Күңел
күрмәгән...

– ...Дөреслек юк...
Бу шомарган фикер –
Үз-үзеңне аклау өчен акшар сыман.
Уйлап кара:
Дөреслек бар.
Фани дөнья
Миллиардлаган дөреслектән,

Бары дөреслектән
тора.

...Бер кояш та
кемгә – артык кызу,
Кемдер көтә
көннең эссесен.
Һәр адәмгә
үз дөресе дөрес,
Мәсләгенә таман,
күңеленә ятыш,
Моңа тагын нәрсә өстисе...

Һәр кешенең
Үз туксаны туксан,
Сүзең дөрес бүген,
Әгәр өскә чыкса.

Кем тапкандыр уйлап
БӘХӘС сүзен,
Мәнлеләргә
бар – фикерләшү.
Бер-береңә шырпы кадамыйча,
Сүзне сүзгә
ялгап сөйләшү.
Фикерләрне тартып
бер-берсенә
түкмә көчең.
Ялганмаган фикерләргә
фикер җитми
фикерләрне
ялгау өчен...

Үз илеңдә
җан тапмаган сүзең
Канатланып
кайтып керә
чит-ягадан...
Әйе,
Бәллүр булып
Камаштыра күзне
Күрше кулындагы
Пыяла да...

Ап-ак казлар – көтү-көтү булсын, –
аккош сагындырыр –
аккош
тумас...
Әйтсен кеше,
халык әйтсен,
әйтсен дәүләт –
Күп дөреслек
Бер хакыйкать булмас...
Язмышмы бу, әллә ялгышумы,
Тән чолгаган җанга
Юк дикъкать...

...Кем күрсәтсен
Хакыйкатькә юлны –
Алла гына бары
Хакыйкать...

*1996*

Искәрмә: Әтинең 1952 елда әнигә багышлап язган шигырьләр дәфтәреннән өзекләр куштырнакка алып китерелә.

***Эчтәлек***

**Шәҗәрәдә – яфрак...**


«Һәр җанлының үз әмәле...» .............................
«Җиде казык тота...» ...................................
Олы сәфәр .........................................
«Ни ул сагыш?..» .....................................
Шәҗәрәдә яфрак булып .................................
Ат тоягы ...........................................
Казан елгасында су түгелдер ..............................
Авылымда яңадан мәчет ачылып, ике ел үткәч... ................
Татарстан картасына карап ...............................
Болгар җиле .........................................
Диңгез күрмәс иде... ...................................
Ә һәлакәт якыная .....................................
Ит тегермәне көенә .....................................
«Мең җәрәхәт – түзә йөрәк...» ............................
«Чит-ят мохит, чит-ят гадәт...» ............................
Бу заман язгы елга күк .................................
«Әйттеләр, халкым, бире кил...» ............................
Татарстан флагына карап ................................
«Күк һәм җир – тегермән ташлары...» .......................
«...Һәр җанлыга туу, үлем зарур...» .........................
«Әмма ләкин...» ......................................
«Катлам-катлам боз астында...» ...........................
Тәкә бәхете .........................................
Ачыну .............................................
«Бире»дә ул да, мин дә... ................................
Кем соң җайлар телнең җанын ............................
«Янә кайтты...» .......................................
«Комда мизгел...» .....................................
«Уйланырлык: авыр ул киселү...» .........................
Соңгы болыт .........................................
«Җыр кирәкме сезгә?..» .................................
Дәүләтле татарлар .....................................
«Беркемнән дә түгел...» .................................
«Каурыйлары...» ......................................
«Мәҗүсилек кылларында...» .............................
«Хәтсез йолдыз күктә...» ................................
«Диңгезгә килдем...» ...................................
«Без бар икән җирдә...» .................................
«Чиста күңел...» ......................................
«Җиде күккә күтәрел дә...» ..............................
Татар йорты ..........................................
Өч таш .............................................
«Нәрсә соң ул Бәхет, диеп...» ..............................
«Дуслык ни ул?..» ....................................
Асылташ ...........................................
Болгар таҗы .........................................
«Халык өчен...» .......................................
«...Куркасы юк...» .....................................
«Ишкәкләрдә озак барырбызмы...» .........................
«Бер сүнеп, бер янган милләтем...» .........................
Иске Казан .........................................
«Канатларны каурый-каләм иттем...» .......................
«Гарәп канатлы татар мин...» .............................
Хәтер .............................................
Татарга ............................................
«Бармы ул халык хәтере?..» .............................
«Вакыт – тырма...» ....................................
Шәһре Биләр ........................................
Имин генә булсын татар-йорт! ............................
Фикерләр ..........................................


**Казыкактым...**


«Бар төрле савытлар...» .................................
Ташларыңны барлар заман ...............................
Казык ............................................
«...Бу дөньяга ялгыш кергәнмен лә...» .......................
Мин бүген кырмыска ..................................
«Үз-үзеңә...» ........................................
«Безнең шигырьләребез...» ...............................
«Кеше, сине чагыштырам кое белән...» .......................

«Күңелем пыяладай...» ..................................
«Йолдызларын коя-коя...» ................................
Җеп очлары күп тә ....................................
Бәхет-сагыш – бер көянтә ................................
«Күңелне чигүләр бизәсә...» ..............................
«Үз мохитен тапкан кеше...» ..............................
«Тамак ялгаганда аш кирәк...» ............................
«Әйттең, әни, балам, бәгырем, сүзем тыңла...» ...................
«Кәеф...» ..........................................
Язгы уйланулар .......................................
«Галәм кешелеккә кырыс әти кебек...» ......................
Афәт шәүләсе ........................................
Юк тыңгы ...........................................
И балык ............................................
Фән һәм шигырь ......................................
«И телем, синнән файдамы...» .............................
Инсайт .............................................
«Сусаганда җир өстендә...» ..............................
«...Ә тормыш – көтүче курае...» ...........................
Түрә булам, дисәң... ....................................
Асылда... ...........................................
Фикер .............................................
«Күңелем – давыл биштәре...» ............................
«Инде күптән Инсан күктә...» ............................
Коелыгыз ...........................................
Тормыштан ..........................................
«...су өстендә әрле-бирле...» .............................
«Күл өстендә...» ......................................
«Күңел күге тишкәләнә...» ...............................
Ямаулыклар .........................................
«Авышты таң көнгә...» ..................................
«Бер күләгә – кара да ул...» ..............................
«Чәй-шикәр дә, бал да түгел...» ...........................
«Җәй...» ............................................
«Вакыт – тырма...» ....................................
«Оныткан да ник искәнен...» .............................
Бу җыру җыру түгелдер .................................
Үлән арасында имән ....................................
«Көмеш ятьмәме ул...» ..................................
«Аллы-гөлле...» .......................................
«Офыктагы кояш кыйпылчыгын...» ........................
«Таш ишелә, юлны каплый...» .............................
«Борын-борын заманда...» ...............................
«...Җир йөзенә карап...» ................................
«Чишмә тавын йөгереп үткән идем...» .......................
«Хаталы сүз йә сызыла...» ...............................
«Җиз кыңгырау чыңгылдавы...» ..........................
«Бер гыйбарә...» ......................................
«Аһ, әлиф...» .........................................
«Бер түмгәге бер гомергә тигез...» .........................
«Көндез якты...» ......................................
«Таң нурына меңнәр үрелгәндә...» .........................
Чи-керт-кә-стан .......................................
Урта диңгез – Олы диңгез ...............................
«Бөркет – бөртек-бөртек...» ..............................
«Төнге күктән шәһәр...» .................................
«Күңелдә сүз...» .....................................
Мин – минсез дөньяда ..................................
«Шатлык – якты...» ....................................
«Йодрыкларым, йомшап...» ..............................
«Өелмәсә ватык хатирәләр...» .............................
«Җиһан берни түгел...» .................................
«– Язганың – байтак...» .................................
«Кыяларда...» .......................................
Үз илемдә .........................................
«Орлык холкын белә, диеп...» .............................
«Тун-толыплар кияр идем...» .............................
«Акка кара язасыңмы...» ................................
«Язмыш гүя патефон...» .................................
«Адәм – язмыш каләме...» ..............................
Тән һәм җан .........................................
Нәфес (*Цикл*) ........................................
«Мәхәббәтне нәфес-субай тота...» .........................
«...Нечкә кыллар...» ...................................
«Нәфес – сөю...» .....................................
«Күңел тишкәләнсә, ямау салам...» ........................
«Минем көймә янә дулкыннарда...» .........................
«Дөнья читлегендә…» ..................................

«Кабаланма кыйбла күренми дип...» ........................
«Яшел үзән күренмәсме диеп...» ............................
«Атларга йөгән кидермим...» ...............................
«Иңнәреңә офык салган килеш...» ...........................
«Җирдә яшим, йөрим дисәң...» .............................
«Коедан су алмый торсаң...» ...............................
«Җирдә чакта адәм вазифасы...» ............................
«Җан күгендә очар мизгелләрдә...» ..........................
«Караңгыда чыра кабынса да...» ............................
«Эткә – хуш исле печән...» ................................
«Каплагыз кояшны, җәегез төн-пәрдә...» .....................
«Караңгыда чаткы да йолдыз булып күренә...» ................
«Бәхетме?..» .........................................
«Тәкәбберләнүчеләргә...» ................................
«Картайдым дип...» ...................................
«Мактанчыкларга...» ..................................
«Акылдамы акыл?..» ..................................
«Саум Мәнни Пат Фәһем!..» ..............................
Өч бишек ...........................................
«Әйе, татар, туу, яшәү, үлү...» ..............................
Ни әйтәсе кала? .......................................
«Үтә еллар, уза гомер...» ................................
Дүрт ат ............................................
Монологлар .........................................
«Көмеш тәңкә булып йөзә өстә күбек...» ......................
«Гомерне ике яшәсәң...» .................................
Тормыш – балан ......................................
«Күз алдында...» ......................................
Тормыш – гармун .....................................
«Өзелә калса ике кылы бәгыреңнең...» .......................
«Иоганн Гёте, һәм Добровский, һәм Мәхмүтов...» ..............
Моцарт йортында. Венада ...............................
«Ап-ачык, ап-ак...» ....................................
Өмет ............................................
Авылыма ...........................................
«Ник язылa озын шигырь...» .............................

**Таң калдым чәчкәгә күз атып...**

«Җайлы ул әйтергә...» ..................................
«Ярсыз елга...» .......................................
«Вакыйг бәхет: сөлек сында...» ............................
«Бер мизгеллек бәхет!..» ................................
Кара җиләк ..........................................
Курай моңы ..........................................
Сиңа гына ..........................................
Әллә бармы гаебең? ....................................
«Өзгәләнмә...» .......................................
Мине көткән чәчкә-гөлләр ...............................
«Йа Аллаһы! Фәрештәңә тиң илчеңне юксындыңмы...» ...........
Туй уңаеннан .........................................
Ник сорыйсың телеп йөрәгем? .............................
«Иңдә – җиһан...» .....................................
«Аһ, җиргә иңәр идем...» .................................
И тылсым! ..........................................
«Җир өчен кояш ул бердәнбер...» ...........................
Янар чәчкә ..........................................
Тулган ай ...........................................
«Уйладым: күңел ул ни икән?..» ............................
Әйдәле, хыял, яшьлеккә .................................
«Әгәр син җаныем булмасаң...» ............................
Боз китә ............................................
Тиңең җуйгач ........................................
Күңел дулкыннарың ...................................
Агылам төшләреңә .....................................
Вакыт юк дип зарланучыларга ............................
«Яшьлеккә күперләр тиз туза...» ............................
«Сиңа, җаным, кулай итеп...» .............................
«Кан тибешең күчте минем канга...» .........................
«Мин менәсе таулар...» .................................
«Сагынам да, тизрәк күрешүләр...» .........................
«Йолдызлы күк...» ....................................
«Болын – яшел...» .....................................
«Җылы сүз дип...» .....................................
«Өзелгәнем, җирдә эзләгәнем...» ...........................
«Арыш мыегын кытыклап...» .............................
«Күңелем – сәхнә...» ...................................
«Кара толым, кара чәч...» ................................
«Олы елга ташмый калмый язын...» ........................

«Урта диңгез кочагында...» .............................
«Йөрәк әрнүеннән улый-улый...» ..........................
Үкенмәм ............................................
Кизләү суы, чәй суы ...................................
Синең күзләр ........................................
«Кил әле, таң гөлем, кил әле яныма...» .......................
Җанкисәгем Венерага ...................................
«Һәрнәрсәнең ахыры бар...» ..............................
«Дөреслектән дөреслеккә...» .............................
Мәхәббәт ............................................
«Кышкы урман. Аккош күле...» ...........................

**Ак шигырьнең ак юллары...**

«Вакыт – елга...» ......................................
Әнием ............................................
Әй, дәрья ............................................
«Әбиләр чуагы бер килер таҗ булып...» ......................
«Әзерме син, зиһен...» ...................................
«Ак битләрне каурый-каләм бизәсә дә...» .....................
Ялгыз имән ..........................................
«Бәягезне беләсез Сез...» ................................
Рәхмәт ............................................
«Дон Кихотлар ничек булмасын ди...» .......................
«Җир өстендә...» ......................................
«Мин – диңгез дулкыны...» ..............................
«Җидегән йолдыз чүмеченнән...» ..........................
«Төнге күккә төрдем...» .................................
«Ап-ак карлар явып үтте җиргә...» .........................
«Шигырь түгел, затлы сырамыни!..» ........................
«Кояш яктысыннан бирәү...» .............................
«Гомер-яфрак алсулана...» ...............................
Кырыгыңда очрашу ...................................
«Өметсез – шайтан, дисезме?..» ............................
«Җидегә ярылам...» ..................................
«Җе» дигәндә җан да, җен дә, җил дә...» ....................
«Ал кулыңа моңлы тальян-дустың...» ......................
«Безнең гомер...» ......................................
«Син күк булсаң...» ....................................
Безнең җизни мунчасы .................................

**Ташъязмалар**

Ташъязмалар ........................................
Тамырлар ...........................................
Иске Казан *(Цикл)* ....................................
Аю каны ............................................
Әтиемә җиде рәкәгать ...................................

Литературно-художественное издание

**Сулейман**
(**Сулейманов** Джавдет Шевкетович)

***Разматывая клубок***

Казань. Татарское книжное издательство. 2011

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Сөләйман**
(**Сөләйманов** Җәүдәт Шәүкәт улы)

***Сүтелә йомгак...***

Мөхәррире *Ф.И.Фәтхетдинова*
Рәссамы *Ф.Я.Нәбиуллин*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректоры *Р.Н.Нуриева*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 10.05.2011.
Форматы 70□108 $^1/_{32}$. Шартлы басма табагы 18,2.
Тиражы 3000 д. Заказ Р-633.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Татмедиа» ААЖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.